ключевое понятие «языковая картина мира», под ним лингвисты понимают отражение национального мировоззрения. В рамках лингвокультурологии фразеология стала рассматриваться как отражение языковой картины мира. Исследование языковой картины мира способствует организации информации об объективной действительности. Термин «языковая картина мира» лингвисты объясняют как социально значимую, системно упорядоченную модель знаков, выраженная с помощью разных средств языка и содержащая информацию об окружающем мире. Языковая картина мира переплетается с проблемой мышления и языка.

Лингвист А.А. Кибрик даёт следующее определение: «языковая картина мира - это исторически сложившаяся в обыденном сознании данного языкового коллектива и отраженная в языке совокупность представлений о мире, определенный способ концептуализации действительности» [Кибрик, 2002; 11]. Во фразеологии как отражении языковой картины мира воспроизводятся черты материальной и духовной культуры общества. Лингвисты изначально отмечали национальную характерную составляющую, присущую фразеологическим единицам в раках языковой картины мира различных народов. Уникальность фразеологических единиц каждой нации объясняется различным образом жизни общества, разным менталитетом конкретного народа.

Особенность восприятия мира каждого народа проявляется в образе жизни. Его отражение находит место в семантической структуре языковых знаков. Примером служит частота употребления семы «Бог», так как это отражает монотеистическое представление христиан о всемогущем создателе всего сущего. Религиозное представление о создании мира и бытия в принципе связано с данной семой и схожими лексически семами типа «господь», «Боже», «царь небесный», «отец небесный», «всевышний (судья)», «вседержитель» и другие. В русском языке фразеологических единиц, в основе которых вышепредставленные языковые единицы, около 220, пословиц и поговорок – около 250. Сема «Бог» часто во фразеологизмах отражает монотеистическое представление христиан о вездесущем создателе мира.

Фразеологизмы передаются из уст в уста, это бесконечный процесс передачи от поколения поколению информации о устоявшейся системе обычаев, законов, традиций и обыденных представлений о бытии. Фразеологические единицы отражают стереотипные представления о культурно-национальном фонде.

**Литература**

1. Кибрик А.А. Языковая картина мира // Энциклопедия Кругосвет. – М., 2002.
2. Маслова В. А. Лингвокультурология: учеб. пособие для студ. высш. учеб. заведений. 2-е изд., стереотип. – М.: Издат. центр «Академия», 2004.
3. Фразеологизмы в русской речи: словарь-справочник / сост. Н. В. Баско. 2-е изд. – М.: Флинта; Наука, 2007.
4. Шанский Н. М. Фразеология современного русского языка. – СПб.: Спец. лит., 1996.

# Ә. ЕНИКИ ПУБЛИЦИСТИКАСЫНДА БАШЛАНГЫЧ МӘКТӘПТӘ ТУГАН ТЕЛНЕ ӨЙРӘТҮ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕНӘ КАРАШЛАР

**Гайнуллина Г.Р.**
Казанский федеральный университет
gulfiarasilevna@mail.ru

**Аннотация.** Публицистика Амирхана Еники, в отличие от литературного творчества писателя, на сегодняшней день является малоизученной темой. Публицистика писателя интересна и тем, что в ней ставятся вопросы преподавания родного языка как в средней, так начальной школе. В статье предлагается обзор взглядам А.Еники к вопросу преподавания родного языка в начальной школе.

**Ключевые слова:** публицистика писателя, А.Еники, родной язык, начальная школа.

Татар әдәбияты классигы Әмирхан Еники гомеренең соңгы ике дистә елын тулаем публицистикага багышлый. Әдипне туган тел мәсьәләсе, башлангыч һәм урта мәктәптә татар телен укытуның торышы борчый: “Җыеп кына әйткәндә, тел мәсьәләсендә минем карашым менә нидән гыйбарәт: татар халкының кимендә яртысы үз телен (ана телен) югалтты. Сәбәбе билгеле: большевиклар партиясенең вак халыкларны, аеруча безнең татарны, әкренләп урыслаштыру сәясәте иде... Хрущев вакытында ук Татарстан шәһәрләрендә, шулай ук күрше өлкәләрнең авылларында да татар мәктәпләре ябылып бетте диярлек... Казанда, мәсәлән, татар балаларының 93% урыс мәктәпләренә күчте. Утыз ел буена без балаларыбызны ана телендә укытудан мәхрүм булып тордык. Шул вакыт эчендә урыс мәктәпләре аша узган берничә буын үз телен онытты, урыс теле генә төп тел булып калды. Без аларны хәзер маңкортлар дип сүгәбез... Хәлбуки аларның бер гаебе дә юк, киресенчә, туган телдән аерылулары үзләре өчен дә, безнең өчен дә зур фаҗига ул... Бездән туган балалар ич!..” [1:814]

Әдип шул фаҗигадән чыгу юлларын эзли, тәкьдим итеп карый: “Моның өчен туган телебезгә яңадан кайту кирәктер. Ә кайтыр өчен татар балалары һәммәсе дә (100% белән) бары тик ана телендә укый башларга тиеш... Бөтен дөньяда ул шулай – һәр милләт баласы иң элек үз телендә укырга-язарга өйрәнә... Безгә дә шул максатка ирешер өчен, беренче нәүбәттә башлангыч мәктәпләрне тизрәк ачарга һәм аларның саннарын да күбәйтергә кирәк иде. Бу хакта мин «үзгәртеп кору» башлангач та язып чыккан идем. Ләкин ни сәбәптер баштарак моңа юньләп игътибар итүче дә булмады... Ә соңрак инде «нигә башлангыч мәктәп» кенә?” [1:814]Ә.Еники бик гадел рәвештә “адәм баласы укуын университеттан башламый, мәктәпнең беренче сыйныфыннан башлый”, – дип белдерә: «Юк, безгә татар гимназияләре, татар университетлары да кирәк», – дип, бик ялкынланып китүчеләр дә булды... Әмма адәм баласы укуын университеттан башламый, мәктәпнең беренче сыйныфыннан башлый”

Язучы бу проблеманы беренчеләрдән булып күтәрүчеләр рәтендә була: “Шуннан соң 10-15 ел вакыт үтеп китте, ә без туган телебезнең язмышы

турында һаман баш ватудан, бәхәсләшүдән узганыбыз юк... Дөрес, ана телен укытуда шактый ук уңышларга ирештек бугай... «Туган телендә белем алучы татар балаларының саны 20%тан 47%ка кадәр артты» дип белдерә әнә «Мәгърифәт» гәзитәсе. Әмма татар балаларының һәммәсен дә ана телендә укыту башлауга ирешкәнебез юк шикелле әле... Бигрәк тә Казанның үзендә” [1:815].

Милләт хадиме Әмирхан Еники нинди караштa тора соң? “Бу мәсьәләдә мин һаман иске карашымда торам... Мәгәр кайбер яңа тәкъдимнәр дә өстисем килә.

1. Балаларны ана телендә укыта башлау безнең Татарстанда, махсус закон нигезендә, мәҗбүри булырга тиеш. Кабатлап әйтәм, сүз укыта башлау турында гына бара. Ягъни бала үз телендә камил укый-яза белгәнчегә кадәр... Моның өчен дүртьеллык башлангыч мәктәпне тәмамлау җитәчәк. Шуннан соң баланың теләсә нинди телдә укуын дәвам иттерергә хакы булырга тиеш.

2. Татар балаларын урыс мәктәпләренең башлангыч сыйныфларына кабул итми торырга... Иң элек ул татар мәктәбенә барырга тиеш. Аннары урыс телен татар мәктәбендә дә өйрәнәчәкләр. Ләкин беренче класстан ук түгел, яшь балага берме-икеме ел фәкать үз телен генә укыту кирәк.

3. Татар мәктәбе үзенә аерым булырга тиеш... Балаларны чорнаган мохитнең да «татарча» булуы кирәктер, мөгаен... Өч-дүрт урам саен бер башлангыч мәктәп булсын иде... Аңа зур биналар кирәкми, әнә Казанны уратып алган меңнәрчә ике-өч катлы коттеджлар да ярый торгандыр, минемчә... Бу изге эшкә хөкүмәт акча табарга тиеш.

Минем бу тәкъдимнәремдә яңалык юк диярлек. Татарның белемгә юлы ана теленнән башланган. Үзебездәге мәктәп-мәдрәсәләрдән соң, әгәр теләсә, югары белемне чит илләргә барып алган. (Истанбулга, Бәйрутка, Каһирәгә, хәтта Сорбоннага.) Әмма инде туган телен бервакытта да онытмаган. Бу җәһәттән олы шәхесләребезнең белем юлы безгә бик матур үрнәк!..” [1:815]. Ә.Еники карашынча, “татар теленең ролен көчәйтү бик кирәк. Мәсәлән, халыкның 70-80% татарлар гыйбарәт районнарда идарә итү эшләре татар телендә барырга тиеш. Бу бик законлы булачак. Шулай ук дәүләт органнары тарафыннан чыгарылачак һәртөрле карар, законнар да башта татар телендә язылып, соңыннан русчага тәрҗемә ителергә тиеш. Телне эшләтә белергә кирәк. Гамәлдә никадәр күбрәк кулланылса, тел шулкадәр камилләшәчәк” [1:814].

Күргәнебезчә, Әмирхан Еникинең 1998 елда язылган мәкаләсендә яңгыраш алган фикерләр бүген дә актуаль. Туган телне башлангыч сыйныфларда өйрәтү методикасы мәсьәләсенә карашлар төрле югарылыкта даими кузгатыла килә.

**Әдәбият**

Еники Ә.Н.татар баласына урысча белмәү куркыныч янамый //Әсәрләр. 3 томда.– Казан: Татар.китап.нәшр, 2019. – Б.814-815.

# ОРТАКТЮРК ТИЛИ В СОВРЕМЕННОСТИ

Гайнутдинова А.С.
Казанский федеральный университет
alina.gaynutdinova@outlook.com

**Аннотация.** Тюркский язык, распространившийся на столь обширную территорию, несмотря на всевозможные политические и географические различия сохранился до наших дней. Главную роль сыграла добавление определенных суффиксов к неизменным корням в турецком языке и создание новых слов сохраняли общую структуру языка. Есть также несколько различных применений, связанных с различиями во времени и пространстве. Однако эта ситуация не в состоянии повлиять на общую тенденцию. С другой стороны, при определении сходства между диалектами следует принимать во внимание синтаксис, а не фонетические, морфологические, лексические и семантические меры. В результате можно сказать, что тюркский язык широко используется в Европе на обширных территориях вплоть до Великой стены. Потому что в этих местах тюрки обычно живут и говорят на одном языке, но на разных диалектах. После всей этой информации мы можем сказать, что тюрки, говорящие на тюркских диалектах, могут понимать друг друга так или иначе, не говоря уже о пространственных диалектах, таких как якутский, чувашский и караимский. На сегодняшний день есть попытки объединения весь тюркский мир под одним искусственно созданным языком Ортатюрк.
**Ключевые слова:** тюркский язык, ортактюрк тили, алфавит, язык,

Тюркский язык - это язык с глубокими корнями, который под воздействием исторических событий распространился на обширной территории. Тюрки переносили с собой как язык, так и культуру. Таким образом, исторические районы распространения тюркского языка стало гораздо более обширны.

Сегодня тюркский язык используется на обширных территориях начиная от Балкан до Китая, в разной плотности диалектах и наречиях. Несмотря на то, что многие тюрки, проживая в разных районах общаются на разных диалектах, среди их речи можно найти общие точки соприкосновений. Как отмечает известный венгерский ученый Арминий Вамбери: «Человек, говоря по-турецки может легко путешествовать с Балкан до Китая». [1: 25] Если рассматривать вопрос о том, сколько людей говорит на тюркском языке, который разбросан по столь широкой географии и разделен на множество ветвей, сложно назвать точное число. Ведь некоторые тюрки, проживающие в вышеупомянутых регионах, живут как независимые республики, некоторые как автономные республики, а другие продолжают свою жизнь как жители других государств. В связи с чем получить точные цифры довольно сложно. Однако мы можем легко сказать, что общее количество тюрок, проживающих в мире, оценивается более чем в 200 миллионов человек. Таким образом, тюркские языки легко входит в пятерку самых распространенных языков мира.

Исторический фон тюркского языка, в связи с Енисейским камнями, переносятся приблизительно до V-VI века. С другой стороны, если основываться найденными надписи на надгробных камнях (Бенгу), то она датируется VIII веком, где употреблено алфавит Гоктюрк (Орхан). Исходя из данных находок, некоторые лингвисты утверждают, что у такого художественного языка должна быть долгая история. Исследование текста показало, что 67% слов состояло из конкретных, а 33% - из абстрактных. Исходя из этого лингвисты считают, что для существования одной трети абстрактных слов в VIII веке не случайно, и для этого необходимо испытать процесс разработки. [2: 87]

С годами турецкий язык продолжал меняться по отраслям и сущности. Конечно, со временем возникло желание свести эти разные языки к одному. Кто-то предлагает воссоздать язык орхоно-енисейских рун, другие - чагатайский, третьи - язык словаря Махмуда Кашгарского, четвертые требуют введения как общетюркского турецкого, кумыкского, крымскотатарского, узбекского или казахского языков с небольшими доработками или без. Но до недавнего времени никто не начал реализовывать свои идеи. Если бы были разнообразные вариации общетюркского языка, то тюркскому народу было бы из чего выбирать. Однако с 2011 года энтузиасты-волонтеры начали свой проект создание в сети общую литературную норму единого тюркского языка. В этом проекте работают профессионалы, специалисты, люди с высшим образование в других сферах и волонтёры, являющие носителями одного из тюркских языков. Однако имена участников не афишируется. Данный проект находиться в социальной сети Вконтакте в группе «Ortatürk tili | Ортатюрк тили». [4]

Ортатюрк тили является искусственно созданным языком, который целенаправлен для облегчения межтюркского общения. Данный проект был подержен Всемирной ассамблей тюркских народов (ВАТН), в связи с чем был написан их официальный гимн на Ортатюркском языке, который был озвучен на Курултае в 2014 году. [3]

О проекте Ортатюрк тили на главной странице группы Вконтакте можно найти, как детальную информацию о целях, задачах и методах их работ. В части обсуждений и на стене группы можно найти примеры из ортатюркского словаря. Например, пословицы из татарского языка на языке ортатюрк:

1) Yaman xabar uzun ayaqlı; 2) İşke waqıt, oyunğa saat; 3) Baxtsızğa yel qarşı; 4) Bir çeçek bile yaz bolmaz; 5) Duşmanğa ölüm tilegençe, özüñe ömür tile; 6) Dunyada yaxşı kişiler bitmegen (bitmemiş); 7) Yılannıñ aqı da yılan, qarası da yılan; 8) Iraqtağı tuğmuştan yaqındağı dos yaxşıraq; 9) Yelden kelgen yelge ketken; 10) Qartlar sözüni qar basmaz. [4]

Как мы видим для ортатюрского алфавита была выбрана латиница. Естественно в обсуждении мы можем найти вопросы о переходе на тюркские руны, на что дан расширенный ответ о том, что если и будет осуществлен переход, то это будет в модернизированном руническом письме. Причиной тому является не адаптированность классические орхоно-енисейские руны к современному тюркскому языку. [4] В тоже время, если рассмотрим публикации

на стене группы, то увидим размышление о том, что арабская вязь для тюркских языков наиболее подходящая. Далее в обсуждение происходит жаркая дискусия, которая осуществляется между сторонниками разных убеждений. Следовательно выявляется основная причина, по которой и был предпочтена латиница. [4]

В группе также дана и грамматические нюансы, статистика исходя из которого и делается выбор слов. [4] [5] Например: «По данным 100 случайно выбранных слов лидерство по "похожести" на ортатюрк занимает крымскотатарский язык (34% полных совпадений), далее следуют турецкий язык и крымский диалект караимского языка (28% совпадений), у туркменского языка - 27%, кумыкского языка - 25%, у узбекского и кыргызского - по 24%, у уйгурского - 23%, у казахского - 22%, у ногайского и карачаево-балкарского - по 19%, у каракалпакского и азербайджанского - по 15%, у алтайского и урумского -по 14%, у татарского и гагаузского - по 13%, у чагайтайского - 12%, у лексики "Древнетюркского словаря" и старо-османского языка - по 11%, у хакасского, телеутского, шорского, крымчакского языков и тракайского и луцко-галичского диалектов караимского языка - по 10%, по 9% у башкирского и средне-кыпчакского языка, у саха (якутского) и армяно-кыпчакского - по 8%, у тувинского - 7%, у древне-уйгурского - 6%, у сарыг-югурского и тофаларского - по 5% полных совпадений, у чулымского, хорезмско-тюркского (староузбекского), древнекыпчакского - по 4%, у чувашского и средне-уйгурского - по 3%, у саларского, сибирско-татарского, долганского языков и языка фуюйских кыргызов - по 2% полных совпадений, у халаджского и орхоно-енисейского - по 1% полных совпадений.» [4]

По завершении данного проекта планировалась выпуск учебника и словаря ортатюрка. В группе указано, что автор уже завершил проект, следовательно либо идут доработки, либо идут сборы средств для выпуска трудов. [4]

В просторах интернета можно найти и другие группы в социальных сетях, которые также предлагают создать Ортатюрк, некоторые в своей группе активно делают публикации используя руническую письменность, некоторые же используют лишь латиницу. Есть также группы, которые также предлагают создать Ортатюрк с использованием методом математической и компьютерной лингвистики [6]. Дата создания группы в Файсбук намного (3 мая 2016 года) позднее группы в Вконтакте (6 августа 2013). Также можно заметить, что в группе Файсбук 4,7 тыс. участников, а в Вконтакте подписчиков 1308. Дальнейшее же исследование показало, что обе группы осведомлены о существование своих единомышленников.

В исследовании было замечено, что в общественном мнение есть группа людей, которые стремляться не создавать, а перенять свой язык, так как этот язык является наиболее активно-употребляемом в народе. Однако в этом варианте имеется ряд недостатков. Если выбрать один национальный язык, то теряется равноправие языков и наций. Все будут вынуждены изучать данный язык, таким образом народ будет тратить на это слишком много времени. Данный вариант естественно будет потери толерантных отношений остальной

части тюркского мира к этой группе. Если рассмотреть, создание общего искусственного тюркского языка, то можно увидеть на подобии него уже созданный в других языках, например на славянском или же на мировой жестовой язык. Второй уже употребляется на международных конференциях и семинарах. Если же рассмотреть тюркские языки, то у каждого языка можно найти общие точки соприкосновения, о которые либо забыты, либо уже не употребляется. Например, если возьмем слово «в прошлом году», которое на татарском звучит как «узган ел» или «былтыр», то в турецком языке «geçen sene» или «bıldır». Суммируя все вышесказанное можно выдвинуть идею того, что нужно изначально тюркским народам изучить свои языки со всеми синонимами и словами, которые уже вышли из употребления. В таком случае Ортатюркский язык может быть и не будет казаться таким отдаленным от своего родного языка.

**Литература**


1. Banarlı Nihad Sami. Türkçenin sırları, İstanbul: Kubbealtı Neşriyatı, 1999. c. 317.
2. Doğan Aksan. Anlambilimi ve Türk anlambilimi (Ana Çizgileriyle). Ankara: DTCF yay., 1987. c. 199.
3. Вконтакте. Ortatürk tili | Ортатюрк тили. (электронный ресурс). // https://vk.com/ortaturkce (дата просмотра 30.01.2021).
4. Онлайн словарь Glosbe. (электронный ресурс). // https://ru.glosbe.com/tr/mis_ort (дата просмотра 30.01.2021).
5. Файсбук. Ortaturk tili - Язык ортатюрк - The language Ortaturk. (электронный ресурс). // https://www.facebook.com/groups/117660641973811/ (дата просмотра 30.01.2021).

# БАШЛАНГЫЧ СЫЙНЫФ УКУЧЫЛАРЫНДА ЭТНОМӘДӘНИ КОМПЕТЕНЦИЯ ФОРМАЛАШТЫРУ ЮЛЛАРЫ

Гайсина Р.С.
Алабуга шәһәренең 6 нчы номерлы мәктәбе
gaisina1972@inbox.ru

**Аннотация.** Статья посвящается описанию способов формирования этнокультурной компетенции у учащихся младших классов. Дается краткий обзор этнокультурного материала в современных учебниках татарского языка для начальных классов русскоязычных школ.
**Ключевые слова.** Этнокультурная компетенция, начальная школа, учебники.

Шәхеснең күпчелек сыйфатлары тәсле үк, этномәдәни компетенция дә тумыштан килгән характеристика түгел, ул тәрбия һәм белем бирү процессында формалаша. Заманча педагогик тикшеренүләрдә башлангыч мәктәп яшендә, урта һәм югары сыйныфларда этномәдәни компетенция формалаштыру факторларын, шартларын, методларын, чараларын өйрәнүгә шактый игътибар бирелгән.

Безнең карашыбызча, әлеге компетенция формалаштыруны башлангыч мәктәптән алып югары сыйныфкача һәр этапта да индивидуаль үзенчәлекләргә ия өзлексез процесс буларак карау максатка ярашлы.

Галимнәрнең хезмәтләрендә еш кына башлангыч сыйныф укучылары белән тәрбия эше алып баруның нәтиҗәлелеге ассызыклана. Мәсәлән, Р.А. Лахин болай дип яза: «кече мәктәп яшендәге бала организмының функциональ, психо-эмоциональ, интеллектуаль, әхлакый сфераларының үсеш процессында булуы тәрбия эшендәге уңышларга ирешүдә зур мөмкинлекләр бирә» [1: 18]. Димәк, башлангыч сыйныфта уку чоры этномәдәни компетенция формалаштыру өчен дә уңышлы вакыт булып санала.

Хәзерге вакытта мәктәпләрдә тормышка ашырыла торган тәрбияви процесс, күпсанлы традицион һәм инновацион алым һәм чаралардан файдаланып, нәтиҗәлелекне арттыру мөмкинлегенә ия. Әмма башлангыч сыйныф укучылары белән эшләүдә иң нәтиҗәле алым – уен, уен технологиясенә нигезләнгән алымнар. Теләсә кайсы халыкның тарихи үсешендә үсеп килүче буынны олы тормышка әзерләү, тәрбияләү чарасы буларак иң элек уен кулланыла. Хәзерге вакытта да галимнәр, халык уенының тәрбия чарасы буларак потенциалы турында сөйләгәндә, «уен аркылы иҗтимагый әһәмиятле сыйфатлар һәм күзаллаулар формалаша, әхлакый гамәлләргә сәләтлелек үстерелә, үз-үзеңне тоту культурасы тәртипкә салына. Индивидуаль һәм күмәк уеннар вакытында балада дисциплинарлык, оешканлык, социаль-әхлакый нормаларны үтәүгә сәләтлелек кебек сыйфатлар ачыла», – дип язалар [1: 21]. Р.А. Лахин хәрәкәтле халык уеннары аркылы балада этномәдәни компетенциянең формалашуын эксперименталь рәвештә дәлилли, аеруча этномәдәни компетенциянең эмоциональ-мотивацион

компонентында уңай үзгәрешләр хасил булганын ассызыклый [1: 22]. Чынлап та, башлангыч сыйныф укучыларына этномәдәни компетенциянең әһәмияте турында чыгышлар ясау формальлек буларак кабул ителә ала, ә менә сыйныф белән, шау-гөр килеп, халыкта гасырлар буена сакланып килгән, балалар тарафыннан яратып уйналган уеннарны оештыру күпкә нәтиҗәлерәк. Татар балалар фольклоры бу яктан бай уен фондына ия. Мәсәлән, башлангыч сыйныф укучыларының яшь үзенчәлекләренә туры килә торган «Борчак чәчеш», «Каравылчылар һәм куяннар», «Бау сикереш», «Токмач», «Җиз бүкән», «Алпавытың өйдәме?», «Син йөгер» уеннары һ.б. Уеннарның кагыйдәләре Р.Ягъфәров хезмәтендә бирелгән [8].

Башлангыч сыйныф укучылары белән эшләгәндә, күмәк иҗади эшләрнең тәрбияви мөмкинлекләрен истә тотарга кирәк. Мәсәлән, этномәдәни компетенция формалаштыруны максат итеп куйган очракта, башлангыч сыйныф укучылары белән викториналар үткәрергә мөмкин. Галимнәр шулай ук башлангыч сыйныф укучылары белән әңгәмәләр уздыруның әһәмиятен дә ассызыклыйлар [3: 32]. Мондый чараларның төп максаты – укучылар өчен аңлаешлы формада этномәдәни компетенция турында төшенчә бирү, этномәдәни тәҗрибәне аңларга һәм гомумиләштерергә ярдәм итү. Һәр әңгәмә бер конкрет темага багышланырга тиеш, теманың балалар өчен кызыклы булуы, проблемалы булуы шарт. Әмма, укытучы шунысын да онытмаска тиеш: педагогика фәнендә әңгәмәләр башка алым һәм чаралар белән берлектә үткәрелгәндә генә уңай нәтиҗә бирәләр, дигән фикер таралган [3: 37]. Шуңа күрә, аларны видео карау, бирем эшләү, проблемалы ситуацияне чишү, анкета үткәрү һ.б.лар белән үреп барырга кирәк. Әйтик, балаларның яшь үзенчәлекләренә туры килә торган видеоматериал тәкъдим итәргә мөмкин. Соңгы елларда электрон дәреслекләр, гомумән, интернет-ресурслар, CD-дисклар татар телендә эшләнгән сыйфатлы мультфильмнар белән баеды. «Туган тел», «Кызыклы шәкерт», «Шаян песи», «Ак бабай», «Кырлай», «Туган авыл», «Чукмар белән Тукмар», «Камыр батыр», «Өч кыз» әсәрләре буенча төшерелгән мультфильмнар татар халкының яшәү рәвеше, милли киемнәр, милли ризыклар турында мәгълүмат бирүдә зур роль уйныйлар, классик җырчылар башкаруындагы җыр белән үрелеп биреләләр. Боларны карау укучыларда милли үзаң, милли горурлык һәм Татарстан халкы белән соклану тәрбияли, «Ак барс» мультфильмы дәүләт символикасына хөрмәтле караш формалаштыра.

Татарстан Республикасы – күпмилләтле республика. Татарлар һәм руслар анда халык саны ягыннан әйдәп баручылар рәтендә. Шуңа күрә этнәмәдәни кыйммәткә ия булган мәгълүмат, нигездә, шушы ике халыкның матди һәм рухи мәдәниятенә карый. Татарстанда яшәүче халыкларның этномәдәнияте белән таныштыру дәреслектәге текстлар аша тормышка ашырыла. Укучылар төрле татар һәм рус халык әкиятләре, мәкальләре белән танышалар. Әлбәттә, предмет үзенчәлекләренә һәм өйрәнү объектына бәйле рәвештә, иң зур урынны татар халык авыз иҗаты үрнәкләре алып тора. Һәр сыйныфта да дәреслекләрдә тизәйткеч, мәкаль, әйтем, табышмак, әкият кебек жанрга караган әсәрләр яки

алардан өземтәләр бирелә. Шулай ук рус фольклоры үрнәкләре дә дәреслекләрдә урын ала. Мисал өчен, икенче сыйныфта «Шалкан» әкиятеннән өзек бирелә, әкиятне дәвам итеп сөйләргә кушыла һәм аннары грамматик бирем башкарыла [5: 108]. Татар халкы мәдәнияте үсешенә өлеш керткән, тарихыбызда зур урын алган шәхесләрдән дәреслекләрдә Абдулла Алиш әкиятләреннән [7: 96], Сибгат Хәким шигырьләреннән өзекләр [6: 28] бирелә. Рус мәдәнияте үсешенә өлеш керткән шәхесләрдән К.Ушинский [6: 27], Л.Толстой [7: 91], А.Куприн әсәрләре кертелә [4: 48-49], И.Шишкин турында мәгълүмат бирелә [7: 76].

Этномәдәният милләтнең, халыкның әхлакый кыйммәтләрен, дөньяга карашын да үз эченә ала. Күзәтүебез күрсәткәнчә, дәреслекләрдә дә, тәкъдим ителә торган мультимедиа әсбапларда да татар халкының сабыр, башка милләтләр белән дус-тату мөнәсбәттә яши белүенә басым ясала. Гомумән, төбәгебез халыклар дуслыгы хакимлек иткән урын буларак тасвирлана. Төрле грамматик темаларны өйрәнгәндә тәкъдим ителә торган текстлар моңа дәлил булып тора. Мәсәлән, өченче сыйныфта «Килеш кушымчалары» темасын өйрәнгәндә, «Tatarschool» сайтында «тыңлап аңлау» рубрикасындагы текстны карап китик: «Безнең илебез – дуслык иле. Әлмәттә күп төрле милләт кешеләре яши. Анда Әзербайҗаннан атаклы нефтьчеләр килде. Башкортостанның оста нефтьчеләре дә үз эшен күрсәтте. Шулай ук Уралдан, Мәскәүдән һәм башка җирләрдән Татарстанга күп эшчеләр ярдәм итте» [2]. Еш булмаса да, дәреслекләрдә Татарстанда яшәүче халыкларның танылган шагыйрьләре әсәрләреннән өзекләр кертелә. Мисал өчен, дүртенче сыйныфта чуаш халык шагыйре Пётр Хузангайның «Туган Татарстанга» шигыреннән өзек бирелә [6: 29]. Әмма Татарстанда яшәүче башка халык йолалары, гадәтләре, халык авыз иҗаты белән таныштыру буенча эш дәреслекләрдә юк дәрәҗәсендә дип әйтер идек. Шуны истә тотып, укытучы үзе дә өстәмә эзләнүләр алып барырга, табышларын укучыларга тәкъдим итәргә тиеш, дип уйлыйбыз. Әлбәттә, бу эш укучыларның яшь үзенчәлекләрен истә тотып башкарылырга тиеш. Мисал өчен, өченче сыйныфта сабан туе бәйрәме турындагы текст [7: 109] укылгач, биремнәр эшләнгәч, укытучы удмуртларның Гырон быдтон бәйрәме белән таныштыра ала.

Гомуми нәтиҗә ясап, шуны искәртергә мөмкин: укучыларда этномәдәни компетенция формалаштыру юллары төрле: укытучы заманча технологияләрдән файдаланып, шулай ук иҗади фикер йөртеп, тематик уеннар тәкъдим итә ала, төрле халык йолаларын чагыштыру эше оештырылырга да мөмкин, әмма төп таяныч – әлбәттә, дәреслек.

**Әдәбият**

1. Лахин Р.А. Народная игра как средство социально-нравственного воспитания младших школьников и подростков (на материале традиционных игровых практик Кубани): дис. … канд. пед. наук. – Курск, 2009. – 251 с.

2. Татар теле. Tatarschool. – URL: http://tatarschool.ru/media/tth3; (мөрәҗәгать итү вакыты: 10.04.2020).

3. Тигунцова Г.Н., Федосова И.В. Формы воспитательной работы в начальной школе: учебно-методическое пособие. – Иркутск: ИГПУ, 2005. – 123 с.

4. Харисов Ф.Ф., Сиразиева Г.Д. Татар теле. Рус телендә башлангыч белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 1 нче с-ф. – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2017. – 71 б.

5. Харисов Ф.Ф., Харисова Ч.М., Панова Е.А. Татар теле. Рус телендә башлангыч белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 2 нче с-ф. – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2017. – 143 б.

6. Харисов Ф.Ф., Харисова Ч.М., Сәгъдиева Р.К., Гарипова В.А. Татар теле. Рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 4 с-ф. – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2017. – 183 б.

7. Харисов Ф.Ф., Шакирова Г.Р., Сәгъдиева Р.К., Хисмәтова Л.К. Татар теле. Рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 3 с-ф. – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2017. – 159 б.

8. Ягъфәров Р.Ф. Уен – күңел бәйрәме. Татар халкының күңел бәйрәме. – Казан: Мәгариф, 2009. – 159 б.

# РУСКИЕ ФРАЗЕОЛОГИЗМЫ КАК СРЕДСТВО ФОРМИРОВАНИЯ КОММУНИКАТИВНОЙ КОМПЕТЕНЦИИ УЧАЩИХСЯ 7-8 КЛАССОВ

Галиева Л. А.
Башкирский педагогический университет им М. Акмуллы
liliyagalieva160316@gmail.com

**Аннотация.** Статья представляет собой анализ формирования коммуникативной компетенции школьников при помощи фразеологии. Рассматриваются наиболее актуальные и применимые на уроках русского языка задания, а позже, на основе их анализа, составляется классификация заданий на формирование коммуникативной компетенции учащихся 7-8 классов.
**Ключевые слова:** фразеологизм, коммуникативная компетенция, учащиеся, задания.

Фразеология в школьном курсе русского языка имеет большой образовательный, развивающий и воспитательный потенциал. Русский язык как средство получения знаний в разных областях науки в наше время выходит на метапредметный уровень, и фразеология, как его неотъемлемый компонент, играет весомую роль в этом процессе. Поэтому важно отметить, что одна из главных задач педагога - показать учащимся широкую сферу функционирования в речи устойчивых языковых словосочетаний.

Фразеологизмы способствуют формированию коммуникативной компетенции учащихся, так как, во-первых, они отражают богатый исторический опыт народа, его материальную и духовную культуру, а, во-вторых, фразеологизм, благодаря своей экспрессивно-стилистической окраске, обладает большей выразительностью по сравнению со словом. Данный раздел русского языка может оптимизировать формирование коммуникативной компетенции учащихся, а также повысить филологическую культуру школьников.

Основные понятия и задачи фразеологии впервые были определены В. В. Виноградовым. Он описал основные типы фразеологизмов, наметил границы объекта изучения фразеологии. В школе этот раздел русского языка изучается с 1970 года. Её включение в качестве самостоятельного раздела в школьную программу по русскому языку повысило познавательно-практическую направленность курса, способствовало развитию интереса учащихся к русскому языку как к учебному предмету. При этом стоит отметить, что до сих пор ведутся споры о границе фразеологии как таковой, существует множество подходов к определению фразеологизма. Так, В. П. Жуков считает, что «фразеология представляет собой особый раздел лингвистики, в котором изучаются семантические, морфолого-синтаксические и стилистические особенности фразеологизмов», а основными признаками фразеологизма он считает идиоматичность, устойчивость, раздельнооформленностъ, то есть внешнюю расчлененность фразеологизма на словесные компоненты. В то же

время исследователь А. М. Бабкин относит к признакам фразеологизмов устойчивость сочетания слов, смысловую целостность, переносное значение, экспрессивно-эмоциональную выразительность. Кроме того другими исследователями выделяются следующие признаки фразеологизма: мотивированность устойчивого оборота, способность создания ярких художественных образов и другое. Подводя небольшой итог, заметим, что в современной лингвистике сложилось несколько точек зрения на предмет фразеологии:

1. Расширенное понимание фразеологии (С. И. Ожегов, В. Л. Архангельский, А. В. Кунин и др.): включают в ее состав все словосочетания, обладающие признаками устойчивости.
2. Узкое понимание фразеологии (А. М. Бабкин, Ю. А. Гвоздарев и др.): включают в нее только номинативные единицы, функционально соотносимые со словом.
3. Направление, понимающее под предметом фразеологии все сочетания лексем (М. М. Копыленко, З. Д. Попова и др.).

При этом большинство современных исследователей сосредоточивают свое внимание на типизации лексических единиц и особенностях их появления с точки зрения семантики непроизводных слов, образующих фразеологическое единство, а также ее изменения внутри неразрывного словосочетания. Стоит отметить, что данные исследования в большинстве своем направлены на рассмотрение общих типов как лексических, так и фразеологических единиц, на их характеристику с точки зрения контекстно-исторического и литературного пласта в зависимости от источника данной единицы. Мы же сосредоточимся на процессе формирования коммуникативной компетенции у учеников 7-8 классов при помощи изучения фразеологии.

В педагогических исследованиях отмечен тот факт, что в современном образовательном процессе школ действует система форм и методов работы, обеспечивающих достижение высоких результатов сформированности умений и навыков коммуникативной компетентности среди учащихся. Независимо от широкого спектра исследований проблем формирования коммуникативной компетентности, не существует однозначного определения данного феномена. В любом случае, она является многокомпонентным образованием, которое соединяет в себе когнитивный, эмоциональный и поведенческий компоненты. Сама же методическая система обучения фразеологии является элементом систем развития речи, потому что обеспечивает связь тематики фразеологизмов с темами по развитию речи. При данном подходе создаются условия для использования детьми усвоенных фразеологизмов в собственной речи, в создаваемых текстах.

Грамотность и культура речи является важным компонентом приобщения учеников к языку, который постигается им в историческом и современном аспектах. Раздел фразеологии при этом не только явно отражает историю русского языка, но и показывает современные тенденции его развития, поэтому на уроках важно рассматривать оба аспекта: исторический и современный.

Формирование коммуникативной компетенции при этом происходит при изучении трех типов фразеологических единиц: архаических, исторических и новых. Наше исследование было направлено на создание классификации заданий по фразеологии для учеников 7-8 классов с учетом вышеперечисленных тенденций и возможностей, а также их влиянием на формирование коммуникативной компетенции.

Перед тем, как представить свою классификацию заданий, приведем две классификации, на которые опиралось наше исследование. Во-первых, это классификация по методу Т. А. Ладыженской. В учебной программе данных авторов выделяются четыре направления усвоения знаний по фразеологии: формирование теоретической базы, развитие умения отличать фразеологизм от свободных сочетаний слов, умения находить фразеологические единицы, умения подбирать синонимы-фразеологизмы. В рамках данных направлений предлагаются такие типы заданий, как:

1) задания, направленные на формирование навыка поиска информации;
2) задания, направленные на формирование умения выявлять ФЕ в тексте;
3) задания, направленные на формирование умения давать толкование ФЕ;
4) задания, направленные на формирование умения подбирать синоним к фразеологизму;
5) задания, направленные на формирование умения различать ФЕ и свободные сочетания слов;
6) задания, направленные на формирование навыков словарной работы с ФЕ;
7) задания, направленные на формирование умения создавать новый текст и на его основе производить пересказ и другие.

Во-вторых, это классификация по методу Г. В. Михеевой. При разделении заданий на типы исследователь исходит непосредственно из цели формирования коммуникативной компетенции учащихся. Выделяются два коммуникативных составляющих: умение обосновать необходимость и уместность фразеологических единиц в речи, а также их грамотное употребление с учетом функций и изобразительных свойств фразеологизмов. На основе этого автор делает вывод о введении двух типов заданий: задания, направленные на формирование умений писать сочинение по фразеологизму и умения создавать эмоциональную окраску высказывания.

Итогом анализа вышеперечисленных классификаций стало создание 13 типов заданий, которые могут быть эффективны в систематическом использовании на уроках русского языка:

1. Направленные на умение выделять фразеологические единицы в тексте.
2. Направленные на умение давать толкование фразеологизмам.
3. Направленные на умение различать фразеологические единицы и свободные словосочетания.

4. Направленные на решение коммуникативно-ситуативных задач по поставленной проблеме.

5. Направленные на формирование умения создавать новый текст и на его основе производить пересказ.

6. Направленные на формирование навыка поиска информации о фразеологизме при помощи словарей.

7. Направленные на формирование навыка поиска нескольких вариантов разрешения ситуации и умения подбирать синонимы к фразеологизмам.

8. Направленные на формирование умения соотносить фразеологические единицы и их синонимы.

9. Направленные на формирование умения сочинять историю.

10. Направленные на формирование умения рассуждать на поставленную тему.

11. Направленные на формирование умения давать эмоциональную оценку.

12. Направленные на формирование умения работать в коллективе.

13. Направленные на формирование коммуникации между учителем и учениками.

## Литература


1. Автономова С. И. К вопросу о системе работы по фразеологии в школе // Актуальные проблемы русской фразеологии: Межвузовский сборник научн. трудов / С. И. Автономова. – Л., 1983. – 132 с.

2. Антонова Л. В. Большой фразеологический словарь русского языка / Л. В. Антонова. – М.: Дом Славянской книги, 2010. – 928 с.

3. Архангельский В. Л. Устойчивые фразы в современном русском языке / В. Л. Архангельский. – Ростов н/Д.: Рост. ун-та, 1964. – 315 с.

4. Бабайцева В. В. Русский язык: теория, 5-11 кл. : учеб. для учеб. заведений с углубл. изуч. рус. яз. / В. В. Бабайцева. – М.: Дрофа, 1998. – 431 с.

5. Бабкин А. М. Лексикографическая разработка русской фразеологии / А. М. Бабкин. –Ленинград: Наука, 1970. – 76 с.

6. Балли Ш. Французская стилистика / пер. с фр. – 2-е изд., стереотипное / Ш. Балли. – М.: Эдиториал УРСС, 2001. – 392 с.

7. Баранов М. Т. Методика лексики и фразеологии на уроках русского языка: Пособие для учителя / М. Т. Баранов. – М.: Просвещение, 1988. – 190 с.

8. Баранов М. Т. Русский язык: Справочные материалы: Учеб. пособие для учащихся / М. Т. Баранов, Т.А. Костяева, А. В. Прудникова; Под ред. Н.М. Шанского. М.: Просвещение, 1993. – 287 с.

9. Виноградов В. В. Русский язык. Грамматическое учение о слове / В. В. Виноградов. – М.: Высш. шк.,1986. – 639с.

10. Воробьева Т. А. Изучение фразеологии в школе / Т. А. Воробьева. – Минск: БНТУ, 2017. – 324 с.

11. Гвоздарев Ю. А. Основы русского фразообразования / Ю. А. Гвоздарев. – Ростов н/Д.: Рост. ун-та, 1977. – 184 с.

12. Жуков В. П. Русская фразеология / В. П. Жуков. – М.: Высш. шк., 1986. – 309 с.

13. Клюева Г. Ю. Методика обучения лексике и фразеологии в культуроведческомаспекте: 5-6 класс / Г. Ю. Клюева. – М.: МПГУ, 2009. – 244 с.

14. Ладыженская Т. А. Развитие речи учащихся / Т. А. Ладыженская. – М.: Учпедгиз, 1960. – 135 с.

15. Ларин Б. А. История русского языка и общее языкознание / Б. А. Ларин. – М.: Просвещение, 1977. – 224 с.

16. Михеева Г. В. Теоретические и методические основы обучения региональной фразеологии / Г. В. Михеева. – Архангельск: КИРА, 2012. – 142 с.

17. Молотков А. И. Фразеологический словарь русского языка / А. И. Молотков. – М.: Советская энциклопедия, 1968. – 538 с.

# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ УҢАЙ МОТИВАЦИЯ ТУДЫРУ – БЕЛЕМ СЫЙФАТЫН АРТТЫРУ ЧАРАЛАРЫНЫҢ БЕРСЕ

Галиева Р.Т.
МАОУ «СОШ №20» ГО г. Стерлитамак
*rimma7709@rambler.ru*

**Аннотация.** В данной статье анализируется роль мотивации в системе образования в общем, и в частности, на уроках родного языка и литературы. Даются практические рекомендации по формированию и повышению мотивации у обучающихся.
**Ключевые слова:** мотивация, урок, познавательная активность, инновационные технологии.

Белем алуга мотивация хәзерге заманда һичшиксез үзәк мәсьәлә булып тора. Ни өчен уку чорында укучыларда белеем алуга мотивация кими соң? Барлык балалар да мәктәпкә укырга дип киләләр һәм укырга телиләр. Тора-бара балалар белән нәрсә була, нигә бала өчен уку процессы авыр йөккә, кызыксыз эшкә әйләнә? Моңа кем гаепле, нишләргә? Иң мөһиме: белем алуга кызыксынучанлыкны ничек арттырырга?

Әлбәттә, баланың белемгә омтылышы һәм кызыксынуы белеем эчтәлегенә бәйле булуын беркем дә инкарь итми. Укучыларда уңай мотивациянең кимүе бүгенге көнгә кадәр актуаль проблема булып кала. Мотивациянең кимүе бигрәк тә яшүсмер вакытта күзәтелә.

Бу проблеманы хәл итүдә укытучы өчен иң мөһим бурыч булып укучыларны белем алуда төрле эшчәнлек төрләрен үзләштерүгә өйрәтү, фәнгә карата кызыксынучанлыкларын арттыру тора.

Укытучының заманча шартларга нигезләнеп эшләнгән нәтиҗәле алымнарын татар телен уку-укыту процессында дөрес куллана белүе, укучыларда фәнгә карата уңай мотивация тудыра алуы – шундый таләпләрнең берсе.

Әлеге проблеманы чишүдә рус һәм татар телләрен укыту методикасы фәнендә әйдәп баручы галимнәрнең – Е. Литневская, В. Багрянцева, Е. Пассов, М. Зайцева, Ф. Вәлиева, Г. Саттаровның хезмәтләренә; Г. Муравьева, А. Панфилов, Н. Саттарова, С. Вәгыйзов, Р. Хәйдәрова, Н. Шәймәрданова, К. Фәтхуллова, С. Айдарова кебек авторларның тел дәресләрен заманча шартларда яңа технологияләр, методлар белән укыту тәҗрибәсе буенча язылган хезмәтләренә таяну мөһим.

Мотивация барлык укытучылар өчен дә катлаулы проблема булып тора. Укучының укуга иң югары мотивациясе – фәнгә карата ихтыяҗы, кызыксынучанлыгы. Россия психологларының әйтүләре буенча, укучының интеллектуаль активлыгына аның кызыксынучанлыгы юнәлеш бирә, чөнки ул игътибарлылык һәм фикерләү дәрәҗәсенә йогынты ясый. Мотив (француз сүзе

– *motif*) – теләк тудыру, сәбәп булу; латин телендә – хәрәкәткә китерү, этәрү. Мотивация – кешене төп эшчәнлеккә этәрүче мотивлар җыелмасы.

Педагогика фәне бу төшенчәгә түбәндәгечә аңлатма бирә:

Мотивация – укучыларны танып белү эшчәнлегенә, белем эчтәлеген актив үзләштерүгә этәрә торган эшчәнлек төрләре, ысуллары һәм чаралары

Укуга мотивация – укучылар тарафыннан укуда максатка ирешү өчен күрсәтелә торган активлык. Укучылар өчен түбәндәге мотивлар (ихтыяҗлар) әһәмиятле һәм кирәкле исәпләнә:

- Танып-белү;
- коммуникатив;
- эмоциональ;
- үзүсеш;
- укучы позициясе;
- уңышка ирешү;
- тышкы (мактау, шелтә).

Белемгә мотивациянең үзенчәлеге шунда, эшчәнлек процессында укучы белемнәр үзләштерә һәм шәхес буларак формалаша. Уңышлы белеем бирүнең төп шартларының берсе укуга ихтыяҗ тудыру икәнлегедә дәлилләнгән.

Бу эштә укытучы тарафыннан түбәндәгеләрне исәпкә алынуы кирәк:

- укучыларның яшьүзенчәлекләрен исәпкә алу;
- укучыларның мөмкинлекләрен исәпкә алган эш төрләре куллану;
- максатка ирешүдә эш алымнарын укучы белән бергәләп сайлау;
- парларда, төркемнәрдә эшләү эш алымнарын куллану;
- мультимедиа, электрон ресурслар, презентацияләр һ.б. файдалану;
- уен элементларын кертү;
- дәрес бирүнең традицион булмаган формаларын куллану;
- үзара хезмәттәшлек һәм аңлашу атмосферасы тудыру;
- уңышка ирешүситуациясе тудыру;
- укытучының укучы мөмкинлекләренә ышануы;
- укучыны кечкенә генә уңышлары өчен дә мактау;
- укучыларны үз эшчәнлекләрен дөрес бәяли белергә өйрәтү;
- укытучының эмоциональ сөйләме.

Мәктәпнең төп укыту формасы – дәрес. Дәрес, анны планлаштыру һәм үткәрү – бу укытуның һәр көнне аңлап, уйлап башкара торган эше. Дәрес – ул укытучының шәхси һәм һөнәри “көзгесе”, иҗади остаханәсе. Һәрбер дәрестә укытучының педагогик системасын һәм нәтиҗәләрен күрергә була. Дәрестә яңача ачышлар туа, экспериментлар үткәрелә, проблемалар чишелә, хаталар ачыклана, иҗади эзләнүләр алып барыла, уңышлы нәтиҗәләр ясала.

Дәрес ул – укучы өчен үсеш вакыты: кызыклы һәм мавыктыргыч “Белем дөньясына” сәяхәт итү, фән баскычларыннан биеклекләргә менү, аның серле һәм таныш булмаган сукмакларыннан бару. Укытучы һәр дәресенә зур әзерлек белән керә, кечкенә шәхесләрнең интеллектуаль, социаль, психик, физик һәм рухи сфераларын үстерүгә зур көч куя һәм махсус шартлар булдыра.

Дәрес ул – шәхси һәм социаль тормышның бер мизгеле һәм күренеше. Дәрес процесс буларак, ул – диалог, аралашу, шәхесара төрле мөнәсәбәтләргә керү, эшчәнлек башкару. Дәрес никадәр җанлы һәм кызыклы – укучыда фәнгә карата уңай мотивация шулкадәр югары.

Дәрес структурасын күзаллау, төзү бу очракта укытучыдан шактый иҗадилык таләп итә. Укытучыга дәрес структурасы буенча төгәл күрсәтмә юк. Ул Федераль дәүләт гомуми белем бирү стандартында күтәрелгән мөһим таләпләрне исәпкә алып, дәрес структурасын үзе төзи. Әмма бер дәрес кысасында укытучы нинди нәтиҗәләргә ничек ирешәсен ачык күзалларга тиеш. Укучыга нәтиҗәле белем алу өчен эффектив ысуллар кулланып, уңай шартлар булдыру – укытучының бурычы һәм шул ук вакытта һөнәри осталыгын күрсәтү мөмкинлеген бирүче чара.

Укучыларның танып-белү эшчәнлеген активлаштыру һәм укучыларда уңай мотивация булдыру дәреснең һәр этабында тормышка ашырылырга тиеш.

Укучыларны кызыксындыруны тәэмин итә торган кайбер нәтиҗәле алымнарга күзәтү ясап китик.

1. Оештыру, ягъни мотивлаштыру өлеше. Дәресне төрле мотивацион чаралар ярдәмендә башлап җибәрү. Мәсәлән, уңай халәт тудырырга ярдәм итә торган шигырь сөйләү, табышмаклар әйтү, бер-береңә матур сүзләр әйтешү, теләкләр, яхшы кәеф теләү, укучыларга исемнәре белән эндәшү, мактау сүзләре.

2. Уку материалын аңлатканда:

– сүз белән эшләү алымнары (сөйләү, сүзлек эше, әңгәмә, һ.б.);

– практик алымнар (күнегүләр, буклетлар, презентацияләр эшләү, электрон дәреслекләр куллану).

3. Фикерләү, уку эшчәнлеге белән идарә иткәндә: проблемалы эзләнү методы (проблемалы сорау кую, проблемалы ситуация тудыру, парлы, группаларда эшләү, фәнни-тикшеренү эшләре).

Дәрестә дә, өй эше итеп тә эзләнү, тикшеренү, уйлану таләп иткән эшләр бирү нәтиҗәле.

4. Уку эшчәнлеген активлаштыру өчен дәресләрдә эмоциональлеккә ирешү, танып-белү уеннары, уңыш ситуациясе булдыру, үзара ярдәм оештыру бик отышлы алым була.

5. Өйгә эш бирү индивидуаль яки дифференциаль якын килүне сорый. Мәктәп баласы мәҗбүри итеп бирелгән өй эшен бик яратмый. Кимендә өч вариантта бирелгән һәм сайлап алу мөмкинлеге булган эш теләп башкарыла. Бигрәк тә иҗади биремнәргә укучы җаваплырак карый.

Компьютер, интерактив такта куллану дәресләрне тагы да мавыктыргыч, нәтиҗәле итәргә ярдәм итә. Интерактив такта белән эшләүче укытучы һәрвакыт укучыларның игътибар үзәгендә, сыйныф белән элемтәдә тора. Бу алым укучыларның белем сыйфатын үстерергә, яңа материалны һәр балага җиңел, аңлаешлы итеп җиткерергә дә ярдәм итә.

Шулай ук татар теле дәресләрендә интернет-ресурсларны куллану уку, язу күнекмәләрен булдыру һәм үстерү, кирәкле материал табу, укучыларның сүзлек

запасын баету, татар телен өйрәнүгә мотив формалаштыру кебек дидактик бурычларны үтәргә мөмкинлек бирә.

Яңа технологияләр ярдәмендә телне өйрәнү укучыны тагын да активлаштыра, мөстәкыйльлек тәрбияли, фәнне югары дәрәҗәдә үзләштерү, максатка омтылучанлык, информацион технологияләр дөньясында яңалыклар белән кызыксыну теләге уята.

Тел дәресләрендә проектлар методын куллану отышлы, чөнки проект эше – ул ниндидер идея, фикер өстендә, җентекле планлаштырылып, эзлекле эшләү һәм эш азагында күзгә күренерлек нәтиҗә чыгару, билгеле бер тема буенча информацияне бер схемада күрсәтү. Проектлар методы укучы шәхесенең белем алуга иҗади якын килүенә юнәлтелгән. Ул, теге яки бу проблеманы тирәнтен өйрәнү максатында, укытучы җитәкчелегендә эшләнә торган мөстәкыйль иҗади эш. Укучы күзлегеннән караганда, проект ул – үзең яисә төркем белән кызыклы нәрсә дә булса эшләп карау мөмкинлеге. Татар теле дәресләрендә укучылар проектлар эшлиләр: “Сүз турында хикәя”, “Сүзлек төзим”,схемалар, сүзләр тарихыннан чыгыш әзерләү, лингвистик темаларга сочинениеләр язу, һ.б. Кроссвордлар, ребуслар, иллюстрацияләр, тестлар дәрескә карата кызыксыну уята; дәресләрне тагын да кызыклырак итә. Проекттагы информация һәр дәрестә укучының күз алдында була, кирәк вакытта ул аңа мөрәҗәгать итә ала. Бу исә материалның хәтта йомшак укучылар тарафыннан да үзләштерелүен тәэмин итә.

Нәтиҗәләрнең яхшы сыйфатына ирешүдә татар теле дәресләрендә уен технологиясе алымнарын куллануның роле зур дип әйтә алабыз, чөнки мәктәп балаларының укуга, белем алуга омтылышын, кызыксынуын ныгытуда, аларның күзәтүчәнлеген арттыруда һәм иҗади фикер йөртү сәләтен үстерүдә уеннар гаять зур әһәмияткә ия. Ә моның өчен мөмкинлекләр җитәрлек. Әйтик, дәреснең аерым этапларында төрле уен элементлары кертергә була. Дәресләрдә уен технологиясе уенга корылган төрле ситуацияләр аша тормышка ашырыла һәм уку эшчәнлегендә кызыксындыру, эшкә дәртләндерү чарасы буларак файдаланыла.

Уңышка ирешү ситуациясе тудыру укучыларда үз мөмкинлекләренә ышанычны арттыра һәм белем алуга уңай мотивация булдыра. Күп кенә танылган педагоглар да уен методына зур игътибар биргәннәр. В.А. Сухомлинский: «Бала – үзенең табигате белән эзләнүче, дөнья ачучы. Шулай булгач, аның алдында тылсымлы дөнья бөтен төсләре белән ачылсын. Бу төсләр ачык һәм дулкынландыргыч тавышларда, экиятләрдә, уеннарда, баланың үз иҗатында... Әкиятләр, фантазия, уен , баланың кабатланмас иҗаты – болар барысы да бала йөрәгенә дөрес юл...»,– дигән. Телдән кулланыла торган уен элементлары язуда кыенлыклар кичерә торган укучы өчен уңышка ирешү юлы. Уенлы биремнәр акыл, йөгерек уй, хәтер үсешенә уңай йогынты ясый. Күп кенә уеннар белем белән беррәттән ихтыяр көче, түземлелек, уен кагыйдәләрен үтәүне таләп итә. Иң мөһиме: уен укучы алырга тиешле белемне бирә торган, аны актив белем алу эшчәнлегеннән игътибарын читкә юнәлтми торган булсын, киресенчә, укучыны актив акыл эшчәнлегенә китерсен.

Дәресләрдә әлеге алымнарны куллану түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирде:

– укучыларның сөйләм теле яхшырды, сүзлек запасы баеды;

– татар мәдәнияте, сәнгате, әдәбияты турында күзаллаулары үсте;

– укучыларның иҗади эшчәнлеге артты;

– иң мөһиме – укучы дәрескә теләп йөри башлады.

Ә теләк булган җирдә мөмкинлек арта, нәтиҗә дә яхшыра. Укучылар төрле конкурсларда, конференцияләрдә, фән олимпиадаларында призлы урыннар алалар.

Алда язылганнардан нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: педагогика фәнендә укыту-тәрбия процессы сыйфатын үстерергә булышлык итүче технологияләр шактый. Укытучының бурычы: яңалыклар агымында югалып калмыйча, дөрес юнәлеш алу, укытучының һәр этабы өчен уку материалын аңлатуның иң уңышлы вариантын табу. Шул ук вакытта аларның бер-берсе белән ярашырга тиешлеген дә онытмау зарур.

**Әдәбият**

1. Зайцева М.В. Мотивация и некоторые пути её повышения. –М., ИД «Первое сентября», 2003.–23с.

2. Фәтхуллова К.С, Юсупова А.Ш., Денмөхәммәтова Э.Н. Татарча сөйләшик. –Казан: Татар.кит.нәшр.,2015.– 311 б.

3. Фәтхуллова К.С., Юсупова А.Ш., Денмөхәммәтова Э.Н. Татарча сөйләшәбез, укыйбыз, язабыз. Урта дәрәҗә.–Казан: Татарстан Республикасы «Хәтер»нәшр., 2015. – 144 б.

4. Шәймәрданова Н. ФДББС шартларында татар теле һәм әдәбияты укытучыларының методик компетентлыгын камилләштерү // Мәгариф. – №3. – 2015.– 15-17 б.

# КЕЙС-ТЕХНОЛОГИЯ ҺӘМ АНЫ ТАТАР ТЕЛЕН УКЫТУДА КУЛЛАНУ МӨМКИНЛЕКЛӘРЕ

Галимҗанова Р.Ф.,
Башкортстан Республикасы Дүртөйле шәһәре
rufinagalimyanova@mail.ru

**Аннотация**. Яңа белемнәр алу һәм практик күнекмәләргә ия булу максатында бердәм информацион комплекс буларак кейс-технология мөмкинлекләре карала.

**Терәк сүзләр:** кейс-технология, кейс-метод, информацион комплекс.

"Кейс-стади" куллану – яңа белемнәр алу һәм практик күнекмәләргә ия булу мөмкинлеге дигән сүз. Бу метод традицион методлардан принципиаль рәвештә аерыла: укучы дөрес чишелешне эзләгәндә, проблема буенча фикер алышканда башка укучылар һәм укытучы белән тигез хокуклы. Ул "коры материал аңлату"дан коткара. Кейс буенча фикер алышу яхшы оештырылган булса, анда эмоция, иҗади ярыш, көрәш шулкадәр күп була, хәтта аны мини-спектакль белән чагыштырып була.

Кейс методын куллануның эффективлыгы күп очракта укытучының уку-укыту процессын ничек оештыра, ничек идарә итә алуыннан тора. Укытучы роле бик зур. Чөнки ул:

– кейс төзи яки әзерне куллана;
– укучыларны группаларга бүлә (4-6 кеше);
– укучыларны ситуация, чишелешне бәяләү системасы, үтәлү вакыты белән таныштыра;
– укучыларның группадагы эшчәнлеген оештыра, докладчыларны билгели;
– группаларда чишелешнең презентациясен үткәрә;
– гомуми дискуссия оештыра;
– ситуациягә гомуми анализ ясый һәм укучыларга бәя бирә.

Әлбәттә, кейс-технологияне куллану өчен иң беренче чиратта кейсның үзен төзергә кирәк.

Кейс – ул бердәм информацион комплекс. Гадәттә, кейс өч өлештән тора: кейсны анализлау өчен ярдәмче информация; конкрет ситуация сурәтләмәсе; кейска биремнәр. Ул бастырылган, печатьләнгән булырга мөмкин (графиклар, таблицалар, диаграммалар, иллюстрацияләр, текст рәвешендә төрле информация). Мультимедиа-кейс кулланырга мөмкин (соңгы вакытта бик киң кулланыла, мәктәпнең техник базасынна бәйле) һәм шулай ук видео-кейс. Ул фильм, аудио и видео материал булырга мөмкин. Тик аның минусы – аны күп кабат карау мөмкинлегенең чикле булуы, шулай ук информациянең үзгәрүе һәм хаталар.

Кейс-технология белән эшләгәндә укытучы аеруча нәрсәгә игътибар итәргә тиеш? Беренчедән, укытучы өстәмә сораулар ярдәмендә юнәлеш бирә ала. Икенчедән, аерым очракларда үзе җавап бирергә мөмкин. Өченчедән,

кемдер проблема өстендә эшләгәндә ул читтән генә күзәтеп тора, берни дә эшләми.

Кейс технологиясе белән эшне оештыру ике этапта алып барыла: әзерлек этабы һәм үткәрү этабы.

Әзерлек этабы – ул кейсны әзерләү этабы. Монда кейс өчен биремнәр төзелә, уку ситуациясе языла яки чынбарлыктан алынган, гадиләштерелгән ситуация китерелә. Аннары укучыларга анализ ясаганнан соң җавап бирер өчен сораулар төзелә.

Икенче этап – дәрестә кейс белән эшләү этабы.

Кейсларны үтәү түбәндәге тәртиптә башкарылырга мөмкин:

1. Кейс белән танышу (3-5 минут).

2.Проблемалаштыру – группада фикер алышу нәтиҗәсендә сюжетның каршылыгын, аңа хас “сәер төгәлсезлек”не ачыклау (3-4 минут).

3. Проблеманы формалаштыру һәм иң яхшыларын сайлап алу (фронталь “ми штурмы” һәм фикер алышу) (3-4 минут).

4. Проблемалы сорауга карата гипотетик җаваплар табу (кечерәк группаларда “ми штурмы”) ( 3-4минут).

5. Кейс информациясе нигезендә гипотезаны һәм башка чыганакларны тикшерү (группада эш, 15 минутка кадәр). Укучыларга булган барлык әдәбият, дәреслек, белешмәләрдән куллану мөмкинлеге бирергә кирәк. Кайбер очракта укытучы дәреслек, белешмәләрдә булмаган 1-2 бит чамасы кирәкле информацияне бастырып чыгарып әзерләп куярга мөмкин.

6. Нәтиҗә – презентация. Группага 3 минут.

7. Рефлексия. Кейсны чишү тәртибе (3-4 минут).

Татар теле дәресләрендә кейс-технологияләрне яңа темаларны өйрәнгәндә дә, кабатлау-гомумиләштерү дәресләрендә дә кулланырга мөмкин.

Практикадан чыгып шуны әйтергә мөмкин, белем бирү процессында кейс-технологияләр:

1. укучыларда белем алуга мотивацияне күтәрә;

2.укучыларның алга таба белем алуында һәм һөнәри эшчәнлекләрендә зарури булган интеллектуаль күнекмәләрен үстерергә ярдәм итә.

Кейс методын мөстәкыйль эшчәнлеккә әзер укучылар белән эшләгәндә генә кулланырга мөмкин. Шуңа күрә кейс белән эшләүче укучы үзаллы һәм текст белән эшләү, аралаша белү, проблеманы чишү күнекмәләренә дә ия булырга тиеш. Укуга мотивациясе булмаган очракта укучы кейсларны өстән генә карап чыгу белән чикләнергә мөмкин.

Үсмерләр өчен мөһим алшартлар дип үз-үзләрен аңлау, үзбәя бирү, узаллылык, үзтәрбия, психологик һәм тойгылы иреге, үз шәхесенә юнәлтелгәнлек, каршы як симпатиясен дә әйтергә була. Менә шул чакта укучы уйландыра, кызыксындыра, фикер алышуга һәм бәхәскә чакыра торган эш төрләрен теләп башкара, берничә вариантта проблеманы чишү юлларын да эзләп таба.

Кейс-метод – теоретик белемне тормышта практик кулланырга ярдәм итүче инструмент. Укучыларда үзаллы фикерләү, тыңлый белү һәм аралашу

сәләтен үстерү, анализлау, бәяләү, командада эшләү, проблеманы хәл итү юлының иң эффектив юлын табу кебек күнекмәләр булдырырга ярдәм итә.

Методика бик күп төрле күнекмәләрне үстерергә булыша. Боларның барсын бер фраза белән аңлатып була – проблеманы иҗади якын килеп чишү, анализ ситуациясен формалаштыру һәм карар кабул итү.

1. *Аналитик күнекмәләр.* Информацияне аңлау, кабул итү, анализлау, тәкъдим итү һәм табу, төшереп калдырылган өлешне тулыландыру, аны тергезү, анык һәм ачык фикер йөртү кебек күнекмәләрне булдыра. Югары сыйфатлы информация булганда соңгысы - анык һәм ачык фикер йөртү - бик мөһим.

2. *Практик күнекмәләр.* Теоретик белемнәрне көндәлек тормышта куллана белүне формалаштыра. Кейсның проблемасы реаль ситуациядәге проблемадан гадирәк булганлыктан, ул практикада теорияне, аның методларын, принципларын куллану күнекмәләрен формалаштыруга ярдәм итә.

3. *Иҗади күнекмәләр.* Логика белән генә кейс-ситуацияне чишеп булмый. Альтернатив чишелешне генерацияләүдә иҗади күнекмәләрнең роле зур. Иҗади күнекмәләр эзләнүдән туа.

4. *Коммуникатив күнекмәләр.* Әйләнә-тирәдәгеләр белән аралашу, дискуссия алып бару, әңгәмәдәшчене инандыру осталыгына ия булу – барысы да коммуникатив күнекмәләр. Күрсәтмә һәм башка төрле медиа-чараларны куллану, группаларга берләшү, үз фикереңне яклау, оппонентларны ышандыру, кыска һәм төгәл отчет төзү кебек эшләр дә шул ук төргә карый..

5. *Социаль күнекмәләр.* Фикер алышу барышында билгеле бер төр социаль күнекмәләр формалаша: кешеләрнең эш-гамәленә бәя бирү, тыңлый белү, дискуссиядә катнашу яки башкаларның фикеренә аргумент китерә белү, үзеңне контрольдә тоту һ.б.

6. *Үзанализ күнекмәләре.* Дискуссиядәге каршылык башкаларның һәм үз фикереңне аңлап кабул итәргә, аны анализларга ярдәм итә. Әхлакый һәм этик проблемалар социаль күнекмәләрне, аларның чишелешен формалаштыра.

Ситуацияне анализлаганда укытучы куя торган сораулар: “Сез нәрсә эшләдегез?”, “Эшнең кайсы аспекты дөресрәк булды?”, “Нәрсәне тагын да яхшырак эшләп була иде?”, “Сез бу проблеманы ничек чишәрсез?”, “Без нәрсә эшли алабыз?”, “Проблема нәрсәдә?”, “Проблеманы ничек хәл итәргә?”, “Әгәр ... нәрсә булырга мөмкин?”

Бүгенге көндә кейс-технология – иң уңышлы технологияләрнең берсе һәм аны куллану мөмкинлекләре бик киң. Хәтта мәктәптә укытучыларга кейс-технологияләрне кулланудан курыкмаска, ә аларны тагын да киңрәк кулланырга кирәклеген әйтәсе килә. Чөнки кейслар куллану конкрет белем һәм күнекмәләрне булдыруга гына юнәлтелми, ә укучының гомуми, интеллектуаль һәм коммуникатив потенциалын үстерүне дә күз уңында тота.

Кейслар үзенчәлекле уку-укыту технологиясе. Ул эзләнү-тикшеренү эшен дә, коллектив белем алу, индивидуаль һәм группада эшләүне дә, проект технологиясенең специфик төре буларак укучылар эшчәнлеген уңышка да стимуллаштыра. ФДББС нәкъ менә шуларны күз уңында тота.

**Әдәбият**

1.Гайфуллин В. Педагогик технологияләр // Мәгариф, 2000. – № 4.– Б.7-10.

2.Харисов Ф. Татар телен өйрәтүдә заманча технологияләр / Ф.Харисов, Ч.Харисова // Мәгариф. – Казан, 2002. – № 8. – Б.33-36.

3.Толочина (Демьянчук) О.Г. Кейс-технологии как один из инновационных методов образовательной среды // Режим доступа: http://nsportal.ru/vuz/pedagogicheskie-nauki/library/2013/01/22/keys-tekhnologii-kak-odin-iz-innovatsionnykh-metodov

# ТАТАР ТЕЛЕ БЕЛЕМЕНДӘ СИНОНИМНАРНЫ ӨЙРӘНҮ ТАРИХЫНА КҮЗӘТҮ

Галиуллина Г.Р.
Казан федеральуниверситеты
caliullina@list.ru

**Аннотация.** В статье представлен краткий обзор изучения лексической синонимии в татарском языкознании.
**Ключевые слова:** татарский язык, синонимы, лексикология, семантика

Тел белемендә синонимияне өйрәнүгә багышланган шактый бай материал тупланган. Фәнни хезмәтләрдә синонимия күренешенең асылын аңлату, синонимнарны аерып чыгару критерийларын билгеләү, төрле телләрдә синонимнарның барлыкка килү һәм кулланылыш үзенчәлекләрен ачыклау мәсьәләләре үзәктә тора. Синонимия күренешенең телнең төрле катламнарында очравына бәйле рәвештә, аның асылын аңлатуда да төрлелекләр күзәтелә. Билгеле булганча, синонимия күренеше лексикада гына түгел, грамматик һәм сүз ясалышы яссылыкларында да күзәтелә, һәм әлеге тел катламнарындагы синонимлык һәр очракта да бертөрле табигатькә ия түгел.

Тел белемендә синонимия күренешенең асылын аңлатуда ике төрле юнәлеш яшәп килә. Беренче юнәлеш вәкилләре (А.Б. Шапиро, А.Н. Гвоздев, Л.Н. Саркисова, П.С. Александров һ.б.) синонимнарны охшаш, әмма мәгънә төсмерләре белән аерыла торган берәмлекләр буларак билгелиләр. Икенче юнәлеш вәкилләре (В.В. Виноградов, Е.М. Галкина-Федорук, Л.А. Булаховский, Н.М. Шанский, Д.Э.Розенталь һ.б.) төп акцентны мәгънә тәңгәллегенә юнәлтәләр. Беренче юнәлеш вәкилләре мәгънә ягыннан тәңгәллекне кире каксалар, соңгылар исә синонимия нигезенә нәкъ семантик тәңгәллекне, мәгънәдәш сүзләрнең бер-берсен тулысынча һәм иркен алыштыра алу үзенчәлеген куялар [5, 155].

Татар тел белемендә парадигматик мөнәсәбәтләргә корылган төркемнәр арасында синонимия күренеше шактый өйрәнелгән санала. Беренчеләрдән булып татар теленең синонимик байлыгы Каюм Насыйриның «Кабуснамә» әсәрендә һәм сүзлекләрендә урын ала. «Ләһҗәи татари» сүзлеген төзегәндә галим татар теленең үз сүзләрен һәм алынмаларны синонимнар аша аңлатуны үзәккә ала [4].

1933 елда «Мәгариф» журналында Х. Сәлимнең «Бездә синонимнар һәм алар өстендә эшләү» мәкаләсе басыла. Әйтергә кирәк, бу – татар теленең синонимнары өйрәнүгә багышланган беренче хезмәт. Автор татар телендә бу төр берәмлекләрнең өйрәнелмәвен искәртеп, рус тел белемендә яшәгән билгеләмәләрнең дә төгәллек соравын искәртә һәм үзенең билгеләмәсен тәкъдим итә, синонимнарның үзенчәлекле сыйфатларын аера [5, 156].

1940 нчы елда В. Хангилдинның синонимнарның экспрессив-стилистик үзенчәлекләренә, барлыкка килүләренә багышланган ике мәкаләсе дөнья күрә.

Автор синонимнарның мәгънәви сыйфатларына, доминанта сүз мәсьәләренә карата да шактый тирәнтен мәгълүмат бирә. Татар тел белемендә бу төр берәмлекләрне тикшерүгә этәргән әлеге ике хезмәтнең әһәмияте зур [8; 9].

XX гасырның 40 нчы еллары ахырында синонимнар мәсьәләсе күренекле әдип, галим Ш. Рамазанов хезмәтләрендә яктыртыла башлый. Аның 1954 нче елда басылып чыккан «Татар теле буенча очерклар» хезмәте татар лексикологиясенең төрле якларын, шул исәптән, синонимия мәсьәләләрен дә шактый тулы яктырта. Галимнең синоним сүзләргә билгеләмәсе түбәндәгечә яңгырый: «Синонимнар, нигездә, бер төшенчәне белдерә торган, ләкин аваз төзелеше белән аерым сүзләр алар». Бу хезмәттә татар телендә синонимнарның барлыкка килү юлларыннан китап теле лексикасының халыкның җанлы сөйләм теле, диалекталь лексика белән кушылуына аерым аңлатыла.

Х.Курбатовның 1956 нчы елда басылган «Татар теленең синтаксис һәм стилистика мәсьәләләре” хезмәтен билгеләп үтәргә кирәк. Биредә синонимнарның стилистик вазифасына аерым игътибар бирелә [5, 157].

Татар теле синонимиясе өлкәсендә Ш. Ханбикова эшчәнлеге аерым урын тота. Аның 1950-1980 нче еллар аралыгында дөнья күргән хезмәтләре һәм филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алу максатыннан эшләнгән «Татар телендә синонимнар» дигән диссертациясе татар теле синонимиясенә багышланган фундаменталь хезмәтләрдән саналалар. Ш.С. Ханбикова татар теленең синонимнары буенча эшләнгән беренче сүзлекнең авторы да. Аның 1980 нче елда басылган “Татар телендә синонимия һәм сүзлекләр” хезмәте бүгенге көнгәчә татар теленең синонимиясен тирәнтен яктырткан хезмәт булып тора [7].

Татар теле лексикологиясе буенча дәреслекләрендә Ф.С. Сафиуллина синонимнарны өйрәнүне яңа фәнни казанышлар нигезендә тагын да баета. Ш.Ханбикова белән авторлыкта 1999 елда галимәнең «Синонимнар сүзлеге» басылып чыкты. Биредә хәзерге татар телендә кулланылган 4500 чамасы синонимик оя тупланган, доминанта сүз рус теленә тәрҗемәдә бирелгән, ахырда сүзләр күрсәткече бирелгән [6].

Татар теленең ономастик берәмлекләрен арасындагы синонимлык мәсьәләләре Г.Ф. Саттаровның хезмәтләрендә тирәнтен яктыртылган.

2009 нчы елда Г.К. Закированың «Алтын Урда чоры төрки-татар язма истәлекләрендә синонимнар» (рус телендә) монографиясе дөнья күрә. Алдарак автор әлеге темага кандидатлык диссертациясе яклый. Хезмәт үзенең һәм назәри, һәм гамәли яктан әһәмиятле булуы белән аерылып тора. Хәзерге тюркология һәм татар тел белемендә синонимнарны өйрәнү торышы, әлеге мәсьәләгә караган теоретик мәгълүмат, тарихи лексикологиягә кагылышлы мәсьәләләр, татар теленең синонимик фонды формалашу һәм үсеше әлеге хезмәттә тулы, эзлекле яктыртылган [3].

И.Б. Бәшированың 2010 нчы елда басылган «Татар әдәби теле. Семасиология» хезмәтенең шактый күләмле өлеше синонимнарга багышланган. Автор татар тел белеменең төрле катламнарында күзәтелгән синонимия мәсьәләләренә, аларның өйрәнелү торышына туктала. Галимә татар теле

лексикасының төрле катламнары мисалында синонимнарның кулланылу үзенчәлекләренә, әлеге төр сүзләр арасындагы мәгънә уртаклыгына, синонимик рәттә семантик бәйләнеш проблемаларына җитди анализ бирә [2].

2015 нче елда дөнья күргән «Татар лексикологиясе» фундаменталь хезмәтнең беренче томында телнең синонимик системасы җентекле анализлана. Биредә гомуми лексикологиядә өстенлек алган тенденцияләр, методологик алымнар нигезендә татар теленең синонимик системасының үсеш тенденцияләре, лексик синонимнарның төрләре һәм функциональ-стилистик вазифалары анализлана [5].

Югарыда аталган хезмәтләрдән тыш, хәзерге татар тел белемендә лексика, стилистика, поэтикага, грамматикага багышланган хезмәтләрдә, башка тел берәмлекләре белән беррәттән, синонимнарга тукталу еш күзәтелә.

## Литература

1. Абдуллина Р.С. Сөйләм культурасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012.

2. Бәширова И.Б. Татар әдәби теле. Семасиология. – Казан, 2010.

3. Закирова Г.К. Синонимы в языке тюрко-татарских письменных памятников периода Золотой Орды. – Казань: Изд-во Казан. гос. технического ун-та, 2009.

4. Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр. 4 томда. 3 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 382 б.

5. Татар лексикологиясе: өч томда /авт.: М.З.Зәкиев, Г.Р. Галиуллина, Р.Ф. Фәттахова, Ә.К. Булатова / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. – Казан: ТӘhСИ, 2015. – Т. I. – 352 б.

6. Ханбикова Ш.С., Сафиуллина Ф.С. Синонимнар сүзлеге. – Казан: Хәтер, 1999.

7. Ханбикова Ш.С. Татар телендә синонимия һәм сүзлекләр. – Татар. кит. нәшр., 1980.

8. Хангилдин В.Н. Татар теленең синонимикасы // Совет мәктәбе. – Казан, 1940. - №11/12. – Б.45-52.

9. Хангилдин В.Н. Татар теленең лексик-морфологик синонимикасы // Казан дәүләт педагогия институты гыйльми язмалары. Өченче чыгарылыш. – Казан, 1940. – Б.47-51.

# НЕКОТОРЫЕ ОСОБЕННОСТИ РАЗГОВОРНОЙ РЕЧИ СТУДЕНТОВ В ПОЛИЛИНГВАЛЬНОМ ОБРАЗОВАТЕЛЬНОМ ПРОСТРАНСТВЕ

Гареева Р.Р., Гареева М.Р.
БГПУ им. М.Акмуллы
ru_gareeva@mail.ru , maryam.gareeva.97@inbox.ru

**Аннотация:** Очевидно, что язык существенно меняется прямо на глазах нашего поколения. Зачастую речь подростков и молодежи не понятна старшему поколению. Радоваться этому или огорчаться? Бороться с изменениями или принимать их? В статье описываются проблемы речевого использования молодежного сленга. Особое внимание уделяется раскрытию возможных причин проникновения данной лексики в язык.
**Ключевые слова:** язык, живая речь, молодежный сленг, компьютерный сленг, интернет, студенты.

Язык не является чем-то застывшим, раз и навсегда данным. Меняются эпохи, а вместе с ними меняется и язык: уходят в прошлое одни слова, появляются другие, меняются правила грамматики и фонетики, орфографии и пунктуации. Меняющиеся представления о правильном и эффективном использовании языка, доводимые порой до абсурда, можно обозначить словом мода. Иными словами, мода есть крайнее проявление вкуса, более индивидуальное, быстро проходящее, бросающееся в глаза и обычно вызывающее раздражение у старшей и консервативной части общества. Речевая мода, видимо, более связана с модой в других областях жизни, нежели языковой вкус – с общим вкусом эпохи. К сожалению, модное не всегда значит хорошее. Сегодня часто приходится наблюдать, что неверно понимаемая свобода слова привела к значительному снижению культуры слова.

«Опасность тут одна, – отмечает В.Г. Костомаров, – любая односторонняя крайность моды, любая халтура уродуют национальный вкус, а он, в свою очередь, меняет чутье языка, отравляет эстетическую флору настолько, что он способен низвести язык Тургенева до краснобайства или удручающей скудости» [1, с.307].

В связи с демократизацией общества язык XXI века очень изменился. На смену чистой и правильной речи пришёл резко раскрепостившийся, свободный язык нового времени. В язык вливается блатная музыка, забываются приличия и нормы. Люди весело жонглируют словами, впитывая иностранную лексику и экспериментируя над своей собственной. Своеобразная мода на жаргонизмы появилась и в СМИ, даже наиболее тиражные газеты считают возможным выносить в шапку на первой полосе слова, относящиеся к примитивным ругательствам. Пытаясь увеличить число подписчиков, слушателей, зрителей, некоторые современные газеты, журналы, радио- и телепрограммы слепо следуют за установившейся в сознании носителей языка речевой модой. А

люди, для которых радио и телевидение является авторитетом, привыкают к данной лексике и воспринимают её как нормированную.

Интернет и другие современные технологии диктуют свои ритмы, навязывают определённую эстетику и вводят в употребление специальные термины и их сленговые варианты: *гамить* (играть), *слить* (скопировать), *хайп (*шумиха, ажиотаж*), чилить (*отдыхать, ничего не делать*), го (*идём, давай*), жиза (*жизненно), ну и такие как шиза, рофл, хз, т.д., крч, всм.

Вообще же следует отметить, что сленговая лексика широко проникает в просторечие, и в то же время просторечная лексика легко получает сленговую маркированность. Таким образом, при классификации лексической единицы важно выявить, как она воспринимается носителем языка. Если говорящий маркирует слово как единицу общения в определенном микросоциуме, то перед нами соответствующий социолект, а потому речь должна идти о сленге. Например, слово *локалка* «локальная сеть» образовано как обыкновенное разговорное слово со сниженной стилистической окраской (ср.: домашка, читалка), однако воспринимается как «свое» слово в среде компьютерщиков, значит, перед нами – профессиональный жаргонизм. Следует отметить, что один и тот же человек может владеть несколькими лексическими подсистемами и использовать (в зависимости от ситуации общения) в учебном заведении – сленг своего вуза, в беседе с друзьями-программистами – сленг хакеров, на дискотеке – сленг хоперов и т.п.

Надо четко представлять себе, что во всех случаях, когда мы встречаемся со сленгизмами не в словаре, а в живой речи – это лишь отдельные включения на фоне нейтральной или фамильярной лексики. В сленге отражается образ жизни речевого коллектива, который его породил. Наиболее развитые семантические поля — «человек» (с дифференциацией по полу, родственным отношениям, по профессии, национальности), «внешность», «одежда», «жилище», «досуг» (вечеринка, выпивка, музыка, курение). Гораздо меньше сленгизмов, которые относятся к учению или работе молодежи. Сленг является одним из обязательных атрибутов социальной группы и выполняет не только функцию обособления социума (это отрицательная оценка сленга как нежелательного явления), но и функцию ее оформления, функцию выражения ценностей определенной субкультуры. С помощью языка носитель сленга отождествляет себя с какой- либо социальной группой и выражает ее идеалы.

Сейчас многие профессии требуют творческого подхода, поэтому всё более актуальным становится развитие в каждом молодом человеке не просто умения владеть словом (чтобы ясно и точно выразить свою мысль), а и нестандартного отношения к нему.

Молодежь чутко откликается на все перемены в обществе. На фоне всеобщей речевой неграмотности возникает социальный диалект людей в возрасте 13-22 лет, возникший из противопоставления себя не столько старшему поколению, сколько официальной системе и бытующий в среде городской учащейся молодежи.

Она возникает как некая возрастная особенность и необходимость в подсознательном закреплении и утверждении своих личностных прав. Подростки, говоря на своём языке, не только понимают друг друга, они объединены и в какой-то степени защищены от взрослого мира. При этом в большинстве случаев ребёнок и сам понимает абсурдность и несовершенство своей речи, но сленг помогает ему адаптироваться в сложной, а иногда и враждебной для него среде. Часто дети эпатируют взрослых, доказывая своё право на самостоятельность. Это возрастное и социальное разделение является вполне естественным. Например,

— А что, папа не *задонатит* (пожертвует) тебе на билет?

— Не, после вчерашнего – *не варик* (не вариант).

Одно из направлений Уфимского государственного колледжа технологии и дизайна – это дизайн по отраслям и информационные системы и программирование. Поэтому студенты, в своем большинстве – это яркие, экспрессивные, нестандартно мыслящие молодые люди. Нестандартность и творческая личность студентов выражается во всем: в мыслях, в одежде и, конечно же, в языке. Часто творческое отношение к делу идет в разрез с чистотой речи языковой личности, а использование в речи молодежного, частично, профессионального, сленга является потребностью молодых людей в самовыражении и встречном понимании.

Мы изучили молодежный сленг обучающихся колледжа и сделали следующие выводы:

Одно и то же слово может входить в различные групповые сленги, поскольку процесс заимствования в социальных диалектах достаточно активен. При этом со сменой групповой маркированности обычно происходит и изменение в семантике слова, изменение его смыслового объёма. Так, в сленге компьютерщиков *глюк* означает «сбой программы», а в молодежном сленге *глюк* употребляется в значении «видение, галлюцинация» или же сленг компьютерщиков *виндушник/винда в* молодежном сленге студентов означает «окно в расписании занятий». Часто речь студента-будущего программиста уже сегодня заполнен компьютерными сленгами и такая речь часто приводит преподавателя в недоумение. Приведем пример из речи студента: «чтобы полностью восстановить *комп*, лучше всего нужно *переставить форточки*, а чтобы нормально *апнуться*, лучше заменить *мать* с камнем, *усилить мозги*, ну и *клаву* поменять и мышь на *зазерную*».

Не сильно отличается речь студента-программиста от речи студента-дизайнера. Последние, наряду со студенческим сленгом, типа креатив, реал, позитив, завал, админка, первак, студак, забить на пару, филонить, стрельнуть и т.д., часто используют и профессиональный сленг.

Далекому от данной профессии человеку сложно понять смысл данного разговора:

— В конце опять у тебя там *вдова* (одинокое слово, которое стоит отдельной строкой в конце абзаца) маячится?

— Да, и *поженить* (в дизайне: сочетать несколько вариантов из разных концепций, идей) не получилось.

Изучая проблему молодежного сленга, следует отметить, что молодежный сленг – это проявление «языковой болезни» – бездумности и отрицания норм, примитивизма и языкового атавизма, присущие молодому поколению. В определенный период роста молодежи не стоит заражаться этой болезнью, а следует, преодолев ее первобытную стихию, осознать достоинство и силу языка. Безусловно, для сбалансированного развития культуры современной речи является необходимым разработать единую стратегию и тактику в области языковой политики, предусматривающие, в частности, повышение культуры устного литературного слова, а также общую языковую компетенцию в общеобразовательных школах и гимназиях.

**Литература**

1. Костомаров В.Г. Языковой вкус эпохи. – СПб., 1999. – С.307.
2. Пеллих И.В. Молодежный сленг как социальная разновидность речи //
3. Вестник Адыгейского государственного университета. Серия 2: Филология и искусствоведение, 2008 // Режим доступа: https://cyberleninka.ru/article/n/molodezhnyy-sleng-kak-sotsialnaya-raznovidnost-rechi/viewer

# ИНОВАЦИОННЫЕ ПЕДАГОГИЧЕСКИЕ ТЕХНОЛОГИИ НА УРОКАХ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

Гареева Р.Р., Гиззатуллина А.Ф.
БГПУ им.М.Акмуллы
ru_gareeva@mail.ru, gizzatullinaaig@mail.ru

**Аннотация.** В рамках данной статьи рассматриваются вопросы использования инновационных педагогических технологий на уроках татарского языка. Также статья содержит и конкретные методические рекомендации.
**Ключевые слова**: инновационная технология, татарский язык.

В современных условиях учебная деятельность учащихся организуется и с помощью инновационных технологий. Среди таких технологий выделяются информационно-коммуникационные технологии, игровые технологии, квест технология, кейс технология, проектная технология и т.д. Рассмотрим особенности включения некоторых из этих технологий в структуру урока татарского языка. Например, игровые технологии особенно эффективны в работе с начальными классами. Хотя, учебная деятельность и является основной деятельностью и особенностью которая отличает учащихся начальной школы от детей дошкольного возраста [3, 80], несомненно, тяга к игре сохраняется и в ученике младшей школы. Поэтому, учителя в целях обучения и развития постоянно используют игровые технологии. Например, в третьем классе при изучении темы «Сложные слова», педагог может предложить игру связанную с именами людей. Учитель разделяет учеников на две команды, каждая команда, исходя из сказанного учителем, пишет на доске одно имя. Скажем, первый вопрос может звучать следующим образом: «это – женское имя, первый компонент имени указывает, что девушка похожа на цветок, а второй компонент означает, что она очень нежная». Соответственно, команда для которой прозвучал этот вопрос пишет на доске татарское имя «Гөлназ» (Гульназ).

Учитель задаёт вопрос второй команде: «это – мужское имя, состоит из двух корней, значение – любящий свою страну, считающий её своим другом». Из второй команды один ученик пишет на доске имя «Илдус» (Ильдус). Если команда затрудняется ответить или допускает ошибку при написании имени, предыдущая команда получает право ответить два раза подряд.

На сегодняшний день очень большое внимание уделяется проектной технологии. Но следует отметить: эта технология не может быть применена на каждом уроке, так как она требует много времени и считается довольно трудной деятельностью. Всё же каждый учитель, в том числе и учитель татарского языка на протяжении учебного года, хотя бы один раз, но должен организовать проектную работу. В соответствии с этими требованиями во многих учебниках татарского языка присутствуют рубрики «проект», «мой проект». Например, при работе с учебником составленным Р.К.Сагдиевой и

Г.Ф.Харисовой для седьмых классов, предлагается следующий проект: «подготовь презентацию о любимом занятии или о профессии родителей» [4, 53].

Этот проект можно задать на дом и на следующем уроке оценить презентации и выступления ребят, также работу можно организовать и в группах. Учёные основными этапами проектной деятельности называют такие, как «работа над заданием проекта, выполнение проекта, выводы, защита проекта» [2, 11]. Как известно, при использовании проектной технологии, обязательным условием является возможность выбора понравившейся темы из предложенных тем. Исходя из этого, вышеприведённую тему из учебника можно развить в двух направлениях.

Скажем, первая группа, как и сказано в учебнике подготавливает презентацию о любимом занятии; вторую группу, возможно интересует профессии, ремесло древних предков, они могут провести исследование в этом направлении; третья группа может работать над информацией и презентацией относительно современных профессий; учащиеся четвёртой группы могут предложить сообщение и презентацию о профессиях которые можно освоить в школе либо во внешкольных организациях. Так как, этот проект предлагается в рамках изучения темы «Причастие», главным его условием является, чтобы каждая группа в своих выступлениях, презентациях использовала причастия. Приблизительный план работы мы показываем на примере первой группы. Скажем, учащиеся готовят проект на тему «Моё любимое занятие – вышивка». На этапе подготовки определяются цели проекта. Например, они могут быть следующими:

1) освоение особенностей причастия через творческий подход и представление их остальным посредством презентации;

2) собрать информацию о вышивке и сообщить другим;

3) побудить уважение к ручной работе.

Следует отметить: хотя целью уроков языка и является формирование языковой личности, в основном ведётся работа и по формированию лингвистической, коммуникативной компетенции. Вышивка, как любимое ручное занятие наших предков создаёт почву и для формирования этнокультурной компетенции.

На этапе выполнения проекта учащиеся работают с источниками информации: с помощью руководителя кружка «Вышивка» и интернета собирают информацию о методах вышивки; отбирают фотографии где изображены платья, салфетки, полотенце и т.д. выполненные в разных методиках вышивки; выбирают названия для слайдов; подчеркивают / выделяют использованные причастия.

На этапе выводов, в случае надобности вносятся поправки в готовую презентацию, подготавливают текст выступления.

На последнем этапе – презентации проекта, результат деятельности демонстрируется аудитории. Например слайды могут расположиться следующим образом: *1) Чигү – иң матур, кызларны алдагы <u>тормышка әзерли</u>*

*торган* *шөгыльләрнең берсе* (Вышивка – одно из самых красивых занятий, подготавливающий девушек к последующей жизни). *2) Чигү белән бизәлгән алъяпкыч* (Передник украшенный вышивкой). *3) Шома чигү белән эшләнгән чәчәк* (Цветок выполненный гладкой вышивкой). *4) Рококо чигүе ысулы белән эшләнгән чәчәк бәйләме* (Букет цветов выполненный посредством вышивки рококо). *5) Ике яклап шома чигү ысулы белән эшләнгән күбәләк* (Бабочка выполненная посредством гладкой вышивки с двух сторон).

В остальных группах работу можно организовать примерно таким же образом.

А теперь обратимся к информационно-коммуникационным технологиям, которые вбирают в себя такие ресурсы как Интернет, аудио- и видеоматериалы, презентации, приложения, электронные книги и т.д. Скажем, в десятом классе на этапе закрепления знаний по разделу «Лексикология», с целью актуализации полученных знаний, предлагаются вопросы. Один из них звучит следующим образом: «*Татар телендә нинди сүзлекләр була? Алар ни өчен кирәк*?» [1, б. 38] (Какие бывают словари в татарском языке? Зачем они нужны). Положительная сторона вопроса заключается в том, что в учебнике десятого класса не повторяется материал про словари из учебника пятого класса, поэтому учащийся вынужден будет обратиться к дополнительным источникам. Ученики в беседе о словарях, могут воспользоваться «Электронным фондом словарей». Школьники образуя пары либо объединившись в малые группы, могут сделать экскурс по словарям изданным в последние годы. Также работу со словарями можно продолжить при изучении тем раздела «Словообразование». Хотя, в учебнике татарского языка и представлена информация о типах словообразования, о словообразовательных гнёздах информации практически нет. Учитель может предложить задание: «Приведите примеры словообразовательных гнёзд лексико-семантической группы «Человек».

Учащиеся воспользовавшись «Электронным фондом словарей» должны будут выписать несколько примеров. Ученик, в поисковике этого электронного ресурса пишет наименование связанное с человеком, это может быть нога, голова, рука, печень и т.д.

В заключении мне бы хотелось отметить: хотя учебники татарского языка и являются главной опорой учителя, они не успевают за каждым новшеством. Поэтому, учитель-новатор должен иметь в виду и инновационные технологии. Например, игровые технологии, выполнение проектов разного типа, информационно-коммуникационные технологии играют большую роль в учебной и познавательной деятельности современного учащегося.

**Литература**

1. Галиуллина Г.Р. Татар теле. 10 сыйныф: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). – Казан: Татар. кит нәшр., 2016. – 111 б.

2. Камаева Р.Б. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә яңа педагогик алымнар. – Алабуга: АДПУ нәшр., 2010. – 106 б.

3. Кулагина И.Ю. Психология детей младшего школьного возраста. – М.: Юрайт, 2020. – 291 с.
4. Сәгъдиева Р.К., Харисова Г.Ф. Татар теле: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүчеләр өчен). – Казан: “Мәгариф – Вакыт” нәшр., 2015. – 215 б.
5. Сүзлекләрнең электрон фонды. – URL: http://suzlek.antat.ru/index.php; мөрәҗәгать итү вакыты: 09.02.2021.

# ЛОГОПЕДИЧЕСКАЯ МНЕМОТЕХНИКА КАК СРЕДСТВО АКТИВИЗАЦИИ РЕЧЕВОЙ ДЕЯТЕЛЬНОСТИ ДЕТЕЙ

Гарифуллина Г. А.
МБДОУ «Детский сад №18 «Улыбка» г. Азнакаево РТ
guzel.almazovna@mail.ru

**Аннотация** В логопедической практике существует эффективная технология коррекции речи на основе мнемотехники. Мнемотехника – это система методов и приемов, облегчающих запоминание, способствующих образованию дополнительных ассоциаций об окружающем мире. При произнесении текста с опорой на красочную картинку, ученик непроизвольно запоминает информацию и активизирует речевую деятельность.
**Ключевые слова:** Приемы мнемотехники, развитие речи, дети с речевой патологией.

Актуальность проблемы состоит в том, что с каждым годом количество детей с речевыми патологиями имеет тенденцию к увеличению. Речевые нарушения отрицательно влияют на развитие интеллектуальных способностей, что снижает успеваемость в школе и является причиной школьной дезадаптации.

Человек с хорошей развитой речью легко вступает в общение, может понятно выражать свои мысли, договариваться с партнерами о совместной деятельности. Неясная речь весьма затрудняет взаимоотношения с окружающими.

Проблема стимулирует постоянный поиск новых идей и технологий, позволяющих оптимизировать коррекционную логопедическую работу, ускорить процесс формирования всех компонентов речи, когнитивных процессов, коммуникативных навыков.

Работая учителем-логопедом с дошкольниками, нужно учитывать, что у них наряду с недоразвитием речи страдают процессы внимания, памяти и образного мышления, а также и то, что в данное время дети перенасыщены информацией, необходимо, чтобы процесс обучения был для них интересным, занимательным и развивающим.

Мнемотехника позволяет контролировать процесс запоминания, сохранения и припоминания информации, требующей дословного повторения, тем самым способствуя развитию речи.

У детей с речевым недоразвитием очень важно развивать наглядно-образное мышление, используя картинки, символы, схемы, обогащать словарь, формировать связную речь. Логопедические мнемотехники представляют собой иллюстрированную последовательную систему мнемодорожек и мнемотаблиц, направленных на совершенствовании речи детей, для автоматизации и дифференциации звуков. Основой дорожек и схем послужили известные скороговорки, чистоговорки, прибаутки и стихи. При подборе

материала ставится цель не только исправить недостатки произношения, но и обогатить словарный запас, расширить кругозор, создать эмоционально благоприятный фон, развить память и мышление детей для более успешной подготовки их к обучению в школе. Дети, видя изображение заинтересованно повторяют за педагогом текст. При проговаривании скороговорок и стихов обучающиеся контролируют собственную речь. Разучивание текстов становиться делом занимательным и интересным. Организация учебного процесса происходит в виде увлекательной игры.

По результатам логопедического мониторинга у детей отмечается положительная динамика в овладении правильным звукопроизношением, ускорением сроков автоматизации звуков. Значительно повышается объём памяти, улучшается распределение и устойчивость внимания, активизируется речемыслительная деятельность. Успехи в этом направлении безусловно содействуют повышению уровня развития речи.

**Автоматизация и дифференциация шипящих звуков Ш, Ж, Ч, Щ**

Шла по аллее мышка,
У мышки в лукошке пышки и шишки.
Саша дала Даше, миску каши и простокваши.

Ежу на ужин, жук да паук нужен.
У Ежа ежата
А у ужа ужата. [4, 113].

Черепаха, не скучая,
час сидит за чашкой чая. [2, 214].
В роще щебечут стрижи,
Чечетки, щеглы и чижи. [2, 244].

Два щенка щека к щеке –
Грызли щетку в уголке. [2, 244].

## Литература


1. Барсукова Е.Л. Автоматизация звуков с использованием мнемодорожек.
2. //Логопед. — 2009. — №5. - С. 26
3. Крутий Е. Л. Волшебная логопедия. – Д.: Сталкер, 1999. – С. 214, 244
4. Маринчева Е.В. Инновационные формы и технологии, используемые в работе по коррекции речевых нарушений у дошкольников (электронный ресурс). // doshkolnik.ru/logopedia/13713.html (дата просмотра 08.02.2021).
5. Селиверстов В.И. Игры в логопедической работе с детьми. М.: Просвещение,1981. – С. 113

# ОБУЧЕНИЕ РОДНОГО (ТАТАРСКОГО) ЯЗЫКА В НАЧАЛЬНОЙ ШКОЛЕ

***Гарифуллина Л.И.***
***МАОУ «Прогимназия №29»***
***Landysh_mama@mail.ru***

**Аннотация**. В данной статье приводятся размышления на тему преподавания родного (татарского) языка в начальных классах.
**Ключевые слова:** нация, литературный язык, разговорная речь, родной (татарский) язык, ученик, культура.

Одна из самых острых проблем современности – проблема сохранения национальных культур, особенно культур малых народов. Кроме того, сегодня остро встала проблема сохранения родных языков. Любой национальный язык непосредственно связан с формированием национального самосознания. В настоящее время особенно необходимо уважительное и тактичное отношение к национальному языку, этническому этикету, объектам национальной культуры и к духовности в целом, которая лежит в основе любого этноса и проявляется через родной язык.

Одна из основных задач обучения родному (татарскому) языку в начальной школе – развитие связной речи учащихся. Учитель, обучающий учащихся родному (татарскому) языку, не может считать свою задачу выполненной, если он не научит их грамотно читать, писать и говорить, т.е. хотя бы элементарно выражать свои мысли. Преподавание и изучение родного языка в школах преследует цель практического овладения языком. Поэтому для обучения школьников родному (татарскому) языку как второму необходима особая программа развития речи. Она должна быть построена на наблюдениях, на обогащении детей знаниями о языковой культуре своего народа, на развитии мышления и чувств ребенка, на практической и синтетической работе над языком, а не на теоретическом и аналитическом изучении языка. Это должна быть практика речи, а не теория языка.

Сколько угодно можно твердить, что это наш родной язык, что мы обязаны его знать, но это, к сожалению, не работает. В сознании наших родителей нет того понятия, что родной язык наша духовная культура, что каждый из нас несет ответственность за её будущее. Каждый родитель хочет видеть своего ребенка успешным, благополучным, воспитанным. Большая часть родителей считает, что для успешной карьеры и учебы родной язык является помехой.Важным моментом в сохранении родного языка является передача полученных знаний и ценного опыта подрастающему поколению. Самыми первыми учителями для ребенка являются его родители. Именно та речь, которая постоянно звучит в кругу семьи, лучше всего запомнится ребенком. Спустя годы, даже пожив долгое время в чужой стране и

вернувшись, этот язык будет легче вспомнить. Поэтому в национальных семьях очень важно говорить дома на своем родном языке.

Стоит проблема нехватки методической помощи. Например, учитель русского языка, зайдя в любой книжный магазин, может купить методическую книгу на любую тему, а вот учитель татарского языка не имеет столь огромного выбора. На сегодняшний день у нас мало специалистов, которые занимаются этой деятельностью. Стоит так же отметить ограниченное количество интернет - ресурсов на татарском языке и о культуре татарского народа. Я считаю, что должно появиться гораздо больше разных источников информации, чтобы ребенку в век информационных технологий было интересно обучаться татарскому языку.

Наиболее эффективным и результативным средством поддержания интереса детей и их родителей к изучению языка являются разнообразные уроки с применением современных технологий и инновационных методов. Источниками развития речи в школьном обучении являются чтение, наблюдение над окружающей действительностью, беседы с детьми, общение дома со взрослыми, специальное обучение нормам литературного языка на уроках и т. д.

Младшие школьники любят слушать стихи поэтов на татарском языке. Когда рассказывают им про наш язык, про наши обычаи и традиции, про нашу культуру, любовь к татарскому языку ещё сильнее разгорается в сердцах детей. На уроках литературы мы часто ставим сценки по тем или другим произведениям. Дети это очень любят. Сами готовят костюмы, готовят декорации и учат наизусть слова, чтобы им досталась та или иная роль. Очень важно знать свой предмет в совершенстве и преподавать его увлекательно, иметь в душе прекрасный идеал, высокую мечту и стремиться к ней, выходить из конфликтных ситуаций с достоинством и юмором. Я перед собой ставлю цель и достигаю результатов. А результат виден по итогам республиканских олимпиад.

Учитель должен обучить ребенка правильному произношению и правильному слушанию на основе развития речевого слуха. Он должен привить детям навыки слушания , чтения и пересказа на примере своего произношения. Обогащение же речи словами и оборотами обычно происходит в процессе наблюдений над природой, над трудом людей, общения друг с другом и бесед с учителем и т. д. Чтобы обогатить словарный запас учащихся, привить навыки правильного использования в речи новых слов из активного словаря и составления элементарных высказываний необходимо на каждом уроке уделять несколько минут наблюдениям за погодой , чтобы на вопрос учителя «Какая сегодня погода?» каждый из детей мог составлять высказывание из 2-3 предложений. Проводить почаще прогулки в парках, скверах или просто во дворе школы, проводить беседы об изменениях в природе, давая ответ на каждый вопрос учителя 2-3 предложениями, хотя бы один раз в неделю читать детям текст из 15-20 слов, комментировать его, дать пересказать каждому из учеников и на каждом уроке проводить краткую беседу по каждой из картин

учебника и составлять высказывания из 3-4 предложений. Затем необходимо выяснить, как повлияют прочитанные произведения, их пересказы, система работ по картинам и наблюдениям на развитие словаря и связной речи учащихся.

Хороший результат дает вовлечение детей во внеклассные, общешкольные мероприятия. Становясь активными участниками таких мероприятий, как «Навруз», «Карга боткасы», «Сабантуй» и др., учащиеся детально знакомятся с порядком проведения мероприятий.

В будущем эти правила дети переносят в свою жизнь. Родителям эти мероприятия также интересны, т.к. их поколение выросло, не зная этих правил. Вовлечение детей в исследовательский процесс – изучение предметов одежды, быта, возможность подержать их в руках, раскрытие секретов и значения татарского орнамента на полотенцах, тюбетейках, фартуках – пробуждает в детских душах чувство гордости, уважения и восхищения своим народом, своими предками.Большое значение придается в работе построению межкультурных коммуникаций. Так, например, традиционными для школы стали мероприятия «День родных языков», «Радуга культур». Здесь звучат песни и стихи на татарском и русских языках, показываются национальные танцы и другие элементы.

На результаты преподавания родных языков в школах влияют следующие составляющие учебно-воспитательного процесса:

Во-первых, родной язык в школах изучается как второй язык, когда мышление ребенка и его речевая деятельность уже сформировались на базе русского языка. Во-вторых, на данном этапе преподавание родного языка не ориентировано на то, что речь является средством коммуникации, средством общения.В-третьих, сами учителя не совсем точно представляют себе, какую цель преследует изучение родного языка в школах, и в полной мере не владеют методикой работы .В-четвертых, тексты в учебниках для школ сложны и не совсем способствуют развитию речи, а упражнения однотипны.

Таким образом, для решения проблем, обозначенных выше, считаю важными следующие моменты:

1. вести активную пропаганду среди родителей о значимости изучения родного языка;
2. использовать при изучении языка связь с историей народа, культурой;
3. соблюдать преемственную связь между «тремя китами» воспитания: родители – детский сад – школа.

## Литература

1. Исаева Р.С. Играя изучаем татарский язык. Методическое пособие. – Набережные Челны, 2010. – 58 с.

3. Муяссарова И.Х. Отдохнем чуть-чуть: Физкультминутки и сюжетные игры (на татарском языке). – Казань, 1998. – 60 с.

4. Программа по обучению детей татарскому языку. – Казань: Школа, 2004. – 84 с

5..Шаехова Р.К Раз словечко, два словечко… занимаемо обучение татарскому языку. Методическое пособие, Казань, 2011г.

# ХАЛЫК ҺӘМ АВТОР ҖЫРЛАРЫ

Гатауллина А. С.
182 нче политехник лицей
gataullina_79@list.ru

**Аннотация.** В статье рассматриваются особенности использования на уроках татарского языка и литературы произведений устного народного творчества, в частности, такого специфичного жанра как народные и авторские песни. С давних пор народ складывал песни, которые сопровождали людей в разные моменты жизни, от рождения до глубокой старости. Люди поют песни и на работе, и на различных праздниках. Эти песни бережно сохраняются в народной памяти и передаются от поколения к поколению.

**Ключевые слова:** устное народное творчество, народные песни, выражение чувств, душа народа, воспитательная роль.

Тел ул – кешеләрне дөньядагы башка төрле җан ияләреннән аерып алып тора торган могҗизалы бер күренеш. Ул – җәмгыятьне оештырып, кешеләрне үзара аралаштырып, аңлаштырып торучан куәтле чара да, сәнгать әсәрләрен иҗат итүнең иң әһәмиятле коралы да. Һәм, ниһаять, камил, дөрес, матур телнең үзен дә сәнгатьнең бер төре дип әйтеп булыр иде.

Менә шушы чиксез кыйммәтле тел хәзинәләреннән уңышлы файдалана беләбезме, аны даими рәвештә баета, үстерә барабызмы, аның җәүһәрләрен тутыкмаслык итеп чистартып, шомартып тора алабызмы икән без? Бүгенге көн өчен бу – бик әһәмиятле, актуаль сорау.

Кеше томышында аның бөтен гомере буена аерылгысыз төшенчәләр, кешеләр, әйберләр була. Мин шуларның берсе дип, аның туган телен саныйм. Ул – кешенең дөньяга аваз салган минутыннан соңгы сулышына кадәр янәшә. Кеше дөньяга беренче аваз салуга, аны тудырган ана үзенең сабыена туган телендә «балам» дип эндәшә. Баланың беренче әйткән сүзе дә туган телендә яңгырый. Кеше үзенең иң саф хисләрен бары тик туган телендә генә белдерә ала. Бөек Тукай юкка гына үзенең иң кадерле кешеләре әти-әниләренә рәхмәт сүзләрен, алар рухына багышлаган догаларын туган телендә белдермәгән.

Тел – кешеләрнең аралашуы өчен иң әһәмиятле чара. Ул – тормыш чыганагы, белем чишмәсе.

Халык авыз иҗаты әсәрләре язу сәнгате туганчы ук барлыкка килгәннәр. Борынгы чорда җыр, бию, уеннар үзара үрелгән хәлдә ыруг, кәбилә иҗаты буларак яши. Заманнар үтү белән кешеләрнең аңы да үсә бара. Шуның белән бергә халык авыз иҗаты да үзгәреш кичерә, аның төрләре арта, әсәрләрдәге фикер тирәнәя бара. Алар мөстәкыйль сәнгать әсәре булып формалашалар. Халык авыз иҗаты әсәрләренә җырлар, экиятләр, бәетләр, эпослар һ.б. керә. Аларда халыкның уй-хыяллары, гаделлек өчен көрәш, якты киләчәккә омтылышы гәүдәләнә. Шунлыктан фольклор әсәрләре һәркемгә якын, һәркемне дулкынландыра, яхшылыкка, әдәпле һәм намуслы булырга өнди.

Халык авыз иҗаты әсәрләре – күмәк иҗат җимеше. Аларның авторы билгеле булмый. Кемдә булса берәү җыр, мәзәк яисә әкият чыгара икән алар шунда ук телдән телгә күчеп йөри башлый, әнә шулай яшәвен дәвам итә. Һәр башкаручы кеше мондый әсәрләрне үзенчә эшкәртә, эчтәлеген тулыландыра, сәнгатьчә матурлый, бизи.

Халык авыз иҗатының барлык төрләре дә кешеләрнең тормыш турындагы уйлануларын,тәҗрибәсен һәм хыял омтылышларын чагылдыра. Шулай да әкият, табышмак, мәзәк кебек жанрлар арасында җыр аерым бер урын алып тора. Әкиятне, мәзәкне берәү сөйли, башкалар тыңлый. Табышмакны берәү әйтә,тыңлаучылар җавабын табарга тиеш була. Ә менә җырны кеше үзе өчен генә дә башкара ала. Күңеле тулып, моңайганда ул ялгызы гына җырлап юана. Яки кәефе күтәренке булганда үзалдына нидер көйләп, куанып йөри. Кешенең җаны, рухы әнә шулай җыр булып телгә килә, моң булып чыңлый. Шулай итеп татар халык иҗатының зур гына бер өлешен җырлар алып тора. Бу борын-борыннан шулай булган.

“Җыр – халык күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә раушан көзгеседер. Бу бер төрле сихри көзгедер”, дигән Г.Тукай. Җырны беренче булып уйлап тапкан кеше, мөгаен, “менә мин җыр иҗат иттем” дип уйламагандыр да. Ул кошлар сайраган, агач шаулаган, җил искән кебек, табигый итеп,үзе дә сизмәстән җырлап җибәргәндер. Хис- кичереш булып җырның сүзләре дә, көе дә берьюлы күңеленән түгелгәндер. Әмма ул дөньяның яктырып, киңәеп киткәнен сизми дә калган. Бу матурлыкны тагын да кабатлыйсы килеп, якын кешесенә, туганнарына, дусларына да җырлап күрсәткән. Шулай итеп, җыр, канатлы кош кебек, дөньяга таралган. Иң матурлары, башкалар яратып тыңлаганы,кушылып җырлаганы,күңелләрдән күңелләргә күчеп,камилләнә барган. Анадан балага, буыннан- буынга тапшырылып,халыкның уртак байлыгы булып безнең көннәргә килеп җиткән.

“Әни” дип теле ачылганчы ук, һәркем әнисенең бишек җырын ишетә, шулай итеп баланың күңел күзләре ачыла, матурлыкны, моңны таный башлый. Шуннан башап кешенең гомере буена җыр озатып йөри,якын сердәш тә, ышанычлы дус та һәм киртәләрне – чикләрне үтә торган хәбәрче дә ул җыр. Җырлар сүзләренең эчтәлеге, көенең яңгырашы ягыннан берничә төркемгә аерылалар. Бу төрлелек җырның кайсы чорда иҗат ителүенә, аның эчтәлегенә һәм башка сәбәпләргә бәйле. Борынгы халык көйләре, мәсәлән, күбесе озын, моңлы көйләр. Аһ-зар да, сагыш та яңгырый аларда. Әмма кайгыларны җиңәрлек көчле рух та бар. Иң кайгылы җырларда да явызлык, усаллык юк. Җырлар бары тик мәрхәмәтле, рәхим-шәфкатьле булырга өйрәтә,татулыкка һәм бердәмлеккә чакыра.

Һәр заман үз җырларын тудыра дип әйтәбез. Бик борынгыдан иҗат ителә килгән җырларны без эчтәлегеннән, көенең озын, моңлы булуыннан танып алабыз. Аларның күбесен, борынгы бабаларыбыз җырлаган кебек, музыка коралларына кушылмыйча да җырлап була. Мондый вакытта без җырчының тавышын, көйдәге һәр борылыш, бизәкне аеруча ишетәбез.

Хәзерге заманга якынлашкан саен, җыр күмәк башкаруга һәм төрле уен коралларына яраклаша, көйләнә бара, яңгырашы, рухы да үзгәрә. Бүгенге халык иҗатчылары, махсус югары белемле композиторлар да борынгы көйләр матурлыгына, алардагы камиллеккә омтылалар.

Җыр кеше күңеленең иң нечкә кылларын тибрәтә, йөрәгендәге иң тирән уй хисләрен чагылдыра торган үзенчәлекле жанр. Җырлар - халык авыз иҗатының иң күпсанлы һәм төрлелеге ягыннан да иң бай өлешен хасил итәләр. Музыка белгечләре, көенең үзенчәлегеннән чыгып, җырларны 4 төркемгә бүләләр: авыл көйләре, озын көйләр, кыска көйләр, такмаклар.

Халык иҗатын өйрәнүче галимнәр җырларның нинди уңай белән көйдә башкарылуына карап, түбәндәге жанрларны билгелиләр: йола җырлары ( мәсәлән, туй җырлары), уен җырлары, хезмәт җырлары, иҗтимагый тормышны чагылдырган җырлар, тормыш-көнкүреш җырлары, лирик җырлар.

Җырның эчтәлегенә, тематикасына карап та төркемләргә мөмкин. Җыр китаплары, гадәттә, шундый бүлекләрдән тора. Шушы төрлелек, жанр байлыгы җырларның халык тормышында аерылгысыз юлдаш булганлыгы, кешеләрнең һәрдаим җырны кирәксенеп, аны иҗат итеп торуларын аңлата.

Халык авыз иҗатының башка төрләреннән аерылмалы буларак, җыр сүз сәнгате генә түгел,ул көй белән, музыка сәнгате белән дә бәйле. Өстәвенә, әле җыр ул тагын бер осталыкны, тагын бер иҗатчыны таләп итә. Бу талант иясе – җырлаучы, башкаручы. Җырның ни дәрәҗәдә моңлы, тәэсирле булуы җырчыныҗ тавышына, сәләтенә бәйле. Шулай да җырның иң әһәмиятле үзенчәлеге – аның әйләнә-тирәдәгетормышны матурлап, бизәп торудан тыш, һәркемнең күңелендә, һәр кешенең рухи байлыгы булып яшәвендә. Җырның көен, сүзләрен уйлап табучы да, аны башкаручы да үз кичерешләре, тормышына мөнәсәбәтләре турында сөйлиләр.

Җыр кешенең эчке дөньясын, аның хисләрен һәм кичерешләрен чагылдыра. Халык иҗаты әсәрләренең бу төре лирик жанрга керә. Җырлар элекке тормышның авыр, күләгәле якларын чагылдыру белән генә чикләнмиләр. Аларда яңа рухи хисләр, шәхес азатлыгы, халык идеаллары белән сугарылган изге теләкләр дә чагылган.

Җырларны халык тормышының реаль чагылышы, кеше күңелендәге хисләрнең матур яңгырашы дип атарга мөмкин. Поль Лафарг болай ди: Халык җыры...Халык рухының үзенә бертөрле, ышанычлы һәм табигый гәүдәләнеше куанычында һәм шатлыгында аның юлдашы, аның белемнәренең, фәлсәфәсенең энциклопедиясе, милли тарихын ышанып тапшыра торган хәзинәсе ул”.

Җырларда кешенең бай рухи кичерешләре, аның тормышка булган актив мөнәсәбәте чагыла. Бу хәл бигрәк тә сюжетлы җырларда ачык күренә. Җырларда кешенең реаль тормыш вакыйгаларына карата булган эчке хисләре, шәхси кичерешләре һәм фикерләре, карашлары гомумиләштереп, ләкин һәркем күңеленә ярардай итеп әйтелә. Кешенең әнә шул реаль тормышта булган вакыйгалар нигезендә туган рухи кичерешләре җыр формасына кертелеп, элек-электән билгеле булган берәр көйгә яки бөтенләй яңа бер көйгә салынып

җырлана башлый. Әгәрдә ул җыр халык күңелен тибрәндерерлек, дулкынландырырлык була икән, андый җыр халык теленә кереп китү генә түгел, бәлки бик күп вариантларда җырлана торган коллектив иҗат җимешенә әверелә.

Халык авыз иҗатының башка төрләре белән чагыштырганда, җырлар халык арасында иң күп таралган булулары белән аерылып торалар.

Тормышның бик күп төрле чакларын яктыртулары һәм тирән эчтәлекле булулары белән дә халык авыз иҗаты әсәрләре арасында алар күренекле урынны тоталар. Халык үзенең меңнәрчә җырларында тигезлекне, хокук һәм шәхес иркен яклап чыккан, дуслык, туганлык, батырлык һәм бердәмлек кергән мәсьәләләргә дә татар халык җырларында зур урын ала.

Халык лирикасының иң зур өлешен тәшкил иткән һәм халык арасында киң таралган мәхәббәт җырларын алып карыйк. Мәхәббәт җырлары халыкның гуманистик идеаллары белән бик мул сугарылганнар. Аларда кешенең кешегә булган тирән ихтирамы, кайнар мәхәббәте, гаять матур һәм чиксез көчле буяулар ярдәмендә әйтелә.

Мәхәббәт җырларының иң күпчелегендә кеше һәм аның матурлыгы, сафлыгы, табигатьтә булган иң гүзәл әйберләр белән чагыштырыла. Кешенең йөрәк ялкыны дип аталырга хаклы булган бу мәхәббәт җырларын халык бик борынгы заманнардан бирле туктаусыз иҗат итә килә, һәм аларда халыкның иртәге көнгә зур өмет һәм ышаныч белән каравы аңлашыла.

Борынгы заманнарда җырлар халыкның төрле гореф-гадәт йола бәйрәмнәрендә, күңел ачу вакытларында да үтәлгәннәр. Бигрәк тә туй һәм йола җырлары, уен һәм бию такмаклары халыкның билгеле бер тарихи чорларда ничек һәм нинди уй һәм нинди теләкләр белән яшәвен бик ачык чагылдыралар.

Җыр – татар халкының иң таралган, иң хөрмәтле иҗат җимеше. Җыр – бер-берсенә тыгыз бәйләнгән ике өлештән – көйдән һәм поэтик сүзләрдән тора. Җыр сөйләр өчен түгел, ә көйләр өчен чыгарыла. Әгәр халыкның моңлы, аһәңле матур көйләре аның тиңдәшсез һәм оста композитор булуы турында сөйләсәләр, шул көйләрнең нәфис сүзләре аның акыллы һәм талантлы шагыйрь булуын раслый.

Татар халкының җыр хәзинәсе үзенә күрә бер тарих ул. Анда без ерак гасырлар тавышын да, бүгенге көннәр аһәңен дә ишетәбез.

Җыр-берни белән дә чагыштырып булмаслык, Ходай кешеләргә бәһасез җан авазы итеп иңдергән изге моң ул. Бары тик чын йөрәктән язылган җыр гына арыган күңелләргә җиңеллек китерә, җанны чистарта, көрәшкә дәшә, матурлыкка ишек ача.

Зур, чын җыр иксез-чиксез көчкә ия. Ул таныштыра, кавыштыра, авырудан дәвалый, хәтта бер-берен дошман күргәннәрне дә татуландыра, елата, юата.

## ӘДӘБИЯТ

1. Фатих Урманче. Татар халык иҗаты. – Казан, 2005. – 383 б.
2. Хәмит Ярми. Татар халкының поэтик иҗаты. – Казан, 1967. – 245 б.

3. Балалар өчен шигырьләр, табышмаклар, әкиятләр. - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2014.

3. Сайфулина Ф.С., Замалиева Л.Ф. Устное народное творчество: учебно-методическое пособие. – Тобольск: Тобольская государственная социально-педагогическая академия им. Д.И. Менделеева, 2013. – 199 с.

4. К. Миннуллин. Фольклор теле - шигърият теле. – Казан, 2001. - 220 б.

# СПЕЦИФИКА ПУТЕШЕСТВИЯ КАК ЛИТЕРАТУРНОГО ЖАНРА В РОССИИ КОНЦА XIX ВЕКА

Гилазетдинова Г.Х., Абдрахманова Ю.Д.
Казанский федеральный университет
ggilaz@mail.ru, tfvteam@gmail.com

**Аннотация.** Данная статья посвящена исследованию особенностей литературного жанра «путешествие» на материале известного памятника письменности XIX века «Путешествие на Восток Его Императорского Высочества государя наследника цесаревича» Э.Э. Ухтомского, содержащего подробное описание истории, культуры и религии народов Востока.
**Ключевые слова:** литературный жанр «путешествие», путешествие на Восток Николая II, ориентализм.

К XIX веку в текстах путешественников была освоена и описана преобладающая часть европейских стран, это в свою очередь породило заинтересованность в изучении экзотических стран среди путешественников. Именно точное описание истории, культуры и религий стран Востока, являющего собой экзотику в то время, позволило считать труды в жанре путешествия достоверными. Интерес человека конца XIX века и начала XX века к экзотике, безусловно связан с отсутствием достаточных сведений о Востоке. Направление путешествия как литературного жанра в эпоху XIX века отличилось не только увлечением экзотическими странами, но и описанием путешествий по родной стране.

Литературе XIX века характерен ориентализм, то есть сосредоточенность на Востоке. Россия идентифицировала себя одновременно частью как Европы, так и Азии, именно такая идентификация полностью зависела от положения дел в Европе, её шаткой имперской идентичности. Непостоянность России накладывала отпечаток на и без того сложные взаимоотношения России с Азией как в военном, так и культурном планах. Образ Востока в представлении России менялся с течением времени под влиянием событий во внутренней и внешней политике. В начале XIX века образ Востока был по большей части продуктом воображения писателей. Так, в ранних представлениях писателей Восток изображался чуждой цивилизацией, полностью отличающейся от привычной Европы. Однако после завоевания Россией Средней Азии возник совершенно иной образ Востока, породивший уникальный востоковедческий дискурс в литературе за рамками романтизма. В отличие от ранних представлений, на рубеже XX века Азия частично представляла собой основу Российской Империи наравне с Европой. Такое видение Азии было создано с целью укрепления отношений между Россией и Азией и развития идеи, что Россия, являясь уникальным самостоятельным государством, вобрала в себя культурное влияние и Европы, и Азии и стала независимым элементом, связующим страны на Евразийском континенте [1:140].

Путешествия – это тексты путешественников, которые создают образы государств, местностей и городов. Невозможно не оценить роль текстов путешественников в русской литературе: при помощи них читателями осмыслялись неизвестные до того территории. Такие литературные произведения изменяли стандартные формы рассказа, романа и повести, а сюжеты часто разворачивались в вымышленных частично или полностью путешествиях.

Изначально путевые записки представляли собой описание путешествий юношей, уехавших за границу в поисках знаний. Так называемые, академические скитания, путешествия с целью изучения стран, которые наиболее подходили для обучения, были популярны среди интеллигентной молодежи [2:19]. Интерес к такому типу путешествий, несомненно, оказал влияние и на литературу. В основном путешественники в своих текстах описывали встречи или события, которые казались наиболее экзотическими или яркими, что привело в свою очередь к сомнениям в их достоверности.

Со временем тексты жанра путешествие стали носить регулярный характер, поскольку писатели пытались систематизировать знания, которые они собирали в пути. Возник новый подход к науке, который подчеркивал необходимость приобретения знаний посредством научных наблюдений. Фрэнсис Бэкон также подчеркивал связь между путешествиями и знаниями, полагая, что путешествия представляют собой форму натурфилософии [3: 293]. Такие идеи вдохновили на многочисленные поездки в далекие страны с целью сбора доказательств того, что европейские ученые должны были классифицировать различные сведения. Однако путешествие как литературный жанр вышло за рамки канона.

После XVIII века жанр путешествия развивался в двух отдельных направлениях: художественном и научном. Тексты путешествий, в которых преобладали чувства и эмоция над холодным изображением действительности, оказались чрезвычайно популярны по всей Европе. Тем не менее, в них присутствовали элементы, присущие больше научному типу путешествий, то есть и в художественном типе путешествий авторы стремились показать больше достоверного, чем выдуманного. Число путешествующих за границу в XIX веке увеличилось в результате популярности Гранд-тура в России, обязательной поездки юношей из аристократических семей в образовательных целях. Такой рост вызван сознательным подражанием русской молодежи европейской моде.

В XIX веке путевые заметки все больше отождествлялись с интересами и заботами европейских обществ, кто хотел поставить неевропейский мир в положение, в котором он мог бы подвергаться влиянию, эксплуатации или, в некоторых случаях, прямому контролю. Как и Западная Европа, Россия участвовала в картировании других стран в своих целях и использовала путевые заметки как средство самовыражения. Раннее светское русское письмо о путешествиях развивалось очень похоже на западноевропейское, хотя произошло это несколько позже.

Самые ранние светские путешествия были совершены во времена

правления Петра Великого, и, как и в случае с первыми французскими и английскими путешественниками, эти путешествия были предприняты с целью сбора знаний [4:111]. Первые путешественники отправлялись в Западную Европу для приобретения технических знаний, которых не было на родине. И дневники путешествий, и переписка, вдохновленная Гранд-туром, помогли сделать путешествия не только предметом, о котором стоит писать, но и тем, что чрезвычайно популярно среди публики. Чтобы путевые заметки стали признанным литературным жанром в Западной Европе, потребовалось внимание большинства выдающихся культурных и интеллектуальных личностей того периода. Для всех писателей и мыслителей путешествие, реальное или воображаемое, давало критический выход политическим, социальным и философским комментариям, способ затемнять явную референцию за дымовой завесой аллегории и воображения.

Путешествие как литературный жанр активно развивается в XIX веке, золотой порой считается период середины XIX – начала XX века. Для него характерно описание нравов, быта не только зарубежных стран, но и дальних территорий России, что значительно отличалось от сухого, лишенного деталей описания пути, застолий и экзотики ближних стран в начале века.

Золотая эпоха путешествий отличалась любовью к красочному изображению пейзажей и ландшафтов, изображением быта, однако в текстах путешественников иногда приводились сравнения культуры России с зарубежными государствами. Всё меняется к концу XIX века, когда путешествие представляет собой не просто знакомство с другой культурой, а шанс обдумать жизнь и взглянуть по-новому на мир. Страсть к путешествиям, присущая героя путешествий начала эпохи, сменяется суровой реальностью. Писатели показывают трудный жизненный путь героя в скитаниях в поисках смысла жизни.

Развитие литературного жанра «путешествие» тесно связано с таким событием как восточное путешествие Николая II на Восток. Путешествие на Восток Николая II, последнего императора России и представителя династии Романовых, стало важным событием в истории России. Оно существенно отличалось от предыдущих путешествий династии Романовых не только масштабностью, но и направлением, ведь до этого ездили исключительно в Европу. Кортеж наследника престола особенно встречали в Сибири: народ тщательно готовился к приезду будущего императора. Путешествие на Восток Николая II неоднократно становилось объектом для исследования в области истории.

Большую роль в развитии жанра путешествие в России XIX века сыграл князь Э.Э. Ухтомский, автор труда «Путешествие на Восток наследника цесаревича». Эспер Эсперович утверждал, что существует особое сродство духа между Россией и Востоком. Очевидно, что князь перенял любовь к Востоку от своего отца, Эспера Алексеевича Ухтомского, сначала прославившегося своим участием в походе Унковского в Японию, а затем и основанием Товарищества Русского Восточного пароходства. Именно благодаря Э.Э. Ухтомскому,

российское общество заинтересовалось Востоком.

Текст, написанный приближенным Николая II, Эспером Эсперовичем Ухтомским, в русском языкознании не был до сих пор изучен, поэтому представляет собой важный материал не только для исследования, но и вклада в понимание русской документалистики в целом. Исследование литературного произведения Э.Э. Ухтомского обусловлено недостаточной изученностью текстов путешественников XIX века, что представляет трудности в определении жанра текстов. Так, текст Э.Э. Ухтомского «*Путешествие на Восток* Его Императорского Высочества государя наследника цесаревича» характеризуется наличием различных форм отражения действительности – от историографического принципа сообщения в событии до художественных приемов изображения события.

Произведение Э.Э. Ухтомского, безусловно, является ценным памятником литературы, включающего в себя сведения по этнографии, религии и истории восточных народов. «Путешествие на Восток наследника цесаревича» получило известность не только на территории Российской Империи, но и за ее пределами и было переведено на немецкий, английский и французский языки. Нельзя не отметить тот факт, что труд включал в себя собрание сведений о буддизме Восточной Сибири, которое считалось наиболее полным собранием предметов буддизма до 1917 года.

«Путешествие на Восток наследника цесаревича» – это произведение, в котором гармонирует биографическая проза и мемуары, и в свою очередь отражающее в себе историю государств, неизвестных до того русского человеку. Повествование ведется от первого лица и отличается разнообразием тематики и богатством материала. Труд Э.Э. Ухтомского включает в себя описание путешествия Николая II, которое продолжалось в течение трехсот дней, с октября 1890 по август 1891. За время путешествия наследник российского престола с князем Ухтомским посетили ряд стран, в числе которых были: Греция, Индия, Япония, Китай и большая часть Сибири. Поездка стала не только важным этапом в подготовке будущего императора и дипломатически значимым для России мероприятием, но и повлияла на направление путешествия как литературного жанра, его развитие [5].

В своей работе автор в форме дневников описывает города, памятники культуры, рассказывает о повседневном быте и развлечениях путешественников, восхищается археологическими памятниками Олимпии и Афин. Помимо описания хода путешествия, Э.Э. Ухтомский акцентирует внимание читателя на колорите Сибири: народах, проживающих на этой территории, их верованиях, особое место уделяя буддизму и шаманизму. Более того, автор подробно рассказывает о строительстве Транссибирской магистрали, в закладке которой участвовал и сам Николай Александрович.

Наличие деталей о жизни народов позволяет говорить о том, что труд Э.Э. Ухтомского является особенным в своем роде. Так, автор подробно рассматривает особенности государств, местные реалии, интересуется жизнью обычного народа, их труде и образе жизни. В произведении можно заметить

большое количество личных историй людей, встретившихся свите на пути, а также детали жизни людей, отправленных на каторгу [6:281].

Русская литература не могла оставаться прежней после того, как вобрала в себя образы путешествий. С появлением нового литературного жанра образы географических объектов стали обыденным средством выражения отношения автора к миру в литературе. Путешествие превратилось не только в литературный приём, но и стало новой литературной метафорой. Хоть и в текстах путешественников иногда стирается грань между реально существующими и выдуманными странами и географическими объектами, но путь и пространство устанавливают сюжет и выступают самостоятельными героями. Путешествие как образ стало опорой практически всех литературных жанров впоследствии. Важным для развития путешествия как литературного жанра стало произведение приближенного цесаревича Э.Э. Ухтомского, которое отличалось от предыдущих памятников литературы подобного жанра изобилием деталей быта и образа жизни народов Сибири и Востока и направлением: к концу XIX века «Путешествие на Восток Его Императорского Высочества государя наследника цесаревича» было наиболее полным собранием сведений о Востоке в русской литературе.

## Литература


1. Brower D.R. Russia’s Orient: Imperial Borderlands and Peoples, 1700-1917 / D.R. Brower, E.J. Lazzerini. – Bloomington: Indiana University Press, 1997. – 368 p.
2. Porter Dennis. Haunted Journeys: Desire and Transgression in European Travel Writing. – NJ.: Princeton University Press, 1991. – 360 p.
3. Бэкон Фрэнсис. Новый Органон. М.: Рипол Классик, 2018. – 364 с.
4. Мамуркина О.В. Травелог в русской литературной традиции: стратегия текстопорождения // Филологические науки. Вопросы теории и практики. – Тамбов: Грамота, 2013. – № 9 (27), ч. 2. – С. 110-113.
5. Ухтомский Э.Э. Путешествие на Восток Его Императорского Высочества государя наследника цесаревича, 1890-1891: [в 3 т., 6 ч.] / авт.-изд. Э. Э. Ухтомский. – Санкт-Петербург, 1893-1897.
6. Шачкова В.А. Путешествие как жанр художественной литературы: вопросы теории // Вестник Нижегородского государственного университета имени Н.И. Лобачевского. – Н. Новгород: Изд-во ННГУ им. Н. И. Лобачевского. – 2008. – № 3. – С. 277-282.

# ИНТЕРАКТИВНЫЙ ПОДХОД ПРИ ОБУЧЕНИИ ИНОСТРАННОМУ ЯЗЫКУ ДЕТЕЙ ДОШКОЛЬНОГО И МЛАДШЕГО ШКОЛЬНОГО ВОЗРАСТА

Гилязова Р.Р., Ашрапова А.Х.
Казанский федеральный университет
tatarandlanguages@gmail.com,
rizalya.gilyazova@mail.ru

**Аннотация:** в статье рассматривается возможность использования методики интерактивного обучения в детском саду и начальной школе для изучения английского языка, раскрываются основные понятия касательно темы, приводятся задачи и преимущества ведения интерактивных тетрадей и их применение в изучении разделов грамматики, лексики, говорения. Данный вопрос на сегодняшний день актуален ввиду популярности интерактивных новшеств.
**Ключевые слова:** интерактивное обучение, интерактивная тетрадь, познавательная деятельность, самостоятельность.

Современное образование всё больше нацелено на то, чтобы воспитать у школьников положительное отношение и интерес к процессу обучения. Следовательно, многие преподаватели ищут способы, позволяющие удержать внимание детей на предмете и мотивирующих на получение знаний. Мастерство современного педагога заключается в активации познавательной деятельности учащихся, стимулировании интереса к процессу обучения.

Среди множества современных идей и технологий преподавания одним из действенных методов является методика интерактивного обучения. Интерактивное обучение – это способ познания, при которой учащиеся взаимодействуют друг с другом, обмениваются информацией, оценивают действия друг друга и свое собственное поведение, совместно решают проблемы, моделируют ситуации и погружаются в них [7, 24].

Интерактивное обучение в сравнении с другими формами обучения, наиболее точно отвечает потребностям современного мира в подготовке квалифицированных кадров, способных адаптироваться под постоянно изменяющиеся условия. В этой связи в интерактивном обучении приоритет отдается двум ключевым задачам. Первая задача – «научить учиться», так чтобы человек мог самостоятельно развивать свою индивидуальность, и иметь возможность эффективно работать с большими информационными массивами, вычленяя и осваивая то, что требуется для решения текущих вопросов. Вторая задача – «научить применять на практике новые знания» [5, 3].

Интерактивная тетрадь – это современная форма ведения тетради учащегося, которая помогает активно участвовать, анализировать, взаимодействовать с новой информацией на занятиях. Можно утверждать, что

такая тетрадь предоставляет ребенку возможность в любое время рассмотреть, изучить, повторить учебный материал в занимательном виде.

Методика преподавания с интерактивными тетрадями была создана американцами для обучения начальных классов для решения следующих задач:

– структурирование и компактная организация информации по изучаемой теме;

– практическое использование теоретической информации;

– детальное понимание и запоминание информации по изучаемой теме;

– многократное повторение изучаемого материала;

–закрепление материала по пройденной теме с учётом различных способов восприятия информации детьми (аудиалы, визуалы, киностеты и дискреты) опираются на логику;

– визуализация теоретического материала;

– развитие творческого мышления учащихся [2, 16].

Преимущества интерактивных тетрадей следующие:

1) визиализируется грамматическая теория, что облегчает понимание материала;

2) дети учатся систематизировать информацию, практически использовать материал;

3) развивается творческий потенциал детей, повышается мотивация к изучению предмета;

4) с помощью интерактивных тетрадей будние уроки оживляются.

Интерактивная тетрадь отвечает требованиям государственного стандарта в силу следующих характеристик:

– информативен;

– вариативен, т.е. возможно несколько вариантов использования;

– полифункционален, т.е. способствует развитию творчества, воображения, мышления, внимания, логики и памяти ребёнка;

– имеет дидактические свойства;

– представляет собой средство для художественно-эстетического развития учащегося;

– обеспечивает игровую, познавательную, игровую, творческую и исследовательскую деятельность активность обучающихся.

Интерактивные тетради универсальны и тем, что их можно использовать с раннего возраста вплоть до окончания школы.

Возраст, с которого дети могут начать знакомство с иностранным языком условно, так как будет правильно утверждать, что у каждого он свой, поэтому точного ответа на вопрос «Со скольки лет дети могут учить английский?» нет. Но тем не менее, психологи, лингвисты и педагоги утверждают, что 3-5 лет является оптимальным возрастом для изучения иностранного языка в силу следующих особенностей развития:

- у ребёнка уже сформировались определенные навыки владения языком;

- наблюдается высокая восприимчивость ребёнка к получению новой информации;

- ведущей деятельностью и основным элементом познания мира является игра. В процессе ролевой игры можно увлекательным образом научить ребенка базовой лексике иностранного языка. Для этого нам понадобятся различные красочные книжки-раскладушки с яркими иллюстрациями членов семьи, животных, фруктов и овощей, предметов и т.д. Можно утверждать, что визуализация и ассоциативный подход – эффективные приемы изучения языка уже с раннего возраста.

Иностранный язык для дошкольников с 5 до 7 лет должен преподаваться ярко, интересно и красочно. С помощью интерактивной тетради можно с легкостью превратить урок английского языка в увлекательное занятие. В этом возрасте дети имеют достаточное представление об окружающем мире, хороший запас слов родного языка, они активно общаются со сверстниками, усваивают навыки письма и чтения, у ребенка увеличивается объем памяти. Все вышеперечисленные особенности помогают прийти к выводу о том, что в этом дошкольном возрасте дети начинают осмысленно изучать второй, не родной для них язык, поэтому если правильно сконцентрировать внимание ребенка и постараться с творческой стороны преподать иностранный язык, то можно сделать значительные успехи.

Английский язык в начальной школе – это сложный и познавательный курс, содержащий знакомство с буквами, цифрами, изучение новой лексики, знакомство с грамматическими формами и конструкциями, улучшение произношения и общения. Иными словами, программа направлена на усвоение и развитие аудирования, чтения, письма и говорения. Перед педагогом начальных классов стоит сложная задача не только сформировать у учащихся устойчивый интерес к изучению иностранного языка, но и заложить прочные основы для дальнейшего изучения. Сделать начальный курс английского языка эффективным и в то же время интересным и захватывающим помогают собранные в интерактивную тетрадь флэпбуки, разные книжечки с окошками, книжки-гармошки, карточки, которые помогают визуализировать грамматическую и лексическую теорию, развить моторику, творческий потенциал детей и быстро усвоить материал. В этом возрасте необходимо применить относительно усложненные шаблоны с словесным содержанием, карточки, наполненные схемами и конструкциями.

Как правило, ученики младших классов очень подвижны, энергичны и эмоциональны, поэтому задания в форме игр (ролевые игры являются неотъемлемой частью интерактивной тетради) позволяют направить энергию детей в правильное русло и сконцентрировать внимание на обучении. Без сомнений, применение полифункциональной интерактивной тетради способствуют развитию творчества, воображения, мышления, внимания, логики и памяти ребёнка

Интерактивные тетради могут применяться в изучении следующих разделов: грамматика, лексика, говорение.

При обучении грамматике, как и при работе с другими аспектами языка, учебный процесс проходит в три этапа: ознакомление и первичное закрепление,

тренировка, применение изучаемого материала с выходом в речь. Однако третий этап при работе над грамматическими навыками в школе опускается, при этом игнорируется коммуникативный характер отработки грамматических структур [6, 51]. В изучении грамматики ребенок, создавая интерактивную тетрадь, развивает зрительную память, которая преобладает у большинства людей. В то время как учащийся оформляет грамматическое правило или какую-нибудь конструкцию самостоятельно с помощью ярких карандашей, разноцветных бумаг, любимых наклеек он делает это с большим интересом, так как процесс создания доставляет ему удовольствие. Красиво оформленное, украшенное с душой грамматическое правило хочется повторять снова и снова. Установлено, что материал в такой форме запоминается лучше, чем любое правило из учебника. Ведь всё, что создается руками, ценнее. Таким образом, с помощью интерактивной тетради можно систематически и наглядным образом освоить такие грамматические темы как to be (глагол «быть»), to have / has got (глагол «иметь»), Plural of nouns (Множественное число существительных), There is / There are (Оборот «есть», «имеется», «находится»), Prepositions (Предлоги), Present Simple (Настоящее простое время), Past Simple (Прошедшее простое время), Future Simple (Будущее простое время), Can / Can’t (глагол «уметь», «мочь»), Like / Don't like (Нравиться / не нравиться).

Овладение большим словарным запасом крайне необходимо для изучения любого языка. Интерактивные тетради уникальны и тем, что усвоение лексики через флэпбуки, книжки-раскладушки гораздо продуктивнее, чем традиционно «зубрить» слова, которые через 2 недели забудутся. Можно утверждать, что чем больше органов чувств задействовано – зрение, моторика, слух – тем эффективнее результат. Иными словами, когда ребенок открывает интерактивную тетрадь и видит слова с соответствующими картинками, проговаривает их, он ассоциативно запоминает новую лексику. Изучение новых слов распределено по тематикам (“Family members”, “Food”, “Vegetables”, “Home”, “Travel”), тетрадь украшена красочными рисунками, ключевые слова выделены жирным цветом, чтобы при пролистывании сразу бросались в глаза. Выявлено: с помощью такой интерактивной тетради выученный материал сохраняется в долгой памяти.

Всеми известный факт: «Чтобы выучить язык, нужно, прежде всего, на нем говорить». Часто в школах для развития речи учителя задают детям выучить готовый диалог из учебника, что доставляет ученикам много усилий и труда, но приносит скудные результаты. В итоге учитель ставит оценку не столько за выработанный навык говорения, как за память учащегося. Таким образом, дети вместо того, чтобы говорить, привыкают пересказывать «вызубренный» текст. Тут мы задаемся вопросом «Есть ли более продуктивный метод?». В данном случае ролевые игры, которые являются неотъемлемой частью интерактивной тетради, производят яркое впечатление и эффективным образом развивают навыки говорения. Каждый ученик, принимая определенную роль и используя подсказки в тетради, начинает строить собственные, незаученные, уникальные диалоги, тем самым воображая себя участником реальной жизненной ситуации.

Учащимся начальных классов можно предложить игры “In the shop”, “In the cinema”, “At home”, “McDonald’s”, где в каждом из них ребенок, погрузившись в смоделированный мир, начинает выражать свои мысли на иностранном языке. Несомненно, превращая учёбу в игру, можно вовлечь интерес ребенка на процесс обучения и добиться отличных результатов.

Таким образом, внедрение интерактивной тетради способствует развитию творчества, внимания, памяти, воображения, мышления и логики. Использование таких тетрадей на уроках вовлекает всех обучающихся, позволяет сделать процесс обучения активным как для учителя, так и для учащихся.

Интерактивная тетрадь – это не просто современнный метод обучения, помогающий развить познавательную, творческую активность ученика, эффективно усвоить и повторить материал на уроке, это полёт фантазии, который в последующем может дать такие превосходные непредвиденные результаты.

**Литература**

1. Днепров Э.Д., Аркадьев А.Г. Государственная программа по английскому языку для общеобразовательных школ Министерства Образования Российской Федерации – М.: Издательство Дрофа, 2013. – 118 с.
2. Вавилова Л.Н., Панина Т.С. Современные способы активизации обучения. Учебное пособие. 4-е изд., стер. – М.: Академия, 2008. – 176 с.
3. Малышева Т.В. Влияние методов интерактивного обучения на развитие коммуникативной компетенции учащихся / Учитель в школе. – 2010 – N 4 – С. 14-16
4. Пассов Е.И. Коммуникативное иноязычное образование. – Липецк: Липецкий гос. пед. институт. – 1998. – 299 с.
5. Райс О.И., Карпенко Е.А. Интерактивные технологии в обучении. Педагогика нового времени Издательство Ridero, 2020. – 80 с.
6. Рогова Г.В. Рабинович Ф.М., Сахарова Т.Е. Методика обучения английскому языку в средней школе. – М.: Просвещение, 1991. – 287с.
7. Щукин А.Н. Методы и технологии обучения иностранным языкам. – М.: Икар, 2017. − 240 с.

# ПРОЕКТ ТЕХНОЛОГИЯСЕН ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСӘРЕНДӘ КУЛЛАНУ ЫСУЛЛАРЫ

Гаязова Д. И.
БГПУ им. М. Акмуллы
gayazova.dilyara@mail.ru

**Аннотация.** Данная статья посвящена одному из ведущих методов учебной деятельности – проектной технологии. Он дает возможность достигать дидактические цели через разработку проблемы, которая должна будет завершиться вполне реальным практическим результатом. Одно из важных предназначений метода проектов является предоставление учащимся возможность самостоятельно приобретать знания в процессе решения практических задач, которые требуют интеграции знаний по предмету родной язык.
**Ключевые слова:** Проект, проектная технология, проблема, планирование, продукт, презентация, схема, творческая работа, индивидуальная работа.

Мәктәп программасының югары сыйныфларында проект технологиясенең эчтәлеге киңәя. Бу аңлашыла да: өлкән сыйныф укучысы инде әзерлекле, эзләнү эшен мөстәкыйль рәвештә башкаруга сәләте күбрәк. Димәк, проект – ул нинди дә булса проблеманы өйрәнү һәм гамәли нәтиҗәсен күрсәтү өчен укучыларның мөстәкыйль эшчәнлегенә нигезләнгән укыту методы.

**Проект эше түбәндәге этаплардан тора:**

1. Әзерлек этабы.
2. Проектны тормышка ашыру этабы.
3. Йомгаклау этабы.

**1. Әзерлек этабында**

1. тема билгеләнә;
2. юнәлеше, максаты, бурычлар аңлатыла;
3. үтәү вакыты билгеләнә;
4. эш планы төзелә;
5. нәтиҗә-продукт, аны презентацияләү формасы билгеләнә;
6. укучыга чыганаклар белән эшләү буенча киңәшләр, күрсәтмәләр бирелә.

**2. Проектны тормышка ашыру этабы**

1. укучы шәхси бирем буенча материал эзли, җыя;
2. информацияне өйрәнә, эшкәртә;
3. проектның соңгы нәтиҗәсе – продуктны эшләп бетерә.

**3. Йомгаклау этабы**

1. проектны презентацияләү;
2. фикер алышу;
3. эшкә бәя бирү.

***Проектка төп таләпләр:***

- Проект өстендә эш ниндедер конкрет, социаль әһәмиятле проблеманы чишүгә юнәлдерелгән булырга тиеш.

- Куелган проблеманы чишүдә эшләнәчәк эшне дөрес планлаштыруның әһәмияте зур. Һәр конкрет гамәл, аның нәтиҗәсе, срогы, җаваплы кешесе күрсәтелә. Шулай ук килеп чыгачак нәтиҗә-продукт һәм презентация формасы билгеләнергә тиеш. Шул ук вакытта кайбер иҗади һәм рольле проектлар башыннан ахырына кадәр планлаштырылып бетмәскә дә мөмкин.

- Һәр проектның төп шарты – укучыларның иҗади эшләве. Проектның характерлы үзенчәлеге булып укучыларның информация эзләве тора. Информация укучы тарафыннан өйрәнелә, эшкәртелә һәм тәкъдим ителә. Укучы информацияне турыдан туры бер җирдән икенче җиргә күчереп куярга гына тиеш түгел, үзенең фикерен дә белдерергә тиеш.

- Проектның нәтиҗәсе булып укучыларның куелган проблеманы чишкәндә булдырган эш продукты тора.

- Һәр проект үзенең тәмамлау этабында продуктны презентацияләү һәм яклаудан торырга тиеш. Димәк проект эше түбәндәге тәртиптә бара:

**Проблема – Планлаштыру – Информация эзләү – Продукт – Презентация**

Проектны эшләү барышында аның портфолиосы барлыкка килә. Бу – бөтен эш материаллары тупланган папка.

Еш кына уңышлы башкарылып чыккан проектларны төрле фәнни-гамәли конференцияләрдә тәкъдим итү мөмкинлеге туа. Фәнни эш белән шөгыльләнү укучыны күп нәрсәгә өйрәтә: уйлау мөмкинлекләре киң ачыла, логик фикерләү дәрәҗәсе үсә, төрле чыганаклар белән мөстәкыйль рәвештә, алдагы нәтиҗәсен күреп эшләргә өйрәтә.

Укучылар фәнни-гамәли конференциядә уңышлы чыгыш ясасын өчен аларда башта эзләнүчәнлек сәләтен үстерегә кирәк:

**1 этап:** диагностика (балаларның мөмкинлекләре ачыклана), фәнгә сәләтле укучылар сайлана;

**2 этап:** эзләнү өчен шартлар тудырыла;

**3 этап:** индивидуаль консультацияләр;

**4 этап:** проект өстендә эш, планлаштыру, чыганаклар белән танышу һәм алар өстендә эш, эш нәтиҗәләрен язарга һәм анны якларга өйрәтү;

**5 этап:** йомгак, анализ ясау.

Укучылар белән фәнни-тикшеренү темасын сайлаганда, аның актуальлегенә, өйрәнелү дәрәҗәсенә, чыганаклардан һәм фәнни әдәбияттан файдалана алу мөмкинчелеген, укучының кызыксынуын истә тотарга киңәш ителә.

Балалар белән фәнни-тикшеренү эше барышында без түбәндәге **максатларны** күз алдында тотабыз:

1. Фән белән кызыксынуны арттыру;
2. Фәнни-тикшеренү эшенә өйрәтү;
3. Тәнкыйди фикерләү һәм анализлау сәләтен үстерү;
4. Патриотик тәрбия бирү.

Фәнни–тикшеренү эше алып бару **алгоритмы;**

1. Тема сайлана;

2. Тема буенча мәгълүмат җыю, аны эшкәртү һәм системалаштыру;
3. Фәнни-тикшеренү эшенә таләпләр белән танышу;
4. Эшкә максат куела;
5. Максатка ирешү өчен бурычлар билгеләнә;
6. Шул бурычлардан чыгып, фәнни хезмәтнең эчтәлеге төзелә;
7. Максатка ирешү юлы модельләштерелә [2:112].

Модельләштерүнең максаты булып фәнни-теоретик фикерләрне формалаштыру, барлык тикшерелгән материалларны бер калыпка салу тора.

Фәнни эшнең **нәтиҗәсе** булып, укучының:
1. Конференцияләрдә катнашуы;
2. Фәнни газета журнал һәм җыентыкларда бастырылуы;
3. Махсус күнекмәләр барлыкка килү.

Укучыларның фәнни хезмәтләренә куела торган **таләпләр:**

**1.** Фәнни хезмәт басма рәвештә 12-15 биттән артмаска, электрон варианта да булырга тиеш.

**2.** Эчтәлек, кереш, төп өлеш, нәтиҗә, кулланылган әдәбият һәм фәнни хезмәтнең тезисы бырга тиеш;

**3.** Рәсем, схема, фотосурәтләргә исем бирергә, битләрне нумерацияләргә тиеш.

Фәнни эшнең **бәяләнү критерийлары**
1. Теманың актуаль булуы;
2. Максат һәм бурычларның дөрес куелуы;
3. Кулланылган әдәбият һәм чыганакларның 3 тән ким булмавы;
4. Эзләнү, яки эксперимент, нәтиҗә яки тәкъдим өлешләре булуы;
5. Фәнни эшнең оформление буенча таләпләргә туры килүе;
6. Укучының эшен яклау моменты 5-7 минуттан артмаска тиеш [3:161]

Проект методын дәресләрдә, класстан тыш уку дәресләрендә һәм класс сәгатьләрендә кулланырга мөмкин. Татар теле дәресләрендә проект методын куллану укучыларны эзләнүгә тарта, димәк – укучылар фән белән күбрәк кызыксына башлый, телне тирәнтен өйрәнә.

Башлангыч һәм урта сыйныфларда укучылар белән гадиләштерелгән проектлар төзү уңышлырак. Бу яшьтәге балалар рәсем төшерергә, фотоальбомнар төзергә ярата. Югары классларда проектларның формасы һәм эчтәлеге катлаулана, аларны төзүдә фәнни якын килү практикалаша, проектларны булдыруга күбрәк вакыт бирелә. Проектларны булдыру процессында укучыларда түбәндәге белем һәм күнекмәләр үсеш ала:

- гомум белем бирү күнекмәләре: дәреслек, сүзлекләр, өстәмә әдәбият белән эшләү; план, доклад, мәгълүмат, тема буенча чыгышлар төзү;
- махсус күнекмәләр: текстны кыскарта белү; лексиканы сайлап алу; кыскача язмалар ясау һ.б.

Фәнни-эзләнү эше бала шәхесен үстерүдә уникаль метод, баланы һәм укытучыны үстерүче, югары кимәлдә гомум күзаллауны һәм белем бирүне формалаштыручы нәтиҗәле укыту процессы булып тора. Кешене гомерлеккә өйрәтеп булмый, әмма аны гомер буе өйрәнергә өйрәтү мөмкин. Проектлар

технологиясе һәм фәнни-эзләнү эшчәнлеге әлеге максатка ирешүдә методиканың беренчел баскычлары, чөнки укытуның бу методлары укучыда ачкыч компетенцияләрне формалаштыруга булышлык итә. Укучыларның фәнни-эзләнү эшчәнлеген дөрес итеп оештыру һәм профессиональ-педагогик ярдәм итү исә иҗтимагый институт булып торган һәр мәктәпнең төп максаты.

**Әдәбият**


1. Вәлиева Ф.С. Татар теле дәресләрендә техник чаралардан файдалану. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1972. – 119 б.
2. Гриценко Л.И. Теория и практика обучения: интегративный подход. – Казан: Мәгариф, 2008. – 112 с.
3. Кузнецов А. А., Пинский А. А., Рыжаков М. В., Филатова Л. О. Структура и принципы формирования содержания профильного обучения на старшей ступени. – М., 2003. – 161 с.
4. Сафиуллина Ф.С. Татар телен рус теле белән чагыштырып өйрәнү. – Казан: Мәгариф, 1996. – № 3. – Б. 12-14.

## ТУГАН ТЕЛГӘ ӨЙРӘТКӘНДӘ ЗАМАНЧА ҺӘМ ИННОВАЦИОН ТЕХНОЛОГИЯЛӘРНЕ КУЛЛАНУ

Гомәрова Г.А.
Казан шәһәре Совет районы«171нче гомуми урта белем бирү һәм аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү мәктәбе»
galinagumarova@mail.ru

**Аннотация.** Гасырлар алышынганда кешелек узганга нәтиҗә ясый, киләчәккә планнар кора. Бу традиция белем бирү сферасын да читләтеп узмый. Бүген белем бирү системасын камилләштерү, укучыларның белем сыйфатын үстерүнең төрле юллары, методлары эзләнелә.
**Төп сүзләр:** заманча технология, татар теле, укыту.

Җәмгыятькә талантлы, иҗади фикерли, аралаша белүче, инициативалы гражданнар сорала. Укып алган диплом гына тормышта үз урыныңны табуга гарантия була алмый. Мәктәп бусагасын атлап чыгучы кешенең җаваплылык хисе, дисциплина, белем күтәрүгә омтылыш, эзләнүчәнлек кебек сыйфатларга ия булырга тиешлеген бөтенебез беләбез. Мәктәпләрдә шундый шәхесләр тәрбияләүгә укучы шәхесенә юнәлдерелгән яңа педагогик технологияләр куллану ярдәм итә.

Бүгенге көндә илебездә дөнья мәгариф тирәлегенә керүгә юнәлтелгән мәгариф системасы урнаша бара. Бу эш укыту-тәрбия процессына зур үзгәрешләр кертүне таләп итә. Белем бирү программалары үзгәртелә, белем эчтәлеге яңа күнекмәләр белән баетыла, мәгълүмат туплауның гадәти ысуллары – телдән һәм язма сөйләм компьютер чаралары белән алмаштырыла. Яңа технологияләр ярдәмендә белем бирү укучыны тагын да активлаштыра, анда мөстәкыйльлек тәрбияли. Ә инде компьютер технологияләрен куллану фәнне югары дәрәҗәдә үзләштерү, максатка омтылучанлык, информацион технологияләр дөньясындагы яңалыклар белән кызыксыну теләге уята.

Заман таләпләре бүгенге көндә туган телне укыту процессында зур үзгәреш сорый. Мәктәптә белем бирүче мөгаллимнәр алдында бик тә җаваплы һәм әһәмиятле бурыч тора. Беренчедән, белем һәм тәрбия бирү бурычы булса, икенчедән, фәнне өйрәнүгә кызыксынуны бетермәү, киресенчә, бу кызыксынуны үстерү бурычы тора. Бу укытучыдан зур һөнәри осталык, түземлелек һәм заман таләп иткәнчә, югары технологияләрдән, мәгълүмати чаралардан хәбәрдар булуын таләп итә. Бүгенге көн укытучыдан иҗади эшли белүне таләп итә. Педагогик эшчәнлектә иҗадилык - бу, беренче чиратта, яңалыкка, үзгәрүчәнлеккә омтылу. Җәмгыятьтәге үзгәрешләрне уңай кабул итү өчен, укытучының заман белән бергә атлап баруы мөһим. Тәҗрибә педагогик эшчәнлекнең нигезе булса, яңалыкка омтылу үсеш - үзгәрешне тәэмин итә. Бүген укытучы, иҗади шәхес буларак, күп укырга, төрле өлкәдәге яңалыклар белән таныш булып кына калмыйча, яңа педагогик технологияләрнең иң нәтиҗәлесен сайлап алып, үзләштереп, эшли белергә дә тиеш. Заманча технологияләр файдаланып белем бирү түбәндәге мөһим

бурычларны үтәргә ярдәм итә: укучыда фәнгә кызыксыну уята; аның танып белү активлыгын үстерә; укучыларның иҗади мөмкинлекләрен камилләштерә; белемнәрне тирәнәйтә.

Дәресләрендә заманча инновацион технологияләр кулланып укытуның максатлары булып түбәндәгеләр тора:
- белем биру процессының нәтиҗәлелеген үстерү;
- укыту нәтиҗәләре өчен җаваплылыкны, белем алуга кызыксынуны арттыру;
- укучыларны киләчәк тормышка әзерләү;

Яңа мәгълүмати технологияләрдән файдалану фәннилек, күрсәтмәлелек, аңлаешлылык, активлык һәм мөстәкыйльлелек кебек дидактик принципларны гамәлгә ашыру мөмкинлеге бирә. Бу очракта укытуның телдән сөйләү, күрсәтмә һәм гамәли методлары кулланыла.

Заманча инновацион технологияләр куллану кызыксынучанлыкны арттыра, белем сыйфатына, уку-укыту нәтиҗәлелегенә, укучының шәхес булып тәрбияләнүенә йогынты ясый. Бу җәһәттән, яңа мәгълүмати технологияләр үзләре үк танып белү, белем туплау коралына әверелә, гомумиләштерү, эзләнү, үстерү, дәртләндерү, тәрбияви һәм контрольгә алу, төзәтмәләр кертү функцияләрен үти. Әмма әлеге яңа мәгълүмати технологияләр телне үзләштерүне тулысынча алыштыра алмый, ә бары тик дәрескә файдалы өстәмә, укучылар һәм укытучылар өчен үзлектән белем алуда үтемле чара булып тора ала.

Заманча инновацион технологияләрне дәресләрдә уңышлы куллану өчен кирәкле җиһазлар, компьютерда эшли белү осталыгы, электрон өйрәтү материаллары һәм Интернеттан алынган материалларның булуы кирәк. Дәрестә укыту формаларын һәм ысулларын төрләндерү дәреснең эчтәлеген баерак һәм кызыклырак итә. Бүгенге көндә мәктәпләрдә мөмкинлекләргә ия булган интерактив такталар җиһазландырылган компьютер сыйныфлары бар. Без бу өлкәдә булган яңалыклар белән танышып, аларны үз эшебездә кулланырга тырышабыз. Әмма һәрбер дәресне дә информацион технологияләр кулланып үткәреп булмый, мондый дәрескә әзерлек укытучыдан күп вакыт та таләп итә.

Дәресләрдә заманча инновацион технологияләрне куллануның өстенлекле яклары күп. Бу метод укучыларны компьютер белән эшли белергә, текст процессоры ярдәмендә төрле документлар, график программалар, иллюстрацияләр әзерләргә, гади программалар төзергә, электрон почтадан һәм интернеттан дөрес файдаланырга өйрәтә.

Дәресләрдә басма күрсәтмә материаллар күп булмаганда, укучылар интернет челтәренә чыгып, сайтлардан төрле кызыклы материаллар бастырып алалар. Белемнәрне тикшерү дәресләрендә файдалану өчен төрле программада тестлар әзерләүдә дә укучылар ярдәм күрсәтәләр. Тестны эшләп бетергәч, компьютер нәтиҗә ясап, билге куя.

Дәресләрендә куллану өчен презентацион программалар бик кулай. Power Paint программасында төрле иллюстрацияләр эшләргә, принтер аша чыгарып, һәр укучыга таратып та бирергә була. Бу эшләрне дә укучылар бик

теләп башкара. Укчылар мөстәкыйль презентацияләр эшлиләр. Шулай ук видео техниканы куллану да отышлы. Түбән сыфныф укчылары мультфильмнар караргa бик яраталар. Компьютер презентацияләреннән файдалану күрсәтмә материалны куллануны үстерә, предметара элемтәне ныгыта, дәреснең җитештерүчәнлеген арттыра, укытучы һәм укучы мөнәсәбәте ныгый. Информацион технологияләрне катнаш дәрестә, дәрес-лекциядә, проект яклаганда, семинар-дәрестә дә кулланырга була.

Шуны да әйтергә кирәк, дәрестә компьютер куллану белән артык мавыгырга да ярамый, чөнки ул укытучы белән укучының үзара аңлашуын, аралашуын алыштыра алмый. Компьютер соңгы елларда уку процессында актив кертелгән яңа һәм иң мөһим чараларның берсе булып тора. Аны куллану яңа информацион технологияләр барлыкка килүгә ярдәм итә. Компьютер технологиясе – компьютер мөмкинлекләрен файдаланып, өйрәнүчегә информацияне әзерләү һәм тапшыру процессы ул.

Алда әйтелгәннәрдән нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: педагогика фәнендә укыту-тәрбия процессы сыйфатын үстерергә булышлык итүче технологияләр шактый. Укытучының бурычы - яңалыклар агымында югалып калмыйча, дөрес юнәлеш алу, укытуның һәр этабы өчен уку материалын аңлатуның иң уңышлы вариантын табу. Шул ук вакытта аларның бер-берсе белән ярашырга тиешлеген дә онытмау зарур. Дәресләрендә мәгълүмати технологияләрне куллануньң өстенлеге бәхәссез. Барыннан да элек алар – шәхескә юнәлтелгән ныклы һәм вариатив. Төрле технологияләр, компьютер, мультмедиа технологияләре күрсәтмәлелекне, контрольлекне тәэмин итеп һәм күп мәгълүмат биреп, укытуның сыйфатын күтәрергә ярдәм итә, этәргеч бирә. Заман таләбе буенча, укучыларның компьютер технологияләренә булган кызыксынуларын истә тотып, дәресләрендә компьютер технологияләрен куллану бик отышлы дип саныйм мин. Информацион технологияләрне куллануның өстенлекле яклары күп: дәрес материалы югары күрсәтмәле дәрәҗәдә була, укучының шәхси сыйфатын ачыкларга мөмкинлек бар, төрле дәресләрнең үзара бәйләнешен булдыру, дәрес укыту формаларын һәм ысулларын төрләндерү дәрес эчтәлеген баерак һәм кызыграк итә.

Дәресләрендә заманча инновацион технологияләр куллану укучыларда фәнне тагын да ныграк өйрәнүгә кызыксыну уята һәм мәгълүмати җәмгыятьтә яшәргә әзерлек булып тора.

**Әдәбият**

1. Лехтина Л.П. Педагогика буенча информацион коммуникатив технология модельләре [электрон ресурс]

2. Морозов К.А. Информационно-коммуникативные технологии и их применение в педагогической деятельности// Личность, семья и общество: вопросы педагогики психологии: сб.ст. по матер.XXX междунар. науч.-практ. конф. – Новосибирск: СибАК, 2013.

# ТАТАР ТЕЛЕН ЧИТ ТЕЛ БУЛАРАК ӨЙРӘТҮ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ЛЕКСИКАНЫ ҺӘМ ГРАММАТИКАНЫ АКТИВЛАШТЫРУ

Гыйләҗева Л.Г.
ГАОУ ДПО “Институт развития образования РТ”
glg4@yandex.ru

**Аннотация.** Цель изучения лексики – развитие практических речевых умений и навыков учащихся. Основная трудность при этом – овладение учащимися реальным словарным запасом, который должен в результате усвоения превратиться в активный словарный запас каждого учащегося. В статье рассматриваются методы и приемы обучения лексике на уроках изучения татарского языка как государственного.
**Ключевые слова:** лексика, активная и пассивная лексика, методы и приемы обучения лексике.

Чит телне белү – телнең лексик системасын белү һәм аларны сөйләмдә куллана алу ул. Чит телне үзләштергәндә укучыларда актив һәм пассив сүзлек формалаша. Әлеге ике катлам лексиканың үзара мөнәсәбәте укыту максаты һәм укуга бирелгән вакыт кебек факторлар белән билгеләнә. Вакыт ягыннан чикләүләр сүзлек минимумына иң еш кулланыла торган лексиканы гына кертергә мәҗбүр итә. Чит телдә актив һәм пассив сүзләр арасында чикләр туган телдәге кебек хәрәкәтчән түгел.

Укучыларның актив һәм пассив сүзлек запасына лингвистик характеристика дәрестә үтелергә тиешле булган лексиканы сайлап алу өчен зур әһәмияткә ия булса, психологик яктан укыту методикасын эшләү өчен бик мөһим. Лексиканы өйрәтү укытуда дифференциацияләнгән якын килүне таләп итә, мәсәлән, сүзләрне аңлатуның һәм ныгытуның төрле методларын һәм алымнарын куллану, төрле типтагы күнегүләрне эшләү.

На уроках учитель применяют поисковый, исследовательский, проблемный методы, применяет следующие приемы, как наблюдение, сравнение, сопоставление. Использование ИКТ технологий формирует и развивает учебно-познавательные компетенции, усиливает мотивацию к изучению предмета. У обучающихся повышается уровень обученности, развиваются коммуникативные способности.

Информационно-коммуникационные технологии при построении урока с применением электронных образовательных ресурсов (ЭОР) выступают в роли инструмента добывания знаний и добавляют больше самостоятельности, активности в деятельность учащихся, что особенно актуально в условиях новых ФГОС.

В последние годы произведения татарских писателей представлены в сети Интернет: в электронных библиотеках, на сайтах журналов, в образовательных порталах. Доступны статьи, находящиеся в архивах, всегда можно познакомиться с новинками и критическими публикациями, становясь осведомленным в вопросах поэзии, прозы современности.

Много сайтов, организующих изучение татарского языка, предлагающих on-line словари. Все эти материалы можно с большим успехом применять на уроках татарского языка и литературы. Есть научно- популярные статьи, которые требуют глубокого осмысления учителем, прежде чем ее содержание преподнести детям. Есть ресурсы, информацию с которых можно применить в готовом виде. Мультфильмы, снятые по известным поэтическим произведениям татарских поэтов, таких как «Эшкә өндәү», «Эш беткәч уйнарга ярый», «Яңгыр илә кояш», «Шүрәле» по произведениям Г. Тукая, «Куян кызы», и др., переведенные на татарский язык, которых можно посмотреть в YouTube http://www.youtube.com/watch?v=dVj6GWXpjoc на уроках при прохождении соответствующих тем (дружбы, доброты, трудолюбия, милосердия, взаимопомощи).

Организация и проведение нестандартных уроков повышают эффективность обучения, развивают активность, самостоятельность, личную инициативу и творческие способности учащихся.

Большую роль в активизации познавательной деятельности обучающихся играет внеурочная деятельность, связанная с поисковой работой. В течение пяти лет я руковожу школьным кружком «Юный краевед», воспитанники которого принимают участие в научно-практических конференциях и занимают призовые места. Исследовательская, проектная деятельность учащихся всех классов – неотъемлемый атрибут методики преподавания родного языка, также успешен в преподавании неродного языка. Проекты школьников разнообразны по виду, типу, условиям, результатам и т.п. В них рекомендуется широко использовать национально-региональную специфику (обычаи, традиции, праздники народного календаря), позволяющую повысить познавательный интерес школьников к национальной культуре. Результаты проектной деятельности школьников оформляются в виде альбомов, бизнес-планов, выставок, газет, книжек-раскладушек, сценариев праздников, спектаклей.

Сегодня, чтобы уверенно ступать на пути педагогического поиска, нужно многое знать в педагогике, надо осваивать новые программы, методы и технологии обучения.

В процессе формирования речевых умений создается комплекс упражнений, например, упражнения, направленные на формирование умения раскрывать тему и основную мысль высказывания; упражнения, направленные на формирование умения выражать свои мысли правильно (с точки зрения норм литературного языка); упражнения, направленные на формирование умения строить высказывание в определённой композиционной форме.

Одним из эффективных путей повышения творческой активности, развития воображения, заинтересованного отношения к изучаемому предмету при коммуникативно-направленном обучении является организация различных игр, особенно ролевых, таких, как «В библиотеке», «В магазине», «В гостях» и др. Методически правильно продуманная игра, с одной стороны, пробуждает у учащихся интерес к изучаемому языку, помогает развивать навыки говорения, приближает речевую деятельность к естественным нормам, а с другой –

способствует плодотворной работе над языковым материалом и отвечает требованиям коммуникативной направленности обучения.

Исходя из поставленных учебных целей, языковой подготовки обучаемых, потенциальных возможностей восприятия и усвоения материала учащимися в пределах одного урока, используются такие методы, как аудиовизуальный, словесный, программированный, ознакомительный, тренировочный. Методы применения изучаемого языка в коммуникативных целях: проговаривание – комментирование учащимися вслух своих действий, взаимная проверка заданий, рецензия, разбор своей работы после проверки ее учителем или после выполнения, диалог учеников класса с учеником, выполняющим работу у доски.

Однако в целях сбережения здоровья учащихся учитываются возрастные особенности, использование средств обучения, учебная нагрузка, прослеживается двигательная активность учащихся, состояние здоровья подрастающего поколения.

Использование современных технологий обучения, компетентное владение ИКТ, нетрадицонные уроки, внеурочная деятельность дает успешный результат.

**Литература**

1. Апатова Н.В. Информационные технологии в школьном образовании. - М., 1994.
2. Беспалько В.П. Педагогика и прогрессивные технологии обучения. - М., 1995.
3. Воронкова, Ю.Б. Информационные технологии в образовании / Ю.Б. Воронкова. - РнД: Феникс, 2010. - 314 с.
4. Захарова, И.Г. Информационные технологии в образовании: Учебник / И.Г. Захарова. - М.: Академия, 2013. - 192 с.
5. Захарова, И.Г. Информационные технологии в образовании / И.Г. Захарова. - М.: Academia, 2017. - 48 с.
6. Роберт И.В. Современные информационные технологии в образовании. Дидактические проблемы, перспективы использования. – М.: Школа-Пресс, 1994.

# Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «КАЗАК КЫЗЫ» РОМАНЫНДАГЫ ТЕЛ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕН УРТА МӘКТӘПТӘ ӨЙРӘНҮ

Насипов И. С., Рамазанова А. Р.
Башкирский государственный педагогический университет им. М. Акмуллы
nasipov2021@yandex.ru, ramazanovaalina1997@mail.ru

**Аннотация.** Данная статья посвящена рассмотрению изучения языковых особенностей романа «Дочь степи» Г. Ибрагимова в средей школе. Для раскрытия основной проблемы в работе представлена краткая информация о романе и самом писателе. При анализе языковых особенностей был представлен лексический состав слов в романе, примеры из текста произведения, показана их роль в описании быта и жизнедеятельности казахского народа.
**Ключевые слова:** языковые особенности, местный говор, хозяйственная деятельность, продукты, домашняя утварь, одежда.

Татар әдәбияте классигы Г. Ибраһимов әдәбият һәм тел мәйданында зур урын алып тора. Ул 1905 елгы революция тәэсирендә башланган иҗтимагый-политик күтәрелеш чорында килеп керә һәм татар халкының иҗтимагый аңы үсешендә, әдәбияты, теле һәм сәнгатенең формалашу тарихында тирән эз калдыра. Г. Ибраһимов үзенең игътибарын, җәмгыятьне рухи яктан яңарту һәм аның үсешен тәэмин итү чарасы буларак, эстетик проблемалар, шәхси эстетик тәрбия бирү мәсъәләләренә юнәлтә. Ул үзенең әсәрләрендә яшь буынның матурлыкка, рухи үсешкә омтылуын, әдәбиятка һәм сәнгатькә эстетик караш уянуны тасвирлый [3, 39-40]. Аның әсәрләре кешене һәм табигатьне ярату хисләре белән сугарылган. Язучы буларак, Г. Ибраһимов татар әдәби процессы үсешендә зур урын алып тора. Шуңа күрә аның иҗатын урта мәктәптә өйрәнү бик тә әһәмиятле роль уйный.

Әлеге вакытта мәктәп программаларына күз салсак, мондый күренешне күрәбез: ФГОС таләпләре буенча 5 нче сыйныфта Г. Ибраһимовның иҗатына 2 сәгать бирелә, 7 нче сыйныфта – 2 сәгать, 9 нчы сыйныфта – 3 сәгать, 10 нчы сыйныфта – 3 сәгать, 11 нче сыйныфта – 2 сәгать. Татар әдәбияты дәресләрендә укучылар Г. Ибраһимовның тормыш юлы, иҗаты белән таныша, аерым әсәрләренең эчтәлеген, хикәяләрдә мәхәббәт, табигать һәм сәнгать культын, әсәрдәге социаль-сәяси тормыштагы булган үзгәрешләрне, аларның иҗтимагый-сәяси һәм иҗади фикергә йогынтысын өйрәнәләр. Ләкин укытучы махсус рәвештә әсәрнең эчтәлеге, геройларның характерлы сыйфатларына гына түгел, аның тел байлыгына да игътибар юнәлтергә тиеш. Әдәби әсәрдәге тел үзенчәлекләрен өйрәнүнең мөһимлеген һәм әдипнең осталыгын күрсәтер өчен, без 11 нче сыйныфта Г. Ибраһимовның «Казак кызы» романына тукталабыз.

XX йөз башында әдәби телне демократлаштыруда һәм аны бердәм нормаларга китерүгә Г. Ибраһимов актив катнаша. Башка әдипләрдән аермалы буларак, ул үзенең эшчәнлеген төп ике юнәлештә алып бара. Беренчедән, ул,

күренекле тел галиме буларак, әдәби телнең фонетик, орфографик, лексик, грамматик нормаларын чагылдырып, тел белеменә караган хезмәтләр яза, шулай татар тел гыйлеменә зур өлеш кертә. Икенчедән, Г. Ибраһимов телнең эчке мөмкинлекләреннән, халыкның җанлы сөйләменнән файдаланып, әдәби тел нормаларын киң халык массасына җиткерүдә зур эш алып бара. Ягъни ул әдәби тел нормаларын матур әдәбият әсәрләре аша гамәли яссылыкта файдалана.

Әйткәндәй, Г. Ибраһимов «Казак кызы» романында оста язучы буларак казах тормышын да төрле тел үзенчәлекләре аша чагылдыра. Боларны мәктәп укучысына ачып бирүдә укытучы эш алып барырга тиеш, дип саныйбыз.

«Казак кызы» романы – татар әдәбиятының иң күркәм бер үрнәге, классик әдип Галимҗан Ибраһимов иҗатының матур бер җимеше буларак танылган әсәр. Анда татарларга кардәш халыклардан булган казахларының XIX гасыр ахыры–XX гасыр башындагы тормышы чынбарлыкта чагылдырылган. Романның сәнгати үзенчәлекләрен аның теле дә билгели.

Аеруча идея-сәнгать функцияләрен «Казак кызы» романында кулланылган сүзлек составы да үти. Алар арасында архаизмнар зур урын алып тора. Хәзерге татар телендә искергән сүзләр, барыннан да элек, узган вакыйгаларның картиналарын торгызу һәм авторлык позициясен белдерү өчен кулланыла. Әйтик, мондый сүзләр романда тарихи стильләштерү вазыйфасын да үти. Аларның кайберләре, чорның гомуми тел колоритын булдыруга ярдәм итеп, төрле сөйләм контекстларына иркен үтеп керәләр. Автор сөйләмендә *ләкап, күҗә, амал, гуй, лазем, аял, әкә, чал* һ.б. лексик берәмлекләр очрый. Укытучыга шуңа да игътибар итәргә кирәк: роман XX йөз башында язылып, 100 елга якын вакыт кичергән. Аңлашыла ки, бу чорда кайбер лексик берәмлекләр искереп, үзләре үк бүгенге укучыга чит-ят булып тоелырга мөмкин. Чөнки телебез өзлексез үсештә, үзгәрештә.

Г. Ибраһимовның «Казак кызы» романында, татар лексемалары белән беррәттән, казакъ сүзләре дә кулланылган. Әлбәттә, бу исә Г. Ибраһимовның чынбарлыкка, телгә, халыкларның мәдәни традицияләренә ни дәрәҗәдә игътибарлы булуын тагын бер кат раслый. Мәсәлән, ***Чалның** тапкырлы кинаясе мәҗлеснең хушына китте* [2, 32]. *Ил агасы өлкән аксакал Биремҗан **әкә**моны куәтләп алды* [2, 32]. *Ул гайбәтче **кимперләрдән** кайбер нәрсә ишеткән иде* [2, 37]. ***Аяллыгың** барма, күп гомер эчендә яманын да, яхшысын да күрми амал юк!*[2, 40] *Үзем карт **кимпер**, балалар яшь...* [2, 51]. Тик шунысы да ассызлыклау тиешле: роман татар әдәби телендә татар укучысына дип язылган. Шуңа күрә әсәрдә казах теле лексемаларын куллануда автор чама белеп эш итә.

Г. Ибраһимовның «Казак кызы» романындагы тел үзенчәлекләре **халыкның җирле сөйләмендә, геройларның телендә** (*Азым әкә! Сары биянең җаен тапмый торабыз. Бире килсәңче*!); **табигатьне сүрәтләүдә** (*Бу калкуның өстенә чыгу белән, картның күз алдына эзләп килнән җәйләвенең бөтен ягы ачылды. Күлләре юк яки кайчандыр булып та корыган. Хәзер аның урынына малга да, адәмгә да файдасыз бер кызгылт үлән үсеп килә. Тик урыны-урыны*

*белән генә әйбәт яшеллекләр күренә* [2, 53]); **казах халкының киемендә** (*Аягына иске читек-кәвеш, өстенә изүе бау белән бәйләнгән, якасы кире кайтарылган озын ак күлмәк, аның өстеннән төя җонынннан сугып, кыл катнаштырып эшләнгән зур көпе кигән, зур буйлы, бөркет танаулы, озын ак сакаллы, ләкин ябык, кипкән тәнле бу баба кунакның эзләп килгән мәшһүр Биремҗан аксакалы иде* [2, 47]); **өй җиһазларында** (*Җир идәннең күп җире ачык, тик түргә генә бераз киез түшәлгән, кирәгә буенда буяулары югала башлаган берничә сандык, алар өстендә берничә юрган, келәм, сул якта бер камыт, кибеп ауган буш саба, күптән кымызга тимәгән пешкәк, керле самавыр, берничә табак – менә өйнең бөтен җиһазы шул иде* [2, 47]); **ашамлыкларында** (*Туктының симезләре суелды, кымыз мул куелды, байбичәгә, кунакларның кадерен белеп, бик сирәк ашлардан булган куырдак, көйгән бөйрән кебек сыйлар хәзерләтте* [2, 134]. *Эремчек эшен бетереп, киезгә тотынган Айбала...* [2, 49]. *Җылкычы ата аңа берничә кисәк казылык, дүрт кабырга, бер майлы бөер, бераз җәймә салды да: "Алыгыз" - диде* [2, 77]) һ.б. чагылдырыла.

Шулай ук укычыга әсәрдәге искә алынган тарихи вакыйгаларга, кеше исемнәренә, топонимик атамаларга, җирле табигый рельеф, һава шартларын белдерүче сүзләргә һ.б. игътибар итү кирәклегенә укытучы басым ясарга тиеш.

Димәк, Г. Ибраһимовның «Казак кызы» романындагы тел үзенчәлекләрен табып эшләү укучыга әсәрнең эчтәлеген төгәлрәк аңларга, геройларның характерларын, аларның бер-берсе белән мөнәсәбәтләрен, барган вакыйгаларның урынын, авторның стилен тасвирларга ярдәм итә. Бу исә укучыларга әсәргә төгәл һәм дөрес анализ ясарга мөмкинлек бирә.

Шулай итеп, Г. Ибраһимов татар матур әдәбият стилен үстерүдә һәм аны төрле тасвири сурәтләр белән баетуда зур эш башкарган әдип. Аның иҗаты XX йөз татар әдәбиятында иң үзенчәлекле дип санарга урын бар. Ул үзенең геройлары, фәлсәфи карашлары һәм, әлбәттә, үзенең теле белән башка авторлардан аерылып тора.

### Әдәбият


1. Ибрагимов Г. Г. Казакъ кызы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 191 б.
2. Ибраһимов Г. Г. Казакъ кызы: хикәяләр, роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. – 384 б.
3. Поварисов С. Ш. Педагогическая эстетика: учебное пособие / С. Ш. Поварисов. – Уфа: РИЦ БашГУ, 2016. – 340 с.
4. Хаков В.Х. Мәктәптә татар язучыларының тел үзенчәлекләрен өйрәнү: Тел-әдәбият укытучылары өчен ярдәмлек. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 144 б.

# СХЕМАЛЫЛЫК ЭШ ТЕХНОЛОГИЯСЕ КУЛЛАНУ БУЕНЧА ТИКШЕРЕНҮ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Нәбиева Я.К.
МБОУ Васильевская СОШ №2 имени Героя Советского Союза Николая Соболева ЗМР РТ, учитель начальных классов
yasmina.nabieva@mail.ru

**Аннотация.** В статье рассказывается об опыте работы с учащимися на уроках радного (татарского) языка с помощью схем.
**Ключевые слова:** схема, технология, родной (татарский) язык, учащиеся.

Схемалылык эш технологиясен кулланып 4 нче сыйныф укучылары белән ике дәрес дәвамында эксперимент үткәрелде. 20 бала алынды, алар өлгереш дәрәҗәсе буенча ике төркемгә бүленеп каралды. Һәр төркемдә 10 бала.

Беренче төркем укучылары эксперименталь төркем, ә 2нче төркем укучылары – контроль төркем укучылары буларак каралды. Аларда бер үк тема, бер үк материал нигезендә үтелде, әмма эш төрләрендә аермалар булды.

Эксперимент өчен “Билгесез үткән заман хикәя фигыль” темасы алынды. 1 нче дәрестә яңа тема өстендә эшләдек, 2 нче дәрестә теманы үзләштерү өстендә эш алып барылды, 3 нче дәрестә тест формасында белемнәрен тикшердем.

Дәреснең максатлары ике төркем өчен дә бер үк:

1. - ган/ - гән, - кан/-кән формалы фигыльне актив сөйләмгә кертү;
2. Үткән заман фигыль кушымчаларын дөрес язу күнекмәләрен формалаштыру;
3. Әхлаклылык сыйфатларын тәрбияләү. Г. Тукай иҗатына мәхәббәт тәрбияләү.

Җиһазлау – 1 нче төркем өчен : мультимедия аша күрсәтү өчен материаллар (Г.Тукай портреты, “Су анасы” мультфильмы, дәрес темасына караган слайдлар, “Ак чәчәк” уены өчен карточкалар, дәреслек (Р.З.Хәйдарова Татар теле һәм уку китабы. Рус телендә белем бирүче дүртеллык башлангыч мәктәпнең 4 нче сыйныфы өчен дәреслек)

2 нче төркем өчен: дәреслек (Р.З.Хәйдарова Татар теле һәм уку китабы. Рус телендә белем бирүче дүртеллык башлангыч мәктәпнең 4 нче сыйныфы өчен дәреслек)

“Билгесез үткән заман хикәя фигыль” темасы өстендә эшләгәндә, беренче төркемдә төрле терәк схемаларны, рәсемнәрне, таблицаларны, мультфильмны мультимедиа аша күрсәтеп, индивидуаль карточкалар кулланып үткәрдек. Ә икенче төркемдә бары тик дәреслекне һәм эш дәфтәрләрен кулланып үткәрдек.

Укучыларның теманы ни дәрәҗәдә үзләштергәнен анализлау өчен тест үткәрелде.

Эшләнелгән тест нәтиҗәләреннән чыгып, һәр төркем теманы ни дәрәҗәдә үзләштергәнен анализладык.

| Тест нәтиҗәләре | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 нче төркем | | | | | | | 2 нче төркем | | | | | | |
| укучы саны | 5 | 4 | 3 | 2 | Сыйфат % | Өлгереш % | укучы саны | 5 | 4 | 3 | 2 | Сыйфат % | Өлгереш % |
| 10 | 6 | 3 | 1 | - | 90% | | 10 | 1 | 4 | 5 | - | 50% | |

Теманы 1 нче төркемдә 90% укучы үзләштергән булса, 2 нче төркемдә бары тик 50% кына. Тест буенча 1 нче төркемдә, 2нче, 4нче, 7нче сорауларда хата җибәргәннәр. 2 нче, 4 нче сорауларда хата, Г.Тукай турындагы мәгълүмәтне тиешле дәрәҗәдә игътибар белән тыңламаганлыктан җибәрелгән булса, 7 нче сорауда хата, татарча сүзләрне начар белгәнлектән, өйдә өйрәнеп килмәгәнлектән җибәрелгән. 8нче – 12 нче сорауларда хаталар юк диярлек. Чөнки теманы аңлатканда терәк схемалар кулланылды, укучылар кагыйдәне таблица һәм схема формасында яздылар.

2 нче төркемдә бер генә укучы барлык сорауларга дөрес җавап биргән. 1 нче сорауда 5 укучы хата җибәргән, чөнки Г.Тукайның портреты күрсәтелмәде. 2нче – 4 нче сорауларга хаталар игътибарсыз тыңлаганлыктан һәм Г.Тукай турында мәгълүмәт бирелгән вакытта, “Су анасы” әкиятен укыган вакытта рәсемнәр күрсәтелмәде. Теманы аңлаткан вакытта, кагыйдәне укучыларга әйтеп яздырган иде, таблица һәм терәк схемалар кулланылмаган иде, шунлыктан 8 нче – 12 сорауларга җавапларда күп хаталар җибәргәннәр. Күргәнебезчә, төркемнәрдә теманы үзләштерүдә аерма бар.

Димәк әлеге методиканы татар телен өйрәнгәндә куллану, һичшиксез, билгеле бер нәтиҗәләр бирә. Дәрестә балалар белән бергә терәк схемалар төзибез, дәреслектә бәян ителгән кагыйдәләрдән теоретик мәгълүматлар алып, аларны гомумиләштерүче символлар рәвешендә күз алдына китерәбез, бу мәгълүматлар арасында логик бәйләнешләрне урнаштырабыз һәм терәк схемада бу бәйләнешләрне сурәтлибез. Шулай итеп, терәк схемалар балаларга әзер килеш бирелми, ә тактада һәм дәфтәрдә укытучы җитәкчелегендә балаларны актив танып белү эшчәнлеге барышында "үсә". Терәк схеманы төзегәннән соң, балаларда тиз арада анда ориентлаша белү, шунда ук терәк схемасының аерым буыннарын табу һәм аңлау, бу буыннар арасындагы үзара бәйләнешне күрә белергә өйрәтү тора. Моның өчен укучылар сыйныф алдында парлап һәм индивидуаль җаваплар рәвешендә терәк схемасын «яңгырату» ысулы, “Кем тизрәк атар?” уены, лингвистик викторина кулланыла. Әлеге алымнарның һәркайсын сайлау терәк схемасында «шифрланган» теоретик материалның үзенчәлекләренә бәйле. Эксперемент нәтиҗәләре күрсәткәнчә, укытучыга һәр укучының белем формалашуы ничек баруын белү өчен, вакыт-вакыт диагностика үткәрергә кирәк дигән фикергә килдек. Шуңа күрә һәр дәрес ахырында мөстәкыйль эш тәкъдим ителә, аны укучылар тарафыннан үтәү өчен һәм аны тикшерү өчен укытучының сарыф ителгән вакыт күзлегеннән караганда, иң экономияле алымнар сайлап алына, мәсәлән: цифрлы, хәрефле,

график диктантлар, ачкычны кулланып үзара тикшерү, перфокарталар буенча эшләү, сигнал карточкалары һ.б. Мондый эш нәтиҗәләре укытучыга, күбрәк хаталар тудырган үрнәкләре нигезендә, киләсе дәрес өчен дидактик материалны сайлап алырга мөмкинлек бирә. Укучылар шулай ук үзләренең уку эшчәнлеген контрольдә тота алалар, бу исә белем алуда уңыш шартларының берсе булып тора.

Гомумиләштереп әйткәндә, татар теле дәресләрендә терәк схемаларны кулланып эшләү, тикшерү һәм контроль эшләр нәтиҗәләрен яхшыртуга, өлгерешне арттыруга китерә дигән нәтиҗәгә киләбез. Схемалар теоретик материалны яхшырак аңларга, аны практикада кулланырга мөмкинлек бирә. Шул ук вакытта эксперимент барышында без башка фикергә дә килдек: терәк схемаларының ролен арттырырга һәм аларны белем бирүнең бердәнбер мөмкин булган ысулы дип санарга кирәкми. Мәгълүм булганча, укыту ысулын сайлау күп факторларга бәйле: уку материалының төренә, сыйныфта балаларның интеллектуаль үсеш үзенчәлекләренә, укытучының үзенең индивидуальлегенә. Терәк схемалар укытучыга татар телен уңышлы укыту проблемасын хәл итәргә ярдәм итәчәк, әгәр алар янына, укытуның башка ысулларына да якын килеп, уку материалы тибы һәм конкрет шартлар нигезендә укытуның һәр ысулы мөмкинлекләрен исәпкә алып, дәрескә иҗади якын килеп әзерләнсәң.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: укучыларга телне схемалылык технологиясенә нигезләнеп өйрәтү, чит телне тизрәк, материалны тирәнтен һәм эзлекле үзләштерүгә ярдәм итә. Аларның сүз байлыгын, логик фикер йөртү мөмкинлеген арттыра, тупланган сүз һәм җөмлә байлыгын гамәлдә куллану, әңгәмәдәшенең сөйләмен аңлап, үз фикерен әйтеп бирергә мөмкинлекләр ача. Терәк схемалары, дәрес үткәрү формаларын төрләндереп кенә калмый, аларны истә калдыручы, эмоциональ итә, шулай ук укучыларның логик фикерләвен үстерә, укучыларның белем һәм күнекмәләрен ныгыту, сөйләмне үстерү өчен практик эшчәнлегендә ярдәм итә.

**Әдәбият**


1. Максимов Н. В. Татар теленнән таблицалар һәм схемалар. - Казан, Мәгариф, 2005.- 187 б.
2. Максимов Н. В., Шәйхразиева З. В. Сүз төзелеше: таблицалар һәм схемалар. – Казан: Мәгариф, 2008. – 64 б.
3. Хайдарова Р.З., Галиева Н.Г., Ахметзянова Г.М. Татарский язык: учебник для образовательных организаций начального общего образования (на русском и татарском языках). 1 класс – Казань: Татармультфильм, 2013. – 144 с.
4. Хайдарова Р.З., Галиева Н.Г., Ахметзянова Г.М. Татарский язык: учебник для образовательных организаций начального общего образования (на русском и татарском языках). 2 класс – Казань: Татармультфильм, 2013. – 144 с.
5. Хайдарова Р.З., Ахметзянова Г.М., Гиниятуллина Л.А. Татарский язык. 4 класс: учебник для образовательных организаций нач. общ. образования. В 2-х частях. Часть 2. – Казань: Татармультфильм, 2014. – 128 с.

# ТАТАР СӨЙЛӘМ ЭТИКЕТЫНА ӨЙРӘТҮ АЛЫМНАРЫ

Нәбиуллина Г.Ә.
Казан федераль университеты
guzelNab2@yandex.ru

**Аннотация.** Статья посвящена средствам, методам и приемам обучения речевому этикету на татарском языке. Рассмотрены основные методические принципы и приемы обучения татарскому речевому этикету.
**Ключевые слова:** речевой этикет, речевая культура, обучение татарскому языку, родной язык.

Туган телнең сөйләм культурасы – гомумкультураның аерылгысыз мөһим бер өлеше ул. Сөйләм культурасы фәне гомумтел белеменең бер тармагын тәшкил итә һәм үз фикерләреңне дөрес, тегәл, логик эзлеклелектә сөйли-яза белү, уй-тойгыларыңны күңелгә үтеп керерлек итеп әйтүне аңлата. Туган телнең байлыгыннан иркен файдалана белү күнекмәләре булдыруны максат итеп куя.

Сөйләм культурасы — иң беренче чиратта, сөйләм нормаларын үзләштерү: авазларны дөрес итеп әйтеп, лексик һәм грамматик чаралардан дөрес файдалану. Сүз, сөйләм осталыгына ия булу кешегә җәмгыятьтә үз урынын таба алырга мөмкинлек бирә. Шуңа күрә яшь буынга тел гыйлеме мәсьәләләрен теоретик өйрәтү белән беррәттән, сөйләм культурасы күнекмәләрен бирү — заман таләбе [1-4].

Сөйләм этикеты – билгеле бер социумда кабул ителгән һәм мәдәни җайга салуның нәтиҗәсе булган тотрыклы формулалар һәм гыйбарәләрне гамәлгә ашыручы индивидның үз-үзен тотыш кагыйдәләренең, нормаларының, таләпләренең комплекслы системасы. Кеше җәмгыятенең барлык вәкилләренә дә яраклы универсаль этикет нормалары да, бер халыкка гына карый торган милли нормалар да бар. Бу төрле халыкларның телләрендә билгеле бер тел йөртүчеләргә генә аңлаешлы булырга мөмкин булган үзенчәлекләр булу белән аңлатыла.

Сөйләм этикетына өйрәтүнең максаты – укучыларында аралашу максатларына эффектив ирешү өчен, төрле аралашу ситуацияләрендә сөйләм этикеты берәмлекләрен адекват куллану күнекмәләрен формалаштыру.

Сөйләм этикетын укучыларга өйрәтүнең төп бурычлары:

1) сөйләм этикеты өлкәсендә укучыларның коммуникатив грамоталылыгын формалаштыру, бу сөйләм этикетының максаты, нормалары һәм функцияләрен белүне таләп итә; шулай ук мәгариф һәм көндәлек аралашу ситуацияләрендә килеп чыккан конфликтларның сәбәпләрен аңлау;

2) үзеңнең коммуникатив практикаңны аңлау сәләтен формалаштыру (берсенең үз-үзен тотышын, әңгәмәдәшенең тәртибен анализлау, берсенең һәм икенчесенең сөйләмендәге хаталарны күрү);

3) җаваплы сөйләм тәртибе осталыгын формалаштыру, аны көйләү;

4) төрле аралашу ситуацияләрендә сөйләм этикетын эффектив куллануга өйрәтү [2: 13].

Галимнәр фикеренчә, сөйләм этикетын укытуның эффектив ысулы - сөйләм этикетына тарихи сылтамалар куллану (Россия һәм башка илләр тарихында әдәплелекне белдерү юллары турындагы хикәяләр), бу сөйләм этикеты кагыйдәләрен үзләштерү мотивациясен арттыра. Тел галиме Ф.С. Сафиуллина фикеренә караганда, «Укытучы сөйләм этикетына караган хаталарны алдан кисәтеп, булдырмау чаралары күрергә тиеш. Авыр очракларны алдан күреп, алар белән эшләүгә игътибар итәргә кирәк. Этикетка караган иң мөһим һәм еш кулланыла торган формаларны сайлап алырга һәм сөйләмгә кертергә кирәк. Башта стилистик нейтраль тәгъбирләр кертелергә тиеш. Телне күбрәк өйрәнгән саен, синонимик формулаларны да әйтергә, өйрәтергә кирәк һәм алар диалогларга кертелә барырга тиеш. Бу юнәлештә эшләү әзерлек күнегүләрендә дә, иҗади күнегүләрдә дә дәвам итә» [3: 113].

Методика фәнендә сөйләм этикетына өйрәтүнең киң таралган түбәндәге ысуллары билгеле:

1) әдәби әсәрләр кулланып, сөйләм тәртибе культурасы үрнәкләренә анализ
2) әхлакый характердагы сөйләшүләр («Симпатияне ничек белдерергә»);
3) бәйсез конкурслар («Туган көн белән ничек котларга»);
4) проблемалы характердагы сөйләм проблемаларын чишү;
5) тәкъдим ителгән сөйләм ситуацияләренә нигезләнеп уйнау;
6) коммуникатив роль уйнаучы уеннар («Китапханәдә»);
7) тематик принципка нигезләнгән «әдәпле сүзләр сүзлеген» саклау;
8) сөйләм этикетын бозуны ачыклау һәм төзәтү буенча күнегүләр;
9) телефон аша сөйләшү этикетын, Интернеттагы корреспонденцияне, SMS хәбәрләрен өйрәнү;
10) гомумиләштерү, өйрәнелгәннәрне системалаштыру формасы буларак әдәплелек турнирлары.

Максатлы һәм системалы итеп сөйләм этикетын өйрәнү балалар мәктәпкә килгән көннән үк башланырга тиеш. Башлангыч сыйныфларда сөйләм этикетының нигезе (әдәплелек, мәктәптә, өйдә, урамда, кешеләр арасында үз-үзеңне тоту) салынса, урта сыйныфларда инде бу нормалар үстерелергә тиеш.

Укытучының төп бурычы – укучыларның этикет таләпләренә туры килә торган, җәмгыять үсеш процессында туплаган культураны чагылдырган осталыгын үстерү. Ләкин укучыларда мондый сәләтләрне һәм күнекмәләрне үстерүнең эффективлыгына, сөйләм белдерү чаралары белән бердәмлектә сөйләм тәртибе нормаларын системалы аңлату һәм практик осталыкка ирешкән очракта гына ирешеп була. Димәк, укучылар үз-үзләрен тотыш кагыйдәләренең билгеле бер исемлеген генә түгел, ә аларны тормышка ашыру формаларын да өйрәнергә тиешләр.

Сөйләм этикетын өйрәтү белән шөгыльләнгәндә, укытучылар еш кына телдән тәэсир итү формаларына зур әһәмият бирәләр, эшне аларның эчтәлеге һәм тормышка ашыру формаларын аңлатуга караганд,а тел тәртибе кагыйдәләре хисабына киметәләр.

Этикетик ситуациядә сораулар, диалог, сөйләм формулалары ярдәмендә үз-үзеңне тотуны камилләштерүнең нәтиҗәле ысулларының берсе – сөйләм ситуациясе. Укытучы төрле яктан укучылар белән бергә этикетик ситуацияләрне модельләштерүгә якын килергә яки әзер килеш бирергә, ситуацияләрне уйнарга һәм аларны тикшерергә, анализларга кирәк. Укучылар моны ни өчен эшләүләрен, кайда һәм кайчан тормышта кирәк булачагын аңларга тиеш.

Уен күнегүләре – укыту процессының тагын бер формасы (белем, осталык, сәләт, эмоциональ һәм бәяләү эшчәнлеге) булып тора. Шулай итеп рольле уеннар үз-үзеңне тоту тактикасын, синең нинди дә булса ситуациядә гамәлләреңне эшләргә мөмкинлек бирә. Әлеге уеннарны үткәрү өчен, ситуациянең моделе эшләнә, рольләр бүленә. Мәсәлән, укучыларга "чакыру ситуациясендә" үз-үзеңне тотуның төрле вариантлары булган карточкалар таратыла. Соңрак хәлләр берничә тапкыр уйнала һәм укучылар, сайлап алынган вариантны нигезләп, тиешле тәртипне һәм уеннарда катнашучыларның сүзен сайлый.

Уен күнегүләренә түбәндәгеләр керә: ситуатив күнегүләр, рольле уеннар, әдәпле уеннар. Яшерен ярдәм, матур тәртип үрнәкләренә басым ясау, чагыштырулар куллану, уңай гамәлләргә таяну кебек ысуллар бик эффектив. Әйтергә кирәк, сөйләм теле культурасын формалаштыру, сөйләм этикетына өйрәтү эше системалы рәвештә төзелергә һәм төрле алымнар кулланып, шул исәптән рольле уеннар, рус теле дәресенең төрле этапларында булырга тиеш. Һичшиксез, алдан эшне оештырырга кирәк (бу кагыйдә буенча әңгәмә, төрле хәлләрдә үз-үзеңне тотуны анализлау).

Шулай итеп, укытучы актив формалар һәм методлар, шулай ук уен технологияләре кулланып, укучылар белән эш алып барса, бу укучыларның сөйләм культурасын формалаштыруда уңай нәтиҗәләргә китерә. Телнең этикеты, аны дөрес куллану, этикетның "язылмаган кагыйдәләрен" куллана белү – телне укытканда аеруча бер мөһим мәсьәлә булып тора.

**Әдәбият**

1. Абдуллина Р.С. Стилистика һәм сөйләм культурасы мәсьәләләре. – Яр Чаллы: «КАМАЗ» нәшрияты, 1997. – 128 б.

2. Бим И.Л. Методика обучения иностранным языкам как наука и проблемы школьного учебника. – Москва: Просвещение, 2002. – 278 с.

3. Сафиуллина Ф.С. Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан: «Хәтер» нәшрияты, 2001. – 432 б.

4. Харисов Ф.Ф. Основы методики обучения татарскому языку как неродному. – Санкт-Петербург, «Просвещение» 2001.– 430 б.

# ТАТАР ТЕЛЕНӘ ӨЙРӘТҮДӘ ӘХЛАКЫЙ КЫЙММӘТЛӘРНЕ ФОРМАЛАШТЫРУ ЧАРАСЫ БУЛАРАК МУЛЬТИПЛИКАЦИОН ФИЛЬМНАР

Нәүмәтова Р.Р.
Казан федераль университеты
rnaumetova16@mail.ru

**Аннотация.** Показаны возможности использования мультипликационных фильмов в целях формирования нравственного опыта детей при изучении татарского языка, описана методика включения учителя в ситуации восприятия детьми кинопродукции.
**Ключевые слова:** татарский язык, мультфильм, анимация, нравственные ценности, нравственно-развивающий потенциал мультфильма.

Мультипликацион фильм, сәнгать төре буларак, зур тәрбияви потенциалга ия. Мультфильм сюжетлары һәм персонаж образлары әхлакый нормалар һәм кыйммәтләрне тапшыру функциясен үтиләр, балаларның игътибарын җитди проблемаларга юнәлтәләр.

Мультипликацион фильмнар балалар әдәбияты белән уртак үзенчәлекләргә ия. Алар яшь буынны тәрбияләүдә, аны рухи яктан үстерүдә мөһим чара булып тора: баланың сөйләмен формалаштыруда ярдәм итә, тирә-юньдәге күренешләр белән таныштыра һәм уй-фикерләрне дөрес белдерергә өйрәтә.

Заманча мультипликацион фильмнар – мәгънәсез сюжетка корылган, балаларның игътибарын җәлеп итәр өчен кулланылган төсле рәсемнәр генә түгел, аларның күбесенең үзәгендә тирән фәлсәфи уйлар, кискен иҗтимагый мәсьәләләр белән беррәттән, теге яки бу халыкның милли үзенчәлекләре дә урын ала. Кинематографиянең башка жанрларындагы кебек үк, теләсә кайсы мультипликацион фильм тамашачыга җиткерелергә тиешле билгеле бер идеягә корылган була. Шуңа күрә телгә өйрәтү процессында мультфильм күрсәтү алымын кулланганда, мультипликацион фильмны җитештергән илнең милли спецификасын, анда өстенлек иткән кыйммәтләрне исәпкә алып, оригинал текст авторлары әйтергә теләгән идея, сюжетны кирәкле дәрәҗәдә тапшыру таләп ителә. Шул исәптән мультфильм тәрҗемә ителгән тел, шул телдә сөйләшә торган халыкның үзенчәлекләре турында да истә тоту мөһим.

Һәр милләтнең тарихи үсеше процессында табигатькә, үзенең һәм чит җәмгыять кешеләренә, әйләнә-тирә мохиткә карата үз мөнәсәбәтләр системасы барлыкка килә. Нәкъ менә шундый мөнәсәбәтләр халык һәм аның мәдәнияте кыйммәтләре системасын формалаштыру өчен нигез булып тора.

Шуңа да карамастан, кыйммәтләр төшенчәсенең хәзерге фәнни хезмәтләрдә гомуми кабул ителгән билгеләмәсе юк. Беренче чиратта, бу төрле мәдәниятләрдә кыйммәтләрнең аерылуы белән аңлатыла. Кыйммәтләр төшенчәсе, гадәттә, әхлак, этика, иҗтимагый тәртип нормаларына, ә еш кына дин төшенчәсенә дә туры килә [3,19].

С.Г. Тер-Минасова билгеләп үткәнчә, «теге яки бу мәдәниятнең кыйммәтләре системасы бик тотрыклы һәм, гадәттә, тышкы факторлар йогынтысында үзгәрә». Моннан тыш, кыйммәтләр үзләре түгел, ә аларның иерархиясе генә үзгәреш кичерә. Кыйммәтләрнең иерархиясе бер мәдәниятне икенчесеннән аерырга һәм теге яки бу кыйммәтнең билгеле бер җәмгыять вәкилләренең тормышына ни дәрәҗәдә йогынты ясавын аңларга мөмкинлек бирүче төп фактор ролен үти [3, 20].

Милли кыйммәтләр – кеше эшчәнлеген җайга сала торган корал, чөнки нәкъ менә алар нигезендә әйләнә-тирә мохит белән хезмәттәшлек итү процессында кирәкле мәгълүмат сайлап алына иҗтимагый элементләр урнаштырыла, хис-тойгылар, аралашу күнекмәләре формалаша.

Анимацион фильмнарны ясаучылар, булачак мультипликацион фильмның үзәгендә торган идея турында фикер йөрткәндә, беренче чиратта игътибарны балаларга яңа, таныш булмаган мәгълүмат бирә алу потенциалына юнәлтә. Мультипликацион фильмның милли кыйммәтләр структурасын төзү нәкъ менә булачак фильмның идеясе хакында уйлаганда булдырыла. Мондый фильмнарның балалар психикасына йогынтысын өйрәнүче экспертлар фикеренчә, анимацион картина тәрбияви функция үтәргә, бары тик уңай кичерешләр генә тудырырга тиеш. «Зыян салма», «Куркытма» принциплары кечкенә тамашачылар өчен иң әһәмиятлеләрдән санала. Визуаль һәм эстетик яктан матурлык, тәрбияви максат мультфильмнарны ясаганда мөһим роль уйный. Анимация булдыруга мондый караш балаларда дөрес сәнгат зәвык һәм гүзәллекне күрә белү хисе тәрбияләү күзлегеннән мөһим, шуннан башка үз-үзе, тирә-юньдәгеләр белән гармониядә булган шәхес тәрбияләү мөмкин түгел.

Анимацион фильмнарны эшләгәндә җитештерүчеләр аларның структурасына гомумкешелек кыйммәтләрен дә кертү яклы. Иң мөһим гомумкешелек кыйммәтләре дип экспертлар *Дуслык, Үзара ярдәмләшү, Намуслылык, Яхшылыкның явызлыкны җиңүе, Гаделлек, Үзара аңлашу, Экология,Сабырлык һәм Уртак тел таба белү*не билгели. Димәк, әлеге үзенчәлекләр барлык илләрнең мультипликацион культурасында да очрый.

Һәр халык милли үзенчәлекле мультфильмнарга бай. Өстәвенә, аудио-визуаль сәнгать төре һәм балаларга йогынты ясауның популяр формасы буларак мультипликация, милли телләр арасындагы чикне үтеп, милләтләр арасындагы бәйләнеш күрсәткеченә әверелә.

Илләр арасындагы тыгыз мөнәсәбәтләр нәтиҗәсендә җәмгыятьнең барлык өлкәләре дә үсеш кичерә. Хәзерге заманда мультипликацион фильмнарның һәрберсе компьютер технологияләр ярдәмендә ясала. Бик сирәк персонажларны хәзер пластилиннан әвәлиләр яки үтә күренмәле элпәдән ясыйлар. Компьютер анимациясенең төрле чараларын куллану персонажларны реаль итеп тасвирларга мөмкинлек бирә. Мондый геройлар кеше кебек хәрәкәт итәргә, кеше башкарган барлык гамәлләрне башкарырга сәләтле. Хәрәкәтләрнең сыгылмалыгы һәм махсус эффектлар анимацион картиналарны чынбарлыкта кебек сурәтли.

Хәзерге заман балаларында әхлакый кыйммәтләргә бай совет мультфильмнары кызыксыну уятмый, алар арасында динамик вакыйгалар, заманча гыйбарәләр, гади булмаган геройларның яшәү рәвешен чагылдырган мультипликацион фильмнар актуаль. Күп очракта заманча мультфильмнар совет заманындагылар белән охшаш, күбесендә шулай ук яхшылык һәм явызлык көчләренә каршы көрәш темасы күтәрелә. Әмма хәзергеләре реаль тормышка күбрәк бәйле, алар балаларны социумга җайлашырга өйрәтәләр.

Шул ук вакытта, экспертлар билгеләп үткәнчә, хәзерге вакытта эстетик һәм әхлакый эталоннарга туры килми торган, балаларда агрессия, курку хисе уята, ялган идеалларны пропагандалый торган мультфильмнар да җитәрлек.

Билгеләнгән проблемага нигезләнеп, без бу мәкаләдә түбәндәге бурычларны хәл итүне максат итеп куйдык:

1) балаларга әхлакый тәрбия бирү мәсьәләсен хәл итү өчен мультипликацион фильмнарны сайлап алу критерийларын билгеләү;

2) татар телен мультфильмнар аша өйрәнгәндә кулланырга мөмкин күнегүләр белән танышу.

Чит телләрне укытуның заманча методикасы мультипликацион фильмны үзенчәлекле аудиовизуаль белем бирү чараларының берсе буларак карый. Әлеге укыту чарасының төп үзенчәлеге – аны ишетү һәм күрү аспектларыннан чыгып куллану.

Немец теле укытучысы Е.В. Заводова үз хезмәтендә: «Чит телләрне укытуның үзенчәлеге – өйрәтелгән телнең халкы, мәдәнияте турында киң мәгълүмат бирү ярдәмендә әлеге телгә игътибарны җәлеп итү зарурилыгы. Мондый төр мәгълүматка милли элементлар – реалийлар күп булу хас, алар, үз чиратында, телне өйрәнүчеләр аңында бик күп проблемалар тудыра. Бу проблеманы хәл иткәндә видеоматериаллар, мультипликацион, сәнгать фильмнары, экранлаштырылган драма әсәрләреннән өзекләр куллану зур өлеш кертә», – дип яза [1].

Мультипликацион фильмнар ярдәмендә укытучы укучыларда коммуникатив компетенция формалаштыра. Бу компетенцияне чит телне үзләштерү процессында сыйныфта булдыру бик авыр, шуңа күрә укытучыга, төрле ысуллар һәм эш алымнары кулланып, чит телне өйрәтү дәресләрендә ясалма аралашу ситуацияләре тудырырга кирәк.

Телне өйрәнгәндә укучыларны бу тел вәкилләренең мәдәни кыйммәтләренә җәлеп итү – мөһим бурыч. Инглиз теле укытучысы Л.М. Мезенина фикеренчә, «чит илләрнең тормышы белән танышу, нигездә, текст һәм иллюстрацияләр аша башкарыла. Хатлар, реклама, белдерүләр, элмә такталар, анкеталар укучыларга, чит илгә барган очракта, яхшырак ориентлашырга мөмкинлек бирә. Моның белән беррәттән, укучыларда чит ил тормышы, гореф-гадәтләре хакында күзаллау булу мөһим. Бу максатларга коммуникатив методиканың мөһим таләпләрен тормышка ашырырга булыша торган мультипликацион фильмнар хезмәт итә ала» [2]. Чит телне өйрәнү процессында ил турында мәгълүматны үзләштерү, тел вәкилләренең тормышы белән танышу, көнкүрештәге ситуацияләрне бу тел вәкиле кебек үк кабул итү мөһим.

Телне мультипликацион фильмнар аша өйрәткәндә түбәндәге күнегүләрне кулланырга мөмкин:

1) фаразлау;

2) эчке монолог;

3) туры китерү;

4) биография;

5) дебатлар.

1. «Фаразлау». Укытучы мультфильмда барган ситуацияләргә яки персонажларның үз-үзләрен тотышын тасвирларга ярдәм итә торган берничә сүз яки фразаны мультфильмда очрау тәртибендә тактага яза. Укучылар белән бу сүзләрнең нинди хәлдә очрарга мөмкинлеге турында фикер алыша.

Укучылар бу сүзләр һәм фразалар кулланылачак сценарий язалар. Укытучы берничә вакыйганы сайлап ала һәм укый. Соңрак укучыларның игътибары мультфильм фрагментын карауга юнәлтелә.

2. «Эчке монолог». Укытучы персонажның хисләре яки мөнәсәбәтләре ачык чагылган өзекне сайлый, ләкин бу өзектә диалог бөтенләй булмый яисә бик аз күләмдә була. Укучыларның бурычы – хисләрне сүзләр ярдәмендә тапшыру өчен эчке монолог төзү.

3. «Биография» кебек күнегү төре еш кына аудиториядән тыш дәресләрдә кулланыла. Укытучы мультфильмнан персонажлар үзара аралашкан биш-ун минутлык өзек сайлый. Өзек үз эченә персонажларның кем булулары хакында мәгълүматны алырга тиеш. Укытучы гактага сораулар яза:

- Персонажның тулы исеме ничек?
- Ул кайда туган?
– Ул кайчан туган?

Күрсәтелгән өзеккә нигезләнеп, укучылар бу сорауга тулы җавап бирергә тиеш була.

4. Соңгы күнегү төре – «дебатлар». Бу бирем телне яхшы белүчеләр өчен уңышлы. Укытучы үз эченә нинди дә булса идея алган өзек сайлый, мәсәлән, ул «Йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсын» мәкаленә багышланган булырга мөмкин. Мультфильмнан бу мәкальгә туры килгән өзек күрсәтелә. Укучылар аңа карата үз фикерләрен белдерәләр, бер-берсенә сораулар бирәләр.

Шулай итеп, мультипликацион фильмнар чит телләрне өйрәтүдә төп аутентик чараларыннан берсе булып тора дигән нәтиҗә ясый алабыз. Мультипликацион фильмнар аудиториянең игътибарын контрольдә тотарга ярдәм итә, укучыларга эмоциональ йогынты ясый һәм тел өйрәнү теләген арттыра. Мультфильмнарның психологик яктан йогынты ясау үзенчәлекләре укучыларның тел, коммуникатив һәм социомәдәни компетенцияләрен формалаштыру өчен уңайлы шартлар тудыра, шулай ук уку процессын интенсификацияләүгә ярдәм итә. Югарыда күрсәтелгән күнегү төрләре укучыларның чит телне өйрәнү белән кызыксынуларын арттырырга мөмкинлек бирә, укучыларның сүзлек запасын шактый тулыландыра һәм дәресне төрлеләндерергә мөмкинлек бирә.

**Әдәбият**

1. Заводова, Е. В. Методика использования аутентичных видеоматериалов на уроках иностранного языка [Электронный ресурс] // URL: http://festival.1september.ru/articles/104294 (дата обращения: 11.02.2021).

2. Мезенина, Л. М. Использование видеокурсов при обучении иностранной речи [Электронный ресурс] // Образовательный портал Фестиваль педагогических идей «Открытый урок» // URL: http://festival.1september.ru/articles/312881 (дата обращения: 12.02.2021).

Тер-Минасова С.Г. Язык и межкультурная коммуникация: Учеб. пособие. – М.: Слово, 2000. – 624 с.

# НАРРАТИВНЫЙ ПОДХОД В МЕТОДИКЕ ПРЕПОДАВАНИЯ ИНОСТРАННОГО ЯЗЫКА В УСЛОВИЯХ ГЛОБАЛИЗАЦИИ ПРОФЕССИОНАЛЬНО - ОРИЕНТИРОВАННОГО ОБРАЗОВАТЕЛЬНОГО ПРОЦЕССА

Некрасова Т.В., Моисеенко Л.Н.
Омский автобронетанковый инженерный институт, г. Омск
tatyana.vladimir@mail.ru , moiseenkolarisa@inbox.ru

**Аннотация.** В статье обоснованы особенности использования нарративного подхода при обучении иностранному языку с учетом специфики профессионально-ориентированного образования, а именно, решение ситуационных задач посредством их описания и представления, используя языковые и речевые навыки и умения.
**Ключевые слова:** глобализация образовательного процесса, нарративный подход, языковые и речевые навыки, профессиональные ситуации и задачи

Современная образовательная ситуация характеризуется обязательным требованием - знание иностранного языка как средства самовыражения и роста профессиональной карьеры. Главным аспектом программ обучения иностранным языкам в мировом сообществе является формирование языковых и речевых навыков для коммуникации по содержанию будущей профессиональной деятельности обучаемых, при этом, усвоение определенной суммы знаний является средством, обеспечивающим эффективность будущей профессиональной коммуникации. Лексические и терминологические единицы, грамматические явления и т.д. являются также средством, а не целью.

Таким образом, в условиях глобализация образовательного процесса преподаватель военного вуза должен использовать эффективные методические подходы к преподаванию иностранного языка для специалистов нефилологического профиля, а именно, соответствие квалификационным требованиям с описанием типовых сфер и ситуаций общения будущих выпускников вузов, с уточнением целей и задач коммуникации будущих офицеров в рамках их военно-профессиональной деятельности. Значимость данных характеристик актуализируется с позиции личностной ответственности будущего специалиста за процесс его подготовки и практической реализации в профессиональной деятельности [7, с. 7].

Такой подход к образовательному процессу по дисциплине «Иностранный язык» требует развития как устных, так и письменных нарративных навыков. Нарратив (англ. и фр. *narrative*, от лат. *narrare* – рассказывать, повествовать) - изложение взаимосвязанных событий, представленных читателю или слушателю в виде последовательности слов или образов [6]. Часть значений термина «нарратив» совпадает с общеупотребительными словами «повествование», «рассказ» [5]. В основе нарративного подхода лежат идеи, разработанные в рамках разных дисциплин: этнографии (К. Гирц, Э. Брунер, А. ван Геннеп, В. Тернер), психологии (Дж. Брунер, Т. Сарбин, Л.С. Выготский и

др.), теории литературы (В. Пропп, М.М. Бахтин, Н. Фрай), истории систем познания (М. Фуко, К. Герген) и др..

Потенциал нарратива, т.е. представления о том, что профессиональная деятельность развивается в виде ситуаций, которые необходимо описывать и представлять, огромен. Этот потенциал дает возможность всем участникам образовательного процесса сотрудничать, создавая осмысленные, выразительные обоснованные акты коммуникации по содержанию профессиональной деятельности, воплощать их в реальность. Нарративный подход принимает во внимание более широкие контексты, нежели непосредственное окружение обучающегося - образовательное учреждение, систему образования: ее тенденции развития, культуру, квалификационные требования и т.д. Специалисты, применяющие в работе нарративный подход, обретают средство вариативности описания ситуации при формировании и развитии языковых и речевых навыков. Нарративный подход в работе с людьми основывается на том, что мы строим свою жизнь в соответствии с историями, которые мы рассказываем о себе самим себе и другим, и в соответствии с историями, которые рассказывают о нас другие люди. Важно отметить, что сам человек - не единственный автор историй своей жизни. Многие из доминирующих историй, довлеющих над нашими жизнями, берут начало из опыта взаимодействия в образовательном профессиональном процессе. Этим взаимодействиям характеризуются «масштабами» – дискурсами, характеризующимися более широкими контекстами [3].

Нарративный подход, в нашей концепции, ориентирован на развитие субъективной активности личности курсанта, а именно, в описании конкретных профессиональных ситуаций. Одной из ключевых проблем современного образования является проблема личности и её развития в специально организованных условиях, так как личность законодательно определена главной ценностью современного образования. Курсант признается субъектом своей образовательной деятельности, а вся система обучения иностранным языкам ориентирована на содействие личностному самоопределению, на развитие способностей и склонностей личности курсанта, создание условий для ее реализации, удовлетворение образовательных потребностей. Процесс субъективной активности личности направлен на формирование у курсантов военной картины мира, адекватной современному уровню знаний, формирование человека активного и самостоятельного, интегрированного в современное ему общество, направлен на полную реализацию индивидуальных особенностей, мотивов, интересов, социальных установок, ту или иную направленность личности [2].

Изучив и проанализировав различные особенности проблемы личности и её субъективной активности в рамках нарративного подхода, в качестве основополагающего мы берём определение, данное С.Л. Рубинштейном: «Личностью является человек, у которого есть своя позиция в жизни, к которой он пришел в итоге большой сознательной работы; такой человек сознательно выделяет себя из окружающего… Глубина и богатство личности предполагают

глубину и богатство её связей с другими людьми» [9]. На наш взгляд, данное определение не только отражает субъективность активности личности курсанта, её самоценность, развитие в процессе профессиональной деятельности, но и проектирует возможности самореализации в процессе совместной деятельности и общения с коллегами по поводу достижения профессионально-значимых и личных целей. Системообразующим признаком личности является её целостность, так как она скрепляет все элементы личностной структуры, служит показателем и внутренним критерием уровня развития личности, является чертой, совершенствование которой может определять выработку определенной линии поведения в сфере профессиональной коммуникации[8,10]. Мы полагаем, что целостность личности как социального субъекта не только отражает единство общего, особенного, единичного, составляющего структуру личностного проявления с позиции нарратива, но и выражает её интегративность, которая выражает себя в профессиональных ситуативных намерениях.

Очевидно, что обучающийся в образовательном учреждении выступает субъектом нарративной деятельности, ориентированной на его профессиональное становление, что определяет результаты учебной деятельности. Использование нарративных стратегий активизирует мотивационный компонент личности, отношение к себе как к субъекту нарративной деятельности. В результате развивается процесс, в котором собственные черты и качества оцениваются курсантом по отношению к мотивам, выражающим потребность в самореализации в профессиональных ситуациях.

Структура субъектной активности, построенной по правилам нарратива, как единицы коммуникации, определяет сущность субъектной самореализации и самоорганизации, определяет мотивы и цели деятельности, характеризует способы их достижения и свидетельствует о достигнутых результатах. При использовании нарративного подхода в обучении иностранным языкам основной акцент делается на повествование и наррацию. Курсанту, прежде всего, нужно мысленно составить ситуацию (профессиональную задачу), а затем ее продекларировать. Наррацию, таким образом, можно представить как результат процесса повествования. Составление рассказа и его проговаривание способствует запоминанию новых терминов и более глубокому проникновению в их содержание.

Нарративный подход очень ценен в методическом плане. Во-первых, он дает возможность обучающимся сконцентрировать работу на повествовании как элементе процесса коммуникации в целях презентации определенного лексического (терминологического) и грамматического материала. Во-вторых, это означает практически бесконечную комбинацию ограниченного количества профессиональных сюжетов, что позволит курсанту при небольшом запасе лексики и грамматики создавать свои собственные уникальные ситуации (истории) и тексты на базовом и специальном этапах обучения иностранному языку. Большое значение имеет адаптация гносеологического аспекта

антиномии нарратива, где в центре соотношения находится именно познавательное тождество события и текста [1].

Гносеологический аспект коммуникации состоит в том, что в принципе событие или ситуация описывается в тексте, что предполагает новое знание этого текста как сообщения для коммуникации. При рассмотрении этого аспекта, нарратив выступает с точки зрения того, искажается ли представление об особенностях коммуникации, насколько, как и почему. В этом смысле исследование нарратива должно заключаться в том, чтобы понять, как минимизировать искажения информации, как по сообщению восстанавливать события, как довести до получателя образ неискаженного события. Цель нарративного подхода в гносеологическом аспекте – научить курсантов создавать и представлять себя решение профессиональных задач и ситуаций в контексте реального современного мира: личностного и профессионального, что служит дополнительным стимулом для реализации их творческого потенциала и достижения максимально – продуктивного усвоения специального иностранного языка.

Чтобы точнее охарактеризовать нарративный подход в обучении иностранному языку, следует рассмотреть его с позиции теории речевых актов **[4].** Как правило, устное и письменное речевое поведение определяются рядом факторов, которые должны учитываться при обучении как родному, так и иностранному языку. Как минимальная единица коммуникации любой речевой акт включает в себя следующие составные части:

Уйгурский народ уделяют большое внимание образованию подрастающего поколения. На сегодняшний день особенно важно, чтобы дети учились в университетах и получили высшее образование. Поэтому, кто бы ни поступил в университет, люди будут говорить о нем только хорошее и эта новость будет неслуху. Соответствующие поздравления:

Поздравляю с успешным поступлением ئالىي مەكتەپكە قوبۇل قىلىنغانلىقىڭىزنى قۇتلۇقلايمەن،

Желаю хорошо учиться ئالىي مەكتەپنى ئۇتۇقلۇق تاماملىشىڭىزنى تىلەيمەن

Желаю стать хорошим специалистом يارامليق ئادەم بول

2.2.2 Пожелания гостям за столом

С давних времён, уйгуры устраивали посиделки дома, приглашая большое количество гостей, но по мере повышения уровня жизни людей, большинство уйгуров отдают предпочтение посещению кафе и ресторанов вместе с гостями. Во время таких встреч, самый уважаемый и высокопоставленный человек, удостаивается чести произнести слова пожеланий. Например,

Пусть ваш стол будет полным, как сегодня داستىخېنىڭىز بۈگۈنكىدەك مول بولسۇن

Приятного аппетита ئاشلىرىڭىز تەملىك بولسۇن

Пусть за вашим столом будет в достатке داستىخېنىڭىزدىن ھەر ۋاقىت ئېشىپ تېشىپ تۇرسۇن

2.3 Поздравления на праздники بايراملىق قۇتلۇق ئىبارىلەر

2.3.1 Поздравление в честь Навруз Байрам نورۇز بايراملىق قۇتلۇق ئىبارىلەر

Этот праздник является началом нового года по старому календарю (солнечному календарю), означающего «уход старого года». Во время празднования уйгуры собираются семьями, готовят праздничные блюда, на улицах толпы людей, все ходят друг к другу в гости, желают друг другу счастливого нового года, здоровья, чтобы год был плодотворным. Соответствующие тосты, такие как:

Счастливого Навруза نورۇز مۇبارەك

Пусть светлый праздник Навруз принесет добрые перемен نورۇزدا مول هوسۇلچىلىق چۈمكەنسۇن

Пусть будет хорошим урожай **هوسۇل ياخشى بولسۇن**

Пусть год будет плодотворным مول هوسۇللۇق يىللاردىن بولسۇن

2.3.2 Поздравления в честь праздника Курбан байрам قۇربان ھېيتلىق قۇتلۇق ئىبارىلەر

Курбан Байрам является важным мусульманским праздником, также известным как «жертвенный праздник». Он отмечается мусульманами всего мира через 70 дней после завершения священного месяца Рамадан. Члены семьи и близкие соседи должны воздать друг другу почести и произнести слова поздравления:

С праздником Курбан Байрам قۇربان ھېيتىڭىزغا مۇبارەك بولسۇن

Пусть твоя жертва будет принятаقىلغان قۇربانلىقىڭىز قوبۇل بولسۇن

Пусть в семейной жизни будет счастьеئائىلە تۇرمۇشىڭىز بەختلىك بولسۇن

2.3.3 Поздравления в честь праздника Ураза байрам روزى ھېيتلىق قۇتلۇق ئىبارىلەر

Праздник Ураза Байрам также известен как Праздник прекращения поста, в котором верующие в ислам уйгуры, как и другие мусульманские массы, по религиозным традициям отмечают завершение поста. Зачастую произносят следующие поздравления:

С праздником Ураза Байрамروزى ھېيتىڭىزغا مۇبارەك بولسۇن

Пусть Аллах примет Ваш пост **ئاللاھ سىزنىڭ روزىڭىزنى قوبۇل قىلسۇن**

В заключении можно сказать, что поздравления уйгурского народа демонстрирует глубокое и сложное культурное содержание. Поскольку оценка поздравлений каждого народа носит условный характер, ведь одно и тоже поздравления будет иметь разное понимание в различных национально-инерционных суждениях и иметь различные культурные значения. К тому же, можно заметить, что все поздравления отражают религиозные убеждения уйгуров. Формирование и развитие поздравлений связано с социальной культурой уйгуров, на которых, несомненно, оказали значительное влияние древние религиозные верования. Изучение поздравлений уйгуров углубляет понимание их языка и культуры.

# «EGE-TÜRKOLOJİ»DE ÇAĞDAŞ TÜRK YAZI DİLLERİ ÖĞRETİMİ VE ARAŞTIRMASI

Mustafa Öner
Ege Üniversitesi
onerizmirli@gmail.com

**Аннотация**. В статье дается информация о развитии тюркологических исследований в Эгейском университете Турции. Дается характеристика по направлениям исследования и о научно-преподавательском коллективе.

**Ключевые слова:** Эгейский университет, тюркские языки, тюркология, родственные языки, лингвистика, филология.

1976'da İzmir'de Ege Üniversitesi içinde kurulan Edebiyat Fakültesi ve Türk Dili ve Edebiyatı Bölümü bugün 45 yaşında!..

Türkiye'de Fuad Köprülü, Reşit Rahmeti Arat, Ahmet Caferoğlu, Muharrem Ergin gibi bilginlerin şekillendirdiği İstanbul Üniversitesi Türkoloji mektebi ve Saadet Çağatay, Tahsin Banguoğlu, Hasan Eren, Zeynep Korkmaz gibi bilginlerin meydana getirdiği Ankara Üniversitesi DTCF Türkoloji mektebi, iki büyük katkı olarak «Ege-Türkoloji»nin akademik geleneklerinin esası olmuştur.

Bölümümüzde Selahattin Olcay ve Mehmet Akalın gibi dilci profesörlerin kuruculuğu ardından; İstanbul'da Muharrem Ergin, Faruk Kadri Timurtaş, Necmettin Hacıeminoğlu ve Kemal Eraslan gibi hocaların yanında Umumi Türk Dili kürsüsünde Çağatayca üzerine yazdığı doktora ile yetişen Altayist-Türkolog Prof. Dr. Günay Karaağaç (1949-) bölümün bugünkü dil araştırmaları ve öğretim yöntemlerini belirlemiş ve bugünkü dil kadrosunun hocası olarak bölümün tarihî-karşılaştırmalı dil bilimi karakterini vermiştir.

Prof. Dr. G. Karaağaç, 1985'ten itibaren 3 yıl boyunca görevli olduğu Macaristan'da (Budapeşte ve Szeged) özellikle Kuman asıllı Macar Türkoloğu István Mándoky Kongur'un (1944-1992) Altayistik, Türk Dünyası bütünlüğü ve Türk-Macar kardeşliği esaslı bilimsel ufkunun etkilerini taşıyan Prof. G. Karaağaç, bunu 1987'den emekli olduğu 2002 yılına kadar Ege-Türkoloji öğrencilerine de köklü bir bilimsel disiplin olarak yansıtmıştır.

Ülkemizin köklü akademik kurumlarından biri olan Ege Üniversitesi (1955) büyük bir kampüs kütüphanesine sahiptir. Bunun yanı sıra Ege-Türkoloji'de 1987 yılından sonra Çağdaş Türk Yazı Dilleri üzerine Türkiye'de benzeri olmayan bir özel kütüphane de meydana gelmiştir:

István Mándoky Kongur'un hocamız Günay Karaağaç'a hediye ettiği kitaplar, Macarca başta olmak üzere Ural Altay dilleri ve Altayistik üzerine yayınlar içerdiği gibi, Sovyet devri ilmî ve edebî külliyatları dolayısıyla Türk Dünyasında henüz gitmediğimiz sahalarda bile bize 1980'lerden itibaren araştırma yapma imkanı vermiştir.

Merhum Tatar üstadımız Prof. Dr. Ebrar Kerimullin'in sağlığında üniversite kütüphanemize bağışladığı şahsi kütüphanesi bugün de 1500'den fazla kitap ve dergisi ile eşsiz bir Tatar araştırmaları merkezi meydana getirmiştir.

Muhterem Hocam Günay Karaağaç'ın yanı sıra; Türk dili ve Türk Dünyası araştırmalarımda daima derin bir motivasyon kaynağı oluşturan Tatar Altayist-Türkoloğu Dr. Üzbek Bayçura'nın şahsen vasiyet ettiği kitaplarından Leningrad'dan İzmir'e taşınabilen bir kısmı, bölümdeki dil araştırmalarına temel olan çok değerli bir Türkoloji kitaplığıdır.

Nihayet *Tatar Halık Yazuçısı* Rinat S. Muhammediyev'in de 30 yıl boyunca şahsıma hediye ettiği seçkin Tatar edebiyatı külliyatları da eklenince bölümümüz aşağıda sunacağımız Çağdaş Türk Yazı Dilleri alanındaki bilimsel araştırmaların Türkiye'de önde gelen bir merkezi olarak belirmiştir.

Bölümdeki Türk Dünyası genişliğinde tarihî ve çağdaş dil araştırmaları ilk örneğini M. Öner'in master teziyle vermiştir: "ABDULLAH TUKAY'IN ŞİİRLERİ» (1990) 559 s. Türkiye'de basılan ilk Tatarca sözlüğün leksikolojik esası olan Tukay'ın şiirleri sonraki yıllarda da Tatarcaya başlayan her sınıfta bir öğretim materyali olarak daima kullanılmaktadır.

Tukay'ın söz varlığıyla başlayan ve sonra da yıllar içinde folklordan çağdaş edebiyata kadar 80 kadar çeşitli metinlerin söz varlığıyla biriktirilen Tatar leksikolojisi dayanan materyal (*corpus*), ilkin 2008 yılında ve sonra genişletilerek 2015 yılında Türk Dil Kurumu tarafından Kazan-Tatar Türkçesi Sözlüğü adıyla yayımlanmıştır.

Güçlü bir tarihî yazı dili mirası olan Tatarcanın merkeze alındığı bu girişim sonra da bütün Kıpçak yazı dillerine kadar genişletilen bir ilgi ile devam etmiştir. M. Öner'in Prof. G. Karaağaç tarafından yönetilen doktora tezi savunulduktan sonra TDK yayınları arasında iki kez (1998; 2012) basılmıştır. BUGÜNKÜ KIPÇAK TÜRKÇESİ (1995) başlıklı tez bölümün doktora programında bir ders olarak hazırlanmış ve Tatar, Başkurt, Kazak, Kırgız gibi başlıca Kıpçak yazı dillerinin öğretimine başlanmıştır. Edebî metinleri alfabelerinden, ses yapısına, morfolojisinden söz dizmine kadar karşılaştırmalı filoloji yöntemleriyle incelemek ve doktorantlara Türkiye Türkçesine uzak olan Kıpçak gramerinin disiplinini kazandırmak dersin amacıdır.

Bu derslerde A. Tukay, A. İshaki, H. Tufan; E. Şemizade, B. S. Çobanzade; S. Kudaş, M. Kerim; A. Kunanbay, M. Evezov gibi klasiklerden Zölfet, R. Harris, R. Zeydulla; Ş. Selim gibi çağdaş ediplere kadar yayılan seçilmiş metin örnekleri üzerinden gramer öğretimi yürütülmektedir. Bu dil incelemeleri sonucunda öğrencilerin; Kırım ve Kazan Tatar, Başkurt, Kazak edebiyatı örnekleri üzerinden, XIX. asır Çarlık, XX. asır başı millî edebiyat, ardından Sovyet dönemi ve nihayet 1991 ertesindeki çağdaş edebiyat ufuklarına ulaşması amaçlanmaktadır.

Bölümde bu alandaki ikinci doktora tezi, Özkan Öztekten'in ŞEYHZADE BABİÇ'İN ŞİİRLERİ, GİRİŞ-METİNLER-DİZİN, 477 s. (2002) başlıklı çalışmasıdır. Tez, İdil-Ural bölgesinde, XX. asır başındaki şiir klasiklerinden birini oluşturan Babiç'in şiirlerinin Arap harfli birinci yayımlarına dayanan belgesel tahlilli bir filoloji örneğidir, maalesef bugüne kadar basılmadan kalmıştır.

Doç. Dr. Özkan Öztekten bölümümüzde son yirmi yıl boyunca Arap harfli tarihî metinlerin (Eski Anadolu Türkçesi, Harezmce, Çağatayca, Osmanlıca vb.) uzmanı olarak öğretim vermekte, yüksek lisans ve doktora programları kapsamında genç

kuşakları yetiştirmektedir. İdil-Ural Türk filolojisi üzerine doçentlik çalışmasını da "*18. Yüzyılda Karışık Dilli Bir Metin Bahadur Şah'ın Arz-namesi*" başlığıyla yayımlayan Ö. Öztekten'in bilimsel çalışmaları arasında Tatar-Başkurt filolojisi ve grameri üzerine birçok çalışma ve yönettiği tez vardır (Özkan Öztekten | Ege University - Academia.edu)

Akademik öğrenimine Tatarca öğrenerek başlayan Prof. Dr. Hatice Şirin, Tatar şairi Hadi Taktaş'ın şiirleri üzerine bir diploma teziyle mezun olmuş sonra da HESEN TUFAN'IN ŞİİRLERİ, GİRİŞ-METİN-SÖZLÜK 740.s. (1998) başlıklı teziyle Tatar şiirinin klasiği üzerine bir tez hazırlamıştır. Başlangıcından Günümüze Türk Yazı Sistemleri başlıklı doktora tezinden sonra Eski Türk Filolojisine yönelen Prof. Dr. H. Şirin bölümümüzde Türk yazıtları üzerine uzman olarak öğretime devam etmektedir; son yıllarda Türk etimolojisine yoğunlaşan çalışmaları arasında Tatar-Başkurt filolojisi üzerine yayınları vardır ve İdil-Ural alanına ait master ve doktora öğrencileri de yetiştirmektedir. (Hatice ŞİRİN | Ege University - Academia.edu)

Bölümde Prof. Dr. G. Karaağaç'ın bizzat eğitimi altında yetişip biçimlenen bu üç Türkologun yetiştirdiği kuşaklar ise son 20 yıllık araştırma ve öğretim faaliyetinin aktörleri olmuştur. Bölümde Çağdaş Türk Dünyası disiplini ile yetişerek bugün Ege Üniversitesi'nin yanı sıra, başka öğretim kurumlarında da akademisyen olan (Murat Özşahin, Sinan Güzel, Mehmet Yasin Kaya, Ahmet Turan Türk, Ülkü Polat, Ezgi Sırtı Zopçuk, Seher Memişoğlu, Elmira Baimukhambetova, Habibe Halibryamova gibi) öğrencilerimizin Çağdaş Türk Yazı Dilleri üzerine hazırladığı doktora ve yüksek lisans tezleri ve yayınları ile bu bildiriyi olgunlaştırabiliriz; yapılan çalışmaları yazı dillerine göre sınıflandırarak değerlendirelim.

KAZAN-TATAR. Doktoralar:

Vedat Kartalcık, ŞERİF KEMAL'İN ROMANLARI 'AKÇARLAKLAR' ve 'TAN ATKANDA' ÜZERİNE DİL İNCELEMESİ (GİRİŞ-İNCELEME-METİN-DİZİNLER) 2008, [Danışman: M. Öner] 1000 s.

Ahmet Turan Türk, NURİHAN FETTAH'IN 'SIZGIRA TORGAN UKLAR' ROMANI ÜZERİNE DİL İNCELEMESİ (GİRİŞ-İNCELEME-METİN-DİZİN), 2014, [Danışman: M. Öner] 1432 s.

Bu doktora teziyle Tatarca üzerine odaklanan Dr. Ahmet Turan Türk (Çanakkale Onsekiz Mart Ü.) Arap harfli Tatar metinleri üzerinde yeni çalışmalar da yayımlamaktadır.

Kazan Tatar//Masterler:

Arife Gülsün, AYAZ İSHAKİ'NİN İKİ HİKÂYESİNDE SÖZ VARLIĞI, İKE YÖZ YILDAN SON İNKRAZ VE ZİNDAN» 2006, [Danışan: M. Öner] 1421 s.

Özlem Özmen ALİMCAN İBRAHİM'İN 'KAZAK KIZI' ROMANINDA SÖZ VARLIĞI, GİRİŞ-METİN-DİZİN, YL, 2006, [Danışman: M. Öner] 386 s.

Şirin Aksoy, BİR TATAR YAZARI GARİF AHUNOV'UN 'GOMER YULI' ADLI ROMANI ÜZERİNDE DİL İNCELEMESİ (GİRİŞ-METİN-DİZİN) 2011 [Danışman: Ö. Öztekten] 1033 s.

Seher Memiş, TATAR ŞAİRİ ZÖLFET'İN ŞİİRLERİ ÜZERİNE BİR DİL İNCELEMESİ: GİRİŞ-METİN-DİZİN, 2012, [Danışman: M. Öner] 766 s.

Erman Aydoğanlar, TATAR YAZARI TELGAT GALİULLİN'İN 'TEVBE' ADLI ROMANI ÜZERİNDE BİR DİL İNCELEMESİ (GİRİŞ-METİN-DİZİN) 2013, [Danışman: H. Şirin] 816 s

Dilek Uzunkaya, ALİMCAN İBRAHİM'İN 'TATAR HATINI NİLER KÜRMİY' ROMANI ÜZERİNE DİL İNCELEMESİ (GİRİŞ-METİN-DİZİN) 2014, [Danışman: M. Öner] 491 s.

Galiya, Saifutdinova, GABOR BALINT'İN DERLEMELERİNE GÖRE XIX. YY. TATARCASI (İNCELEME-METİN-DİZİN) 2018, [Danışman: M. Öner] 252 s.

Nazan Yapıcı, ALİMCAN İBRAHİM'İN ROMANI 'ADEMLER' ÜZERİNDE DİL İNCELEMESİ (GİRİŞ-METİN-DİZİN) 2018, [M. Öner] 272 s.

Aydın Gündüz, MÖDERRİS EGLEMOV'UN 'KİLEÇEKKE KAYTUV' ADLI ŞİİR KİTABI ÜZERİNE DİL İNCELEMESİ (GİRİŞ-METİN-DİZİN) 2020, [Danışman: M. Y. Kaya] 688 s.

BAŞKURT. KAZAK. Doktoralar:

Mehmet Yasin Kaya, İLYAS ESENBERLİN'İN 'KÖŞPENDİLER' ROMANI ÜZERİNDE KAZAKÇA DİL İNCELEMESİ (GİRİŞ-METİN-DİZİNLER) 2012, [Danışman: M. Öner] 1563 s.

İlkin Tatar-Başkurt alanında yetişen Dr. M. Yasin Kaya, doktora tezi olarak Kazak edebiyatının bu klasikleşmiş eserini filolojik ve leksikolojik bakımdan işlemiş ve daha sonra da çok sevilen bu romanın Türkçe yayımını yapmıştır.

Elmira Baimukhambetova, KAZAKÇANIN TARİHİ-KARŞILAŞTIRMALI DİL BİLGİSİ, 2019 [Danışman: M. Öner] 342 s.

Masterler:

Suzan Işık, ŞEKERİM KUDAYBERDİYEV'İN ŞİİRLERİ, GİRİŞ-METİN-DİZİN, YL, 2004, [Danışman: M. Öner] 352 s.

Alua, Toktarbayeva, SAKEN SEYFULLİN'İN 'ASAV TULPAR' ADLI ŞİİR KİTABI ÜZERİNDE KAZAKÇA DİL İNCELEMESİ (GİRİŞ-METİNLER-DİZİN), YL, 2019, [Danışman: M. Y. Kaya] 503 s.

Doktoralar:

Murat Özşahin, BAŞKURT TÜRKÇESİ SÖZ VARLIĞI, 2011,[Danışman: M. Öner] 3279 s.

Bu çalışma ile Başkurt leksikolojisine dair geniş bir söz varlığını işleyen Doç. Dr. M. Özşahin (Afyon Kocatepe Ü.) daha sonra TDK tarafından yayımlanan kapsamlı bir Başkurt sözlüğü de hazırlamıştır (2017, 717 s.)

Masterler:

Murat Özşahin, SEYFİ KUDAŞ'IN ŞİİRLERİ, GİRİŞ-METİNLER-DİZİN, 2005, [Danışman: M. Öner] 307 s.

Mehmet Yasin Kaya, MOSTAY KERİM'İN ŞİİRLERİ, GİRİŞ-METİNLER-DİZİN, 2005, [Danışman: G. Gülsevin] 319 s.

Fatma Eriş Soytürk, MECİT GAFURİ'NİN ŞİİRLERİ (GİRİŞ-METİN-DİZİN), YL, 2006, [Danışman: M. Öner] 534 s.

Mertcan Akgün, BAŞKURT MİTOLOJİK DESTANLARININ SÖZ VARLIĞI, YL, 2018, [Danışman M. Y. Kaya] 523 s.

ÇUVAŞ

Sinan Güzel, İLPEK MİKULAYİ'NİN 'TIVATI KÜN' ADLI ESERİ ÜZERİNDE ÇUVAŞÇA DİL İNCELEMESİ (GİRİŞ-METİN-DİZİNLER) 2012, [Danışman: M. Öner] 1599 s.

İlkin Tatar-Başkurt alanında yetişen Doç. Dr. Sinan Güzel (İzmir Katip Çelebi Ü.) bu doktora tezinden itibaren Çuvaşça üzerine odaklanmış ve sonraki yıllarda da İdil-Ural'daki bu eski Türk dili üzerine yayımlar yapmıştır.

KIRIM-TATAR. Doktoralar:

Seher Maşkaroğlu, KIRIM-TATAR SÖZ VARLIĞI, 2018 [Danışman: M. Öner] 2357 s.

İlkin Kazan-Tatarcasına odaklanan ve Zölfet'in şiirleri üzerine bir master tezi yazan Dr. S. Maşkaraoğlu (Kilis 7 Aralık Ü.) bu teziyle Kırım Tatar söz varlığına ait elimizdeki bütün metinleri ve sözlükleri biriktirip 49.000 kadar leksem içeren büyük bir sözlük hazırlamıştır ve bu eser TDK'de yayım durumundadır.

Masterler:

Abdülkadir Atıcı, ATICI, YILDIZ DERGİSİ-KIRIM TÜRKÇESİ DERLEMELERİ-I, 2008, [Danışman: Ö. Öztekten] 1777 s.

Elif Hendem, YILDIZ DERGİSİ-KIRIM TÜRKÇESİ DERLEMELERİ-II, 2008, [Danışman: H. Şirin] 1570 s.

Perihan Yiğit, YILDIZ DERGİSİ-KIRIM TÜRKÇESİ DERLEMELERİ-III, YL, 2008, [Danışman: M. Öner] 1724 s.

TARİHÎ-KARŞILAŞTIRMALI GRAMERLER

Ezgi Sırtı Zopçuk, KIPÇAK LEHÇELERİNDE KÖK FİİLLER (TARİHİ-KARŞILAŞTIRMALI SÖZ VARLIĞI İNCELEMESİ), DR, 2017, [Danışman: M. Öner] 495 s.

Habibe Halibryam, BUGÜNKÜ OĞUZ TÜRKÇESİ (TARİHİ-KARŞILAŞTIRMALI DİL BİLGİSİ), [Danışman: M. Öner] 2020, 1005 s

TEMATİK SÖZLÜK MASTER TEZLERİ

KARAÇAY-BALKAR

Ebru Yuradkul, KARAÇAY-BALKAR TÜRKÇESİ KONU ÇÖZÜMLEMELİ SÖZ VARLIĞI, YL, 2011, [Danışman: M. Öner] 567 s.

KARAKALPAK

Ahmet Demirhan, KARAKALPAK TÜRKÇESİ KONU ÇÖZÜMLEMELİ SÖZ VARLIĞI, YL, 2011, [Danışman: M. Öner] 278 s.

TÜRKMEN

Cihan Çakmak, TÜRKMEN TÜRKÇESİ KONU ÇÖZÜMLEMELİ SÖZ VARLIĞI, YL, 2010, [Danışman: M. Öner] 1392 s.

# ТУГАН (ТАТАР) ТЕЛ ДӘРЕСЛЕКЛӘРЕНДӘ ЭЛЕКТРОН ДӘРЕСЛЕКЛӘРНЕ ФАЙДАЛАНУ

Сәгъдиева Р.К., Хөснетдинов Д.Х.
КФУ Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты
ramsag777@rambler.ru, domer1982@mail.ru

**Аннотация.** На сегодняшний день у всех учебников общеобразовательных организаций среднего общего образования имеются электронные варианты. Статья посвящена рассмотрению содержания электронных учебников, используемых при обучении татарскому языку. Дается наставление учителям для эффективного использования инновационных технологий.
**Ключевые слова:** Учебник, электронный учебник, дидактические материалы, проверочная работа, тестирование, диктант, аудиозапись

Укучының белемнәрен системага салу, тирәнәйтү, яңа мәгълүмат бирү, укучыларның сөйләм һәм язу культурасын үстерү, аларны тәрбияләү – татар теле дәресләренең төп максаты. Бу максатка ирешүдә, укытучыларның иң беренче ярдәмчесе — дәреслек. Рус мәктәпләрендә укучы татар балалары өчен эшләнгән әлеге дәреслекләр [1, 2, 3, 4, 5] Федераль дәүләт белем стандартлары (ФДБС) таләпләренә җавап бирә.

РФ Фән һәм мәгариф министрлыгының «Федераль исемлеккә кергән дәреслекләргә таләпләр үзгәрүе турындагы» әмере (№1559, 8.12.2014) нигезендә, 2015 елның 1 нче сентябреннән федераль исемлеккә кергән һәр дәреслекнең электрон варианты булырга тиеш. Әлеге таләп басма китаплар урынына электрон форманы куллануга кертә башлауны, укучыларны калын-калын дәреслекләр күтәреп йөртүдән азат итүне, балаларны өстәмә материал белән тәэмин итүне һ.б. күз алдында тота. Россиянең кайбер төбәкләрендә нәкъ менә шундый дәреслекләрне файдалана да башлаганнар. Бүгенге көндә дәреслекнең электрон формасын куллану-кулланмау һәр мәктәп карамагына калдырыла. Мондый төр дәреслекләрнең уңайлыклары белән беррәттән четерекле яклары да юк түгел. Мәсәлән, һәр укучының да планшет белән тәэмин ителгән булуы кирәк, техника ватылган очракта нишләргә кебек сораулар, әлбәттә, уйландыра.

Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен V-IX сыйныф дәреслекләре төп гомуми белем бирү оешмаларына таратылды. Әлеге дәреслекләрнең электрон форматы диск рәвешендә дөнья күрде. Төп шартларның берсе буларак, басма һәм электрон дәреслекләр эчтәлек, төзелеш һәм бизәлеш ягыннан бер-берсенә тулысынча тәңгәл килә.

Хәзерге көндә барлык укучылар да татар теленнән электрон дәреслеккә күчәргә әзер түгел. Шуңа күрә югарыда аталган дәреслекләрнең электрон варианты, беренче чиратта, татар теле укытучылары өчен тәкъдим ителә. Ул өстәмә материал белән тулыландырылган. Укытучы бер УМК белән эшләгән очракта, һәр дәрестә басма һәм электрон дәреслектән уңышлы файдалана ала.

Анда дүрт төрле бирем урын алган: аудиоязма, диктант, тест һәм физкультминутлар өчен видеороликлар.

Электрон дәреслекләрне файдаланып, уку елы дәвамында күп кенә шигъри һәм чәчмә әсәрләрнең диктор тарафыннан укылышын тыңларга мөмкин. Әлеге төр биремнәр, беренче чиратта, укучыларга авазларны дөрес әйтергә өйрәтсә, икенче чиратта, аларны әсәрне сәнгатьле итеп укырга да өйрәтә. Укытучы электрон дәреслекне экранга чыгармыйча, әлеге төр биремне кулланып, хәтер диктантлары да яздыра ала. Кайбер очракларда шул ук текстларны изложение яздыру максатыннан да файдаланырга мөмкин. Укучы бер генә укытучының түгел, ә диктор сөйләмен дә отып калырга күнегергә тиеш. Басма дәреслектә ике өлешкә бүленеп бирелгән чәчмә текстлар да урын алган. Алар барысы да укучыны тәрбияләүне максат итеп куялар. Укытучы электрон дәреслекнең билгеле бер күнегүендәге текстның алдагы өлешен тыңлата, һәм укучыга әсәрнең дәвамын сөйләп карарга, теге яки бу ситуациягә үз фикерен белдерүен сорый. Укытучы укучыларга сораулар биреп, баланы сөйләштерә, сыйныфташлары белән аралаштыра, аларның фикерләрен тыңлый. Шуннан соң басма дәреслекне ачып, укучылар язучының фикере, ягъни әсәрнең дәвамы белән танышалар. Ахырдан нәтиҗә ясау: укучының фикерен дөрес юнәлешкә бору бик мөһим.

Электрон дәреслектә билгеле бер темалардан соң тестлар тәкъдим ителә. Һәр сорауга дүрт төрле җавап варианты күрсәтелә, укучы шуннан дөрес җавапны сайлап ала һәм аны саклый. Алдагы сорау автомат рәвештә үзеннән үзе ачыла һәм шул тәртиптә эш дәвам итә. Ахырдан соңгы биттә җавапларның нәтиҗәләре чыга, ягъни максимум ничә балл җыеп була иде, укучы күпме балл туплаган, ничә процент нәтиҗәлелеккә ия – барысы да ачык чагыла. Шунда ук җавапларны, хаталарны карау мөмкинчелеге тудырылган: бала һәр биремнең дөрес җаваплары белән таныша, анализ ясала, онытылган яисә начар үзләштерелгән теманы ныгыту эше алып барыла. Электрон дәреслектә урын алган тестлар ярдәмендә укытучы тиз вакыт аралыгында берничә укучының белемен тикшереп карый һәм бәяли ала.

Укытучыларга методик әсбаплар да тәкъдим ителә. Анда һәр дәреснең технологик картасы урын алган. Методик яктан һәр дәрестә динамик пауза булу шарт. Методик әсбапта динамик паузаларның кайсы күнегүне эшләгәннән соң үткәрелергә тиешлек күрсәтелеп барыла. Әлбәттә, бу авторларның тәкъдиме генә, укытучы һәр дәрескә технологик картаны яисә дәрес планын үзенчә эшләргә хокуклы. Ләкин электрон дәреслектә нәкъ менә методик әсбапта күрсәтелгән күнегүләрнең һәрберсе янында билгеле бер тамга белән, физкультминутлар ясату максатыннан, видеороликлар урын алган. Дәреслектә бик күп төрле видеоролик кулланылды. 5-7 нче сыйныфлар өчен бер төрле булса, 8 нче сыйныф укучылары өчен башка төр физик күнегүләр тәкъдим ителә. 5-7 нче сыйныфлар өчен төзелгән электрон дәреслекләрдә диктор сәнгатьле итеп шигырьне укый, бер укучы (егет яисә кыз) шундый төр күнегүләрне башкаралар. 8 нче сыйныфта, шулай ук яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, бөтенләй башка төрле физик күнегүләрне югары сыйныф

укучылары күрсәтә. Укытучы һәр дәреснең уртасында, видеороликны күрсәтеп, укучыларга физкультминут эшләтеп алырга мөмкин.

Электрон дәреслекнең тагын бер уңай ягы: укытучы һәр дәрес ахырында сүзлек яисә сүзтезмә диктантлары яздыру мөмкинлегенә ия. Технологик картада күрсәтелгән һәр дәрес ахырында диктантлар бар. Алар һәрвакыт 6 сүзне яисә сүзтезмәне үз эченә алган. Дәрес дәвамында кулланылган текстларда очраган авыр сүзләрне укучы исендә калдырып, диктант язып карый ала. Аларны диктор укый, укучы әйтелешне тыңлый һәм яза. Уң яктагы түгәрәккә басып, җавабын тикшерә. Дөрес язылган очракта яшел дөрес дигән тамга чыга, әгәр хата киткән булса, кызыл х тамгасы пәйда була. Бу очракта укучы яңадан дикторны тыңлый ала һәм кабаттан яза, үз-үзен тикшерә. Берничә дәрес дәвамында укытучы шундый төр биремне эшләткәннән соң, укучылар алга таба дәрес барышында текстларның һәр сүзен игътибар белән укып, язылышын исендә калдырып барырга омтылачак. Бер дәрестә язган сүз алдагы дәресләрдә очрамый. Һәр дәрес ахырында укучы яңа сүзнең язылышын исендә калдыра.

Шунысы кызык: теге яки бу дәрес вакытында диктант яздырганнан соң яисә тестларны эшләткәннән соң, электрон дәреслек кире шул биткә әйләнеп кайта. Укытучы да, укучыда яңадан әлеге битне эзләп утырмый. Бу бик уңайлы, укытучының эшен нык җиңеләйтә, системаның уңайлы һәм төгәл эшләнгәнлеге хакында сөйли.

Электрон дәреслек Интернет белән бәйләнмәгән, ягъни аны ачып эшләткәндә Интернет кирәк түгел.

Алда әйтелгәнчә, электрон дәреслек басма дәреслекне сүзгә сүз, биткә бит кабатласа да, анда укытучы һәр дәрестә куллана алырлык кызыклы биремнәр һәм эш төрләре чагылыш тапкан. Яңа теманы аңлату өчен дә әлеге төр дәреслекләр уңайлы, тактада ачып укучыга юнәлеш бирелә, бала эзләнә, күзәтә, уйлана һәм нәтиҗә ясый. Аннары гына укытучы теге яки бу кагыйдәне экранда күрсәтә, һәм укучы үзенең нәтиҗәсе белән грамматик кагыйдәләрне чагыштыра, фикер алышуда катнаша.

Заман үзгәрә, үсә, шуның белән беррәттән һәр нәрсә яңалык белән баетыла. Басма дәреслекләрнең электрон төре укучыларга да, укытучыларга да файдалы булыр дип өметләнәсе килә. Әлеге яңа төр форма җәмгыятебездә урнашып кына бара. Вакыт узу белән электрон дәреслекләр тагын да камилләшәчәк, укучының белем дәрәҗәсен арттыруда мөһим роль уйнаячак.

**Әдәбият**

1. Сәгъдиева Р.К., Гарәпшина Р.М., Хәйруллина Г.И. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 6 нчы с-ф. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшр., 2015. – 191 б.

2. Сәгъдиева Р.К., Кадирова Э.Х. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 9 нчы с-ф. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшр., 2017. –143 б.

3. Сәгъдиева Р.К., Харисова Г.Ф., Сабирҗанова Л.К., Нуриева М.Ә. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 7 нче с-ф. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшр., 2015. –215 б.

4. Сәгъдиева Р.К., Хәйруллина Г.И. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 8 нче с-ф. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшр., 2016. –223 б.

5. Шәмсетдинова Р.Р., Һадиева Г.К., Һадиева Г.В. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 5 нче с-ф. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшр., 2015. –175 б.

# СҮЗ СӘНГАТЕНДӘ КЕШЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘРЕНЕҢ БИРЕЛЕШЕ

Сабирҗанова Р. Р.
Казан шәһәренең 72нче мәктәбе
ruzila79@yandex.ru

**Аннотация**. В этой научной статье речь идет об изучении человеческих ценностей на уроках родного языка и родной литературы. Приводится анализ творческих заданий при преподавании литературного материала.
**Ключевые слова**: воспитание, человеческие ценности, мораль, творческие задания.

Тәрбия эше бервакытта да җиңел булмаган. Бүген ул аеруча кыен чор кичерә. Чөнки хәзерге буын әти-әниләрнең күбесе ишле гаиләдә үсмәгән, әби-бабайлардан аерым тору сәбәпле, аларның кыйммәтле рухи мирасыннан мәхрүм калган. Еш кына балалар буш вакытларын компьютер каршында, урамда үткәрә, аларны телевизор, урам тәрбияли. Үгет-нәсихәт, боеру аша балалары белән уртак тел таба алмаучылар да җитәрлек. Тәрбиянең нигезе – гаилә. Һәрбер әти-әни баласын итәгатьле, эш сөючән, белемле, кешелекле, ихтирамлы итеп тәрбияләргә тели. Әмма теләк белән чынбарлык арасында кайвакыт зур аерма була. Чын тәрбия берьяклы гына була алмый. Тәрбиянең төп асылы – мәктәп белән гаиләнең бердәмлеге. Алар бер юнәлештә эшләгәндә генә уңышка ирешергә мөмкин. Бердәм булганда гына гаилә белән мәктәпнең эшләү нәтиҗәсе яхшы күренә. Бала үзенең көндәлек тормышында гаиләдәге, мәктәптәге, үзе яшәгән мохиттәге традицияләрне истә тотып эш итә. Әлеге традицияләрнең нинди булуы укучының киләчәк тормышына, шәхес буларак формалашуына хәлиткеч йогынты ясый. Тәрбия процессы ата-анадан, мәктәптәге укытучы-тәрбиячеләрдән килешеп эшләүне, акыл һәм көч егәрлеген бер максатка туплауны сорый.

Мәсәлән, һәрбер дәрестә, белем бирүдән тыш, тәрбияви максат та куелырга тиеш. Туган тел һәм әдәбият дәресләрендә бу проблемага зур игътибар бирәбез. Бу эшне ничек алып барырга мөмкин соң?

“Кешене әхлаклылык бизи”, – диләр. Иң беренче чиратта, укучыларны исәнләшергә һәм саубуллашырга өйрәтү зарур. Халык авыз иҗатына да мөрәҗәгать итү урынлы.

Татар төркемнәрендә мәкальләрнең мәгънәсен аңлатуны тәкъдим итәргә була: *Олыларны хөрмәт ит, кечеләргә шәфкать ит. Олыласаң олыны, олылалар үзеңне. Ата-ананы тыңлаган адәм булган, тыңламаган –әрәм булган.*

Тагын бер кызыклы эш төре булып, шигъри юллардагы төшеп калган сүзләрне уйлап язу тора. Мисал өчен: *Алдыңмы гармун (кулыңа) – /Син (уйна). // (Эшкә) тотыныр алдыннан/ (Нык) уйла. // Учагыңны (сүндерергә) /Онытма. // Чын дус (тапсаң), араларны /(Суытма). //Ялган сизсәң, дәшми (калма), / Йөзен (ач). // Юкка мактау (ишетелсә), / (Тизрәк) кач. //*

Дөрес, урынлы файдаланганда мәзәк тә яхшы тәрбия чарасы була ала икән. “Кеше холкын күзәт, үзеңнекен төзәт”, – ди халкыбыз .

Тел дәресләрендә лексик-грамматик күнегүләр эшләүне дә мавыктыргыч итәргә мөмкин. Әйтик, бирелгән аңлатманы бер сүз белән алмаштырырга кирәк: *Үз-үзен тотышында җәмгыятьтә кабул ителгән кагыйдәләрдән чыкмый торган кеше – ... (тәртипле). Кызгану, мәрхәмәт күрсәтү – ... (шәфкатьлелек). Инсафлы, тыйнак, үзен тота белә торган – ... (әдәпле). Тиешле әдәп кагыйдәләренә өйрәтү – ... (тәрбияләү). Намуслы, гадел – ... (вөҗданлы). Дөреслекне яклый торган, хак – (гадел).*

Алдагы эш төре “Җөмләнең ахырын уйла”, – дип атала:

*Шәфкатьлелек ул − минемчә, ... (игелеклелек, олыларга булышу, кечкенәләргә ярдәм итү, миһербанлылык, әти -әнине кайгырту, олыларның сүзен тыңлау, мәктәптә яхшы уку, авыруларның хәлен белү, күршедә яшәүче әби-бабайларга эшләрендә ярдәм кулын сузу, тәмле телле булу).*

Тәрбияви максатларга ирешүдә, әдәби әсәрләрдән өзекләр алып, проблемалы ситуацияләр бирү дә отышлы.

Татар халкында “Яхшылык ит тә суга сал, халык белмәсә, балык белер”, – дигән әйтем бар. Без балаларга бу гыйбарәне истә калдырырга, һәр көн игелекле гамәлләр кылырга, кешеләргә карата миһербанлы, шәфкатьле булырга өндәргә тиешбез.

**Әдәбият**

Раушан көзге. Татар балалар әдәбиятыннан хрестоматия. - Казан "Мәгариф" нәшрияты, 1993, -7 б.

Татар халык әкиятләре. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1986, - 6 б.

# ХАРАКТЕРНЫЕ ОСОБЕННОСТИ ИСПОЛЬЗОВАНИЯ КОМПОНЕНТОВ-ЗООНИМОВ В ПОСЛОВИЦАХ ТУРЕЦКОГО И ТАТАРСКОГО ЯЗЫКОВ

Саде Бейза
Турция, Анкара
modatadinda@gmail.com

**Аннотация.** В статье рассматриваются особенности пословиц с компонентом-зоонимом в турецком и татарском языках. Автор работы анализирует компоненты и выявляет частотность употребления пословиц с компонентом-зоонимом в турецком и татарском языках, анализирует специфические качества и свойства пословиц.
**Ключевые слова:** турецкий язык, татарский язык, пословица, зооним.

Язык – это вечно движущийся и вечно развивающийся организм, непрерывно вызывающий интерес к изучению и понимаю его свойств и функций. Любой язык, независимо от того, к какому семейству он принадлежит, является величайшим богатством народа, он обладает колоссальным набором элементов, отражающих народную мудрость и культуру. Одним из таких элементов являются пословицы, обладающие ярко выраженным национальным характером и наглядно демонстрирующие восприятие тем или иным народом различных жизненных явлений, ценностей. Как турецкие, так и татарские пословицы не являются исключением из этого правила и составляют неизменную часть как разговорного, так и литературного языков.

При изучении турецких и татарских пословиц мы обнаружили как универсальные для обоих языков, так и уникальные для каждого языка выражения с компонентом зоонимом. Зоонимы являются одним из самых важных пластов лексики во всех языках мира. Характеризуя свое поведение, чувства, состояния, человек прибегает к сравнению с тем, что ему ближе и похоже на него самого — животным миром.

При сравнении пословиц с компонентом-зоонимом в татарском и турецком языках можно выделить несколько типов:

1. Пословицы, совпадающие и по значению, и по компоненту-зоониму: *тур. «Aç tavuk kendini arpa ambarında sanır» – тат. «Тавык төшенә тары керә»; тур. «Aç ayı oynatamaz» – тат. «Ач аю уйнамас»; тур. «Kurttan korkan ormana gitmez» – тат. «Бүредән курыккан урманга бармас»; тур. «Beleş atın dişine bakılmaz» – тат. «Бирелгән атның тешен санамыйлар»; тур. «Balık baştan kokar» – тат. «Балык баштан чери».*

2. Пословицы с одинаковым зоокомпонентом и разной структурой: *тур. «Ayıyı evvela öldür de sonra derisini sat» – тат. «Аюны үтермәс борын тиресен сатма».*

3. Пословицы с совпадающим значением, но разной структурой и зоокомпонентом: *тур. «Bugünkü tavuk yarınki kazdan iyidir» – тат. «Һавадыгы торнага ышанып, кулыңдагы чыпчыкны очырма»; тур. «Ayıyı evvela öldür de sonra derisini sat» – тат. «Тавык йомырка салмаган, чебешләрне сатарга уйлый»; тур. «Pireyi deve yaptak» – тат. «Чебеннән фил ясама»; тур. «Şahin yavrusu serçe olmaz» – тат. «Арыслан баласы арыслан булыр»*.

4. Пословицы, в которых одному компоненту-зоониму в другом языке соответствует несколько зоонимов: *тур. «Ayıyı evvela öldür de sonra derisini sat» – тат. «Үтермәгән аюның тиресен тунау», «Алмаган ат, тумаган тай», «Тавык йомырка салмаган, чебешләрне сатарга уйлый»*.

Сравнительный анализ показывает, что своеобразие языковых традиций употребления компонентов-зоонимов в качестве компонентов пословиц есть яркое проявление национального лингвистического своеобразия.

Сравнение зоонимов, используемых в турецких и татарских пословицах, позволяет выявить группы, характеризующие домашних животных, диких животных, птиц, пресмыкающихся, наиболее типичными образами которых в пословичном фонде обеих языков являются «баран», «овца», «курица», «медведь», «волк» и другие. Основной характеристикой исследуемых единиц является наличие оценочности состояния, качества, поведения, привычек человека, по отношению к которому пословица употребляется.

В турецком языке пословица *Kurttan korkan ormana gitmez (Кто боится аолка, тот в лес не пойдет)* характеризует робкого человека, у которого не хватает смелости на отчаянный поступок. Для выражения такого же значения в татарском языке употребляется название другого животного: *Аюдан курыккан урманга бармас.*

Зооним «корова» в пословицах обоих языков может использоваться как в положительном, так и в отрицательном значении. Положительный назидательный оценочный знак отмечен в татарских пословицах: *Ишек алдында сыерың булса, табыныңда маең булыр; Сыерны сөтенә карап ал*. В конкретной речевой ситуации ей соответствуют турецкие пословицы: *Zemheride yoğurt isteyen cebinde bir inek taşır*. Зооним «корова» с отрицательной маркировкой употребляется в татарской пословице *Сөзгәк сыерга Ходай мөгез бирми*.

В турецком и татарском языках пословицы с зоонимом «лошадь» могут ассоциироваться как с положительным, так и с отрицательным значением. Например, пословицы с положительным значением: *Yavaş atın tekmesi pek olur; Atın bahtsızı arabaya düşer; Atın ölümü arpadan olsun; Eğer koca bir kurt yardım ederse, sivri sinek de ata hükmeder; Arık ata, kuyruğu da yüktür; Aslan kükrerse atın ayağı kösteklenir; Atın ürkeği, yiğidin korkağı; Олы ат белән уйнаган тайның аягы сынар; Уртак аттан тай артык; Керле кешенең аты тирле; Алтмыш колын ат булмас; Алама атка менгәнче, йөгер кеше күргәнче; Атның аламасы кеше тибеп үтерә; Атым яхшы дип, чыбыркыңны куйма; Барасы килмәгән ат тәртәгә тибә.*

Следующие турецкие и татарские пословицы с зоонимом «лошадь» сопровождаются назидательным значением: *At almadan ahır dikme; Atın sağlıklı ise yoldan korkma; Үз атыңны сынар өчен үз атыңа утыр; Атсыз ир – канатсыз кош; Аты барның канаты бар, сыеры барның сые бар.*

Таким образом, анализ фактического языкового материала, позволил сделать следующие выводы. Зоонимы в пословицах турецкого и татарского языков – чрезвычайно интересный и самобытный языковой пласт, выявляющий специфику мировосприятия носителей языка и культуры. В пословицах турецкого и татарского языков использованы красочные образы и сравнения, они богаты иронией и тонкими наблюдениями.

**Литература**

1. Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре: мәкальләр җыелмасы: 3 томда. 1 т. 2-нче басма. – Казан: Татар кит. нәшр., 2010. – 623 б.

2. Ermakova L., Üçgül S. Kısa Rusça-Türkçe Deyimler Sözlüğü. – İstanbul, 1998. – 34 s.

# ЛЕКСИКОГРАФИЧЕСКОЕ ОПИСАНИЕ МИФОЛОГИЧЕСКОГО ПЕРСОНАЖА “ДИЮ”

Салахова А.Р,
Казанский федеральный университет
alsusalakh@mail.ru

**Аннотация**. В ходе нашего научного исследования мы изучили пять словарей: толковый, энциклопедический словарь татарской мифологии, словарь диалектов татарского языка, антонимов и синонимов. Интересно то, что мифологический персонаж “Дию” (или “Дию пәрие”) бывает не только отрицательным, но и положительным героем, также нужно подчеркнуть, что этот мифологический образ встречается в литературе многих народов, и в них он описывается по-разному.
**Ключевые слова:** миф, мифология, “Дию”, Див, “Дию пәрие”, лексикография, лексикографическое описание.

Актуальность данной научной работы определяется, во-первых, возрастающим интересом современной лингвистики к проявлению национального менталитета в языке; во-вторых, частотностью слов-мифологем в татарском фольклоре, художественной литературе; в-третьих, необходимостью комплексного изучения духовной культуры, что в свою очередь может существенно продвинуть нас в познании различных сторон общественно-социальной жизни человека и языка в том числе.

Как известно, понятие мифа, мифологии еще остается спорным, ведь нет общепризнанного, единого для всех исследователей термина, обозначающего единицы мифологической лексики. Мы в свою очередь взяли в основу определение С.А. Кузнецова: “Древнее народное сказание о богах и обожествлённых героях, о происхождении мироздания и жизни на Земле”[6]. Мифологический персонаж понимается как «пучок релевантных признаков и функций, скрепленных именем» [3: 99].

Самым распространенным сюжетом мифологии разных народов и культур является борьба человека-героя с “враждебными” силами, которая в то же самое время повышает лучшие его качества, поражение в этой схватке имеет далеко идущие последствия для дальнейшего развития мира. Мифологическим персонажем таких событии в татарском сказочном мире можно выделить несколько образов. Это Дию (Див), Елан (Змей), Аждаһа (Дракон), Юха (Змееподобное чудище) и т.п. В нашей научной статье мы рассмотрим описания мифологического персонажа “Дию” в татарской лексикографии.

Образ Дива встречается в мифологии разных народов. Дэвы/Дивы - общие божества славян, иранцев, тюрок и индийцев. Во времена индоевропейской общности, мифология будущих персов, балтов, славян, иранцев и тохар имела общих божеств - дивов. Со временем, одни народы утратили этих существ, другие наоборот распространили их и среди тюркских народов.

В толковом словаре татарского языка слово «Дию» описывается в двух значениях: как глагол означает “сказать”, как существительное “мифическое создание”. Мы рассмотрели только второе значение - “очень страшное, некрасивое мифическое существо, может быть с одной, тремя и более головами, съедает людей”. Также в словаре приведено слово “Дию пәрие” - значение в словаре идинтичное [8; 187].

В энциклопедическом словаре татарской мифологии Ф.И.Урманчеева «Див» описывается как огоромное трех-шести, девяти-двенатцатиголовое чудище. “Киргизские ученые выделяют следующие качества Дию: демоническое существо внешне похожее на человека, его огромное тело покрыто густой шерстью, на лбу рог, и зубы, и когти очень острые, может летать, обладает горомной силой, живет на горе Каф или в пустыне, обычно очень злой и заклятый враг человека, но иногда положительный персонаж, который помогает главному герою. В татарской мифологии Дию обладает теми же качествами” [11; 21].

В диалектах другие эквиваленты слова “Дию” не обнаружены.

В синонимическом словаре татарского языка (Ш.С.Ханбикова и Ф.С.Сафиуллина) “Дию” (див, чудовище) приведены такие примеры как “гыйфрит”, “пәри”, “җен” [7; 35].

В словаре антонимов татарского языка (Ф.С.Сафиуллина) эквиваленты слова “Дию” не представлены.

В словаре “Язык татарского фольклора: пословицы, крылатые выражения, присловья и поговорки” мифоним “Дию” встречается три раза и приводятся следующие поговорки: “Юләрдән дию пәрие дә качкан” (От дурачка и Див убежит), “Диюгә тәмуг юлын күрсәтмәсәң, оҗмах юлын белмәс” (Если Диву не покажешь дорогу в ад, то он не узнает где дорога в рай), “Сөләйман үлде, диюләр котылды” (Сулейман умер, Дивы освободились) [10; 128].

Таким образом, мифоним “Дию” довольно хорошо описан в татарской соверменной лексикографии. Татары использует это слово не только в сказках и мифах, но и в пословицах, в литературе, в быту. “Дию” или “Дию пәрие” в татарских сказках сохраняет свои основные качества, приведенные в древнеиранской мифологии и зараостризме, и становится одним из самых популярных образов в национальных сказках. Его можно встретить в таких сказках, как “Чүмеч”, “Аучы малае”, там он описывается как злодей, а в сказке “Дутан батыр” можно увидеть Дию, которое помогает главному герою. Доброта этого мифического существа объясняется его до зараострическим, древними характеристиками.

**Литература**

1. Әхмәтьянов, Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда. I том (А—Л). — Казан: Мәгариф — Вакыт, 2015. — 543 б. - Б. 77.

2. Җамалетдинов Л.Ш. Татар әкиятләрен барлау юлында / төз. И.И. Ямалтдинов. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – 264 б.

3. Левкиевская Е. Мифы русского народа. — М.: ООО «Издательство Астрель»; 528 с.

4. Литература древнего Востока. Иран, Индия, Китай (тексты). Авторы-сост. Ю. М. Алиханова, В. Б. Никитина, Л. Е. Померанцева. — М.: Изд-во МГУ, 1984. 352 с.

5. Мифология. Большой энциклопедический словарь/ Гл. Ред. Е.М.Мелетинский. – 4-е изд. – М: Большая Российская энциклопедия, 1998. – 736 с.

6. Новейший большой толковый словарь русского языка / гл. ред. С. А. Кузнецов. — СПб., М.: Норинт; Рипол классик, 2008. — 1534 с. https://gufo.me/dict/kuznetsov

7. Синонимнар сүзлеге / төз.: Ш.С.Ханбикова, Ф.С.Сафиуллина - Хәтер, Казан, 1999, 255 б.

8. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: II том: Г-Й. – Казан: ТӘһСИ, 2016. – 748 б.

9. Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / төз.: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р.Садыйкова, Т.Х.Хәйретиднова. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2009. – 839 б.

10. Татар фольклоры теле: мәкальләр, канатлы әйтелмәләр, җор сүзләр һәм әйтемнәр: сүзлек = Язык татарского фольклора: пословицы, крылатые выражения, присловья и поговорки: словарь / К.Р. Галиуллин; фәнни ред. К.М. Миңнуллин. – Казан: ТӘһСИ, 2018. – 588 б.

11. Урманче Ф.И. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 1 т. (А-Г) / Фатих Урманче. - Казан: Мәгариф, 2008. - 303 б.

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ИСЕМ ФИГЫЛЬ
# ҺӘМ АНЫ УКЫТУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Саматова И.Р.
МБОУ “Лицей имени В.В. Карпова”
ilzirashka88@mail.ru

**Аннотация.** В работе рассмотрена структура имени действия. Дан краткий обзор этих структур. На основе анализа фактического материала доказано, что синтетические формы имени действия используются в речи чаще.
**Ключевые слова:** имя действия, фразеологизмы, конверсия, синтетические формы имени действия, активность, продуктивность.

Теге яки бу телдә сөйли белүче ул телнең һәрбер конкрет җөмләсен хәтерендә йөртми, бәлки ул сүзләрне. бәйләүче чараларны һәм җөмләнең шул телгә хас калыпларын гына үзләштергән була. Нәрсә турында булса да хәбәр итәргә кирәк булганда, сөйләүче кеше җөмләнең билгеле калыпларына сүзләрне бер-берсенә бәйләп салып бара, һәм шулай итеп, сөйләм барлыкка килә. Сүзләрнең сөйләм оештырудагы рольләреннән чыгып, сүз төркемнәрен иң элек түбәндәге ике зур төркемгә аералар: 1)мөстәкыйль сүз төркемнәре, 2) ярдәмлек сүз төркемнәре. Мөстәкыйль сүз төркемнәре, барыннан да элек төшенчәләрне белдерәләр һәм, сөйләмдә бергә оешып, хәбәрлек барлыкка китерәләр. Фигыль - шундый сүз төркемнәренең берсе һәм иң катлаулысы. Фигыльнең сүз буларак мәгънәсен өйрәнү ике яклап әһәмиятле. Беренчедән, грамматик категорияләр никадәр абстракт булмасыннар, җентекләп тикшергәндә, аларның гомумиләшкән лексик мәгънәгә бөтенләй үк битараф булмавы ачыла. Лексик мәгънәгә бәйле рәвештә кайбер сүзләр грамматик мәгънәгә яңа төсмерләр өсти, аны үзгәртә алалар, кайбер грамматик категорияләрне алар бөтенләй кабул итми яки аларның төрләнеше чикләнгән була.

Икенчедән, фигыль үзенең семантик табигате белән предметны һәм предметлыкны белдергән исемнәрдән бик нык аерыла, чөнки ул чынбарлыктагы предметларның үзләрен түгел, бәлки алар арасындагы мөнәсәбәтләрне белдерә. Фигыльнең мәгънәсе дә шул сүзләр белән бәйләнештә генә ачыла. Ләкин теге яки бу фигыль кулланылган контекстлар һәм ул белдергән мөнәсәбәтләр гаять күптөрле була, шуңа күрә фигыльнең мәгънәсе дә киң булуы белән аерылып тора.

Фәнни эшебезнең асылы затланышсыз фигыльләрнең бер төре – исем фигыльләрне өйрәнүдән гыйбарәт булды. Хезмәтебезне язу барышында исем фигыльләр генә түгел, гомумән барлык фигыльләр системасы күздә тотылды. Аерым бер фигыль формасын киң аспектта тикшерү, барлык фигыль сүз төркеменең күп кенә яңа үзенчәлекләрен ачуда зур роль уйный. Исемнең башка сүз төркемнәре, мәсәлән исемнәр, сыйфатларга мөнәсәбәте ачыкланды. Бу сүз төркемнәренең исем фигыльләр белән уртак һәм аермалы яклары

билгеләнде. Аларны бер-берсеннән аеруның төп критерие булып, әлбәттә, җөмлә тора. Бары тик җөмлә эчендә генә бу фигыль формаларын һәм алар белдергән мәгънә үзенчәлекләрен төгәл ачыкларга мөмкин. Фәнни эшебездә исем фигыльләр темасын яктырту өчен хәзерге көндә дә бик актив иҗади эш алып баручы язучыбыз М.Маликованың "Кызыл гөл" әсәреннән файдалануыбыз шуның белән аңлатыла.

Гадәттә, мәктәп программаларында, исем фигыльләрнең төп формалары һәм аларның контекстка бәйсез мәгънәләре белән генә эш ителә. Әмма контекст эчендә, төрле сүзләр чолганышында килгәндә, исем фигыльнең үзәк категорияләре мәгънә төсмерләрен үзгәртә дә ала. Фәнни эшебезгә куелган төп бурычларның берсе әнә шундый мәгънәләрне ачыклау иде. Хезмәтебездә исем фигыльләргә төрле аспекттан чыгып анализ ясарга тырыштык. Фәнни эшен язу барышында шактый кызыклы мәгълүматлар тупланылды һәм аларның һәрберсенә әдәби әсәрләрдән мисаллар китерелеп барылды. Хезмәтебезнең нәтиҗәләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Хәзерге татар әдәби теленең норма таләбе нигезендә, исем фигыль ***–у/-ү*** формасында кулланыла. Татар теленең диалект сөйләшләрендә исә исем фигыль ***–у/-ү, -ыш/-еш, -мак/-мәк, -мыш/-меш*** формаларында реальләшә. Әдәби әсәрләрдә хәзерге көндә кулланыла торган ***–у/-ү*** формасы белән беррәтән ***–ганлык/-гәнлек*** кебек формаларны да очратырга туры килде.

Хәзерге татар әдәби телендәге *–**у/-ү*** исем фигыль формасы без тикшергән әсәрдә дә киң кулланылыш алган. Биредә алар төрле юнәлеш кушымчалары алган хәлдә дә, барлык һәм юклык формаларында да бик еш орадылар. Хәтта бер үк җөмләдә берничә исем фигыль кулланылган очраклар да күзәтелде.

Фәнни эшебездә һәр фигыль формасына, шул исәптән, исем фигыльгә дә хас булган дәрәҗә категориясе аерым бер бүлекчәдә тикшерелде. Дәрәҗә категориясенең аналитик формалары әсәрдә ешрак кулланылган. Бу исем фигыльләргә генә кагылмый. Гомумән синтетик формалар телдә үзләренең активлыкларын югалтып баралардыр дигән нәтиҗәгә килдек. Дөрес, башка фигыльләрдә аның синтетик формалары (***-гала/-гәлә, -ыштыр/-ештер***) күзәтелде, әмма аларның да саны аз. Әлбәттә, бу язучының иҗат алымы, язу стиле белән дә бәйле.

Фәнни эшен язу барышында исем фигыльләрнең структурасына (төзелешенә) дә игътибар иттек һәм исем фигыльнең синтетик формалары ешрак кулланылган дигән нәтиҗәгә килдек. Кушма төзелешле исем фигыльләрнең түбәндәг төрләре ачыкланды:

- парлы тезмә исем фигыльләр;
- тезмә исем фигыльләр;
- фразеологик нигезле исем фигыльләр;

Шулар арасында иң киң кулланылганы – тезмә исем фигыльләр һәм алардан кала фразеологик нигезле исем фигыльләр. Без тикшергән әсәрдә *Җирәнү катыш **куралмау** хисе(25)* дигән җөмләдә *куралмау* исем фигыле күчерелмә мәгънәдә кулланылган сүз тезмәсе буларак фразеологизмнар рәтендә каралырга тиеш дип саныйбыз, ул *яратмау, үз итмәү* кебек мәгънәне белдерә. Әмма

төзелеше буенча ул саф кушма төзелешле фигыльләргә охшаш. Мондый очракларны хәзерге татар әдәби телендә еш күзәтергә мөмкин. Без исә әлеге җөмләдәге *куралмау* сүзен фразеологизм буларак теркәдек, чөнки анда күчерелмә мәгънәлелек көчлерәк.

Исем фигыльләрнең тагын бер үзенчәлекле ягы - конверсияләнүе. Татар телендә исем фигыльнең ***–у/-ү, -ыш/-еш, -мыш/-меш*** формалары конверсиягә дучар була. Хәзерге татар телендә әдәби норма нигезендә кулланыла торган ***–у/-ү*** формалы исем фигыльләр исемнәргә һәм сыйфатларга күчәләр.

Әсәрдә исем фигыльләрнең бәйлекләр белән һәм хәбәрлек сүзләр белән кулланылу очракларына да мисаллар китерелде, бүлек ахырында әлеге мәсьәләргә кагылышлы нәтиҗәләр яктыртылды.

Шулай итеп, фәнни эшебездә алынган нәтиҗәләр, күпмедер дәрәҗәдә, исем фигыльләр һәм гомумән фигыль категориясенә хас булган үзенчәлекләрне ачыкларга, бу өлкәдә алган белемнәребезне тагын да тирәнәйтергә мөмкинлек бирде.

Хезмәтебезнең нәтиҗәләре, тәкъдим ителгән эш төрләре киләчәктә, укыту процессында, һичшиксез, үзенең лаеклы урынын табар дип ышанып калабыз.

**Әдәбият**


1. Алпаров Г. Сайланма хезмәтләр. - Казан, 1945. - 117 б.
2. Ахунҗанов Г.Х. Образлы фразеологик әйтелмәләрнең телдәге роле // Сов.мәктәбе. – 1961. - №9. – Б.37-41.
3. Ганиев Ф.А. Суффиксальное словообразование в современном татарском языке. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1974. – 231 б.
4. Ганиев Ф.А. Образование сложных слов в татарском языке. – Казань: “Печатный двор”, 2002. – 192 с.
5. Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге: Ике томда. II том. – Казан: Тат. кит.нәшр., 1990. -365 б.
6. Маликова М.Г. Кызыл гөл: Романнар. – Казан: Татар. кит.нәшр., 2005. – 414б.
7. Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. - Казан: Мәгариф, 1998. - 315 б.
8. Серебренников Б. Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. – Баку: «Магариф», 1979. – 288 с.
9. Татар грамматикасы. 3 томда.Т.1. - М: “Инсан”, Казан: “Фикер”, 1998. – 510б.
10. Тумашева Д.Г. Көнбатыш Себер татарлары теле. Грамматик очерк һәм сүзлек. – Казан, КДУ нәшрияты, 1961. – 248 б.
11. Харисова Ч.М. Татар теле: Теория, күнегүләр, тестлар. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2006. – 206 б.
12. Юсупов Ф.Ю. Неличные формы глагола в диалектах татарского языка. – Казань: Издательство Казанского университета, 1985. – 318

# ЯСАЛМА СҮЗЛӘР СИСТЕМАСЫНДА СИНОНИМ, АНТОНИМ, ОМОНИМНАР

Саматова М.А.
Бурнашевская средняя общеобразовательная школа
Апастовского МР РТ
Samatova-m@mail.ru

**Аннотация.** К лексическим средствам выразительности речи относят такие слова, как синонимы, антонимы, омонимы. Каждый из видов этих лексических средств несет в себе настоящие драгоценные камни, которыми украшается родная речь. Если же отказаться от их использования в языке, то речь будет скудной, бедной и абсолютно без эмоциональной, а люди, которые будут разговаривать в подобном ключе, больше будут напоминать роботов, выполняющих односложные команды. В этой статье мы рассмотрим следующие определения: антонимы, синонимы, омонимы. Что они обозначают и для чего используются в речи?

**Ключевые слова:** синоним, антоним, омоним, кушымчалау ысулы, сүзләр кушылу, конверсия

Татар телендә сүз ясалыш системасының гаятъ катлаулы һәм бай булуы күренә. Бер яктан караганда, сүз ясалышы телдә яңа синонимик мәгънәләр тууга җирлек булып тора. Кушымчалау ысулы ярдәмендә яңа синонимик мәгънәләр барлыкка килә: (*акыл - акыллы, бел – белем – белемле, зиһен – зиһенле, укы - укымышлы* һ.б. Синонимик мөнәсәбәткә төзелешләре ягыннан аерылып тора торган сүзләр дә керә; сүзнең кыскартылган формасы аның тулы формасына абсолют синоним була: ТИҮ – татар иҗтимагый үзәге, БМО- Берләшкән милләтләр оешмасы, БТК – Бөтендөнья татар корылтае, БДБ – Бәйсез дәүләтләр берлеге[Сафиуллина, 1999, 43].

Икенче яктан караганда, үзара синоним булган сүз ясагыч чаралар(сүз ясагыч кушымчалар, аерым сүзләр) сүз ясалу процессында шактый зур роль уйный, ягъни синонимлык мөнәсәбәте телдә яңа сүзләр ясау өчен шартлар тудыра. Мәсәлән, *Прилавка янына килеп җиткән ана* ***йолкынды-бәргәләнде****, ә халык аны һаман кысты* җөмләсендә парлы фигыльләр кулланмыйча, *Прилавка янына килеп җиткән ана* ***бәргәләнде****, ә халык аны һаман кысты* дип тә бирергә була, ләкин беренче җөмләдәге үзара синонимик мөнәсәбәттә торган парлы фигыль ярдәмендә ананың эчке халәте тулырак гәүдәләндерелә, анда экспрессивлык-эмоциональлек тагын да көчәйтелә. Шулай итеп, үзара мәгънәдәш булган ике сүз тезүле бәйләнеш нигезендә бер-берсенә кушыла һәм яңа лексик мәгънәгә ия булган берәмлек ясый.

Гомумән алганда, сүз ясалыш системасында синонимлык күренеше зур урын алып тора. Синонимияне төрле ысуллар белән ясалган ясалма сүзләр арасында да күрергә мөмкин. Мәсәлән, татар телендә фигыль ясагыч ***–лат/-ләт*** кушымчасы сыйфатларга яки саннарга ялганып, ясаучы нигез белдергән

билгене яки ясаучы нигез кадәр берәр нәрсә ясауны аңлата: *турылат, матурлат, күркәмләт, икеләт, унлат* һ.б. Шушы ук мәгънәгә ия булган сүзләрне нигезләр кушылу ысулы белән ясалган тезмә фигыльләр арасыннан да табарга була: *туры ит, матур ит, күркәм ит, ике ит, ун ит.* Шундый ук хәл рәвешләр ясалышы системасында да очрый. *Иртән – иртә белән, көзен – көз көне, тереләй – тере килеш, бушлай – буш килеш* һ.б. Конверсия ысулы белән саннан билгесезлек алмашлыгы булып күчкән *бер, берәү* сүзләре һәм сүзләр кушылу ысулы белән ясалган *әллә кем, кемдер* кебек алмашлыклар. Шулай итеп, ясалма мәгънәдәш сүзләр төрле ысуллар белән дә ясала алалар икән.

Телдә төрле сүз ясалыш ысуллары ярдәмендә ясалган ясалма антонимнар байтак.

Сүзьясалыш ысулы - нинди дә булса телнең материаль берәмлекләреннән, алар арасында сүз ясалыш мөнәсәбәтләре хасыйл итеп, яңа сүзләр ясау алымы, методы.

Сүз ясалышы ярдәмендә күп кенә тамыр сүзләрнең антонимик парлары ясала дидек, моңа мисал итеп түбәндәгеләрне китерергә мөмкин: *матур – ямь+-**сез**, озын – кыс+-**ка**, ким – арт+-**ык**, макта – хур +-**ла**, кайгы – шат+-**лык**, үл – яш(ь)+-**ә**, аяз - болыт+-**лы**.*

***Озын** янында **кыска** беленер (мәкаль).*

***Аяз** булса – суытыр, **болытлы** булса – җылытыр(мәкаль).*

Телдә ике пары да ясалма сүзләрдән торган антонимнарның саны бихисап. Әлеге факт нигезендә, галимнәр антонимнарның ясалышлары ягыннан ике зур төркемгә бүлеп өйрәнәләр: төп антонимнар һәм ясалма антонимнар. Икенче төрләре ниндидер ясагыч чара нигезендә барлыкка килә, гадәттә, мондый төр антонимнар сүз ясагыч кушымчалар ярдәмендә ясалалар. Мәсәлән: *күп+-**челек**-аз+-**чылык**, караңгы+-**лык** – якты+-**лык**, кат+-**ы** –йомша+-**к**, кыс+-**ка**+-**р** – озын +-**ай**, тәм+-**ле** – тәм+-**сез**, бай+-**лык** – ярлы+-**лык**.*

***Эшлегә** сәгать җитми, **эшсезгә** сәгать үтми(Әйтем).*

***Һөнәрсез** сау кешедән **һөнәрле** гарип артык(Әйтем).*

Югарыда китерелгән мисалларда, ясалма антонимнар кушымчалау ысулы ярдәмендә ясалганнар, әмма телдә башка ысуллар, мәсәлән, конверсия, фонетик ысул, сүзләр кушылу ысуллары ярдәмендә барлыкка килгән антонимнаны да бик еш очратырга мөмкин. Мәсәлән, сүзләр кушылу һәм сүзтезмәнең кушма сүзгә күчү ысулы белән түбәндәге ясалма антонимнар барлыкка килгән: *быел – (бу + ел) – киләсе ел, көньяк – көн+як – төньяк - төн+як, кайтып килү – китеп бару, эри башлау – эреп бетү* һ.б. Шундый ясалма антонимнарны контекстта карап китик:

*Кич кояш иңгән вакытларда **көньяктан** сыекча болытлар күтәрелеп бераз яңгыр да сибәләп алды (Ш.Камал). **Төньяктан** акрын, ләкин бик тирән гөрләү белән күк күкрәгән тавыш ишетелә(Ш.Камал).*

Конверсия ысулы ярдәмендә ясалган антонимнарга түбәндәге мисалларны китерергә була:

***Ялкау – уңган, ялкау – тырыш. Ялкау*** – сыйфаттан исемгә конверсияләнгән, ***уңган*** – сыйфат фигыльдән исемгә күчкән:

***Ялкау*** *ялга туймас,*

***Уңган*** *эштән туймас(Мәкаль).*

Югарыда күрсәтелгән мисалларда антонимның ике пары да бер үк ысул(кушымчалау, сүзләр кушылу, конверсия) ярдәмендә ясалганнар. Телдә ясалма антонимнарның бер компоненты бер төрле ысул белән барлыкка килеп, икенче компоненты икенче төрле ысул белән ясалырга да мөмкин. Күзәтүләргә караганда, мондыйлары телдә күбрәк кулланыла. Мәсәлән, ***ялкау*** (конверсия ысулы белән ясалган) – ***эш+-чән*** (кушымчалау ысулы белән ясалган) б***ай*** *(*конверсияләнгән сүз *–* ***хәер+-че*** *(*кушымчалау ярдәмендә барлыкка килгән*).*

***Хәерчегә*** *ачык йөз күрсәтсәң, ямаулык сорый*

*Ямаулык бирсәң, тун сорый*(Әйтем).

*Йомры тояк тайларда,*

*Алтын-көмеш* ***байларда****(Җыр).*

Конверсия һәм кушымчалау ысулы ярдәмендә барлыкка килгән антонимнар: ***бүген*** (сүзләр кушылу – бу+көн) – ***иртә +-гә*** (кушымчалау).

***Бүген****ге эшне* ***иртәгә*** *калдырма* (Мәкаль).

Антоним парларның үз синонимик рәте булырга мөмкин, мәсәлән, *дәү – олы, олуг, зур; бәләкәй – кечкенә, нәни, вак.* Мондый синонимик рәтләр ясалма сүзләр ярдәмендә дә байый бара. Мәсәлән: *киму – азаю, әзәю; арту – киңәю, ишәю, күбәю.*

Омонимнар – (грек. homos – бертөрле, onyma – исем) бертөрле аваз составына ия булган төрле сүзләр. Мәсәлән: *сыр* (ашамлык) – *сыр*(сызык), *ай* (утыз көн) – *ай* (күк җисеме), *кала* (фигыль) – *кала* (шәһәр) һ.б. Соңгы елларда “омонимлык” термины үзенең барлык формаларында да туры килүче төрле сүзләргә, төрле лексик берәмлекләргә генә түгел, бертөрле яңгыраучы морфемаларга, сүз тезмәләренә һәм җөмләләргә карата да кулланыла башлады. Гомуми тел белемендә омонимлык мәсьәләсе шундый киң планда өйрәнелсә дә, аны ахыргача тикшерелеп беткән дип әйтә алмыйбыз.

Ф.С.Сафиуллина, омонимнар турында сөйләгәндә, төрле сүзләрнең аваз составлары бердәй булуына игътибар итә һәм болай дип белдерә: “Омонимнар – бертөрле аваз составына ия булган сүзләр, икенче төрле әйткәндә- аваздаш сүзләр”[Сафиуллина, 1999, 27].

Сүз ясалыш оясын билгеләгәндә, бер тамырдан чыккан сүзләр белән аваз төзелешләре очраклы рәвештә тәңгәл килгән омонимнарны бутарга ярамый. Хәзер хезмәтебездә сүз ясалыш оясындагы төп сүзнең омоним булу очрагын һәм аннан ясалган сүзләр белән танышып, мөмкин булганча, аларны аеру критерийләрен билгеләп карыйк. Мисал өчен ***кара*** фигыленең һәм *кара* сыйфатының сүз ясалыш оялары:

**Кара**(фигыль) – ***карар, кара****рсыз,* ***кара****рсызлык,* ***кара****та,* ***кара****улы,* ***кара****чкы,* ***караш, кара****-каршы.*

*-Аска карама син, алга таба* ***<u>кара</u>****, йөз чакрымдагы авыллар күренә торгандыр моннан(И.Гази). Газинурның* ***<u>карар</u>ы*** *нык: Аның күңелендә курку да, тетрәү дә, икеләнү дә юк(Г.Әпсәләмов). Мавия әллә нинди* ***<u>карар</u>сыз*** *бер*

*кыяфәттә күренә(М.Фәйзи). Капитан Газинурга **карата** артык каты кылана иде(Г.Әпсәләмов). –Өйләнәм дисәң, беткәндер сиңа бирәр тол хатын. Тамагың тәрбияле, өстең-башың **караулы** булыр иде ичмасам(Р.Төхфәтуллин).*

*Кайвакытта кара күзле, кара кашлы*

*Матур белән утырамын **кара-каршы**(Г.Тукай).*

**Кара**(сыйфат) - ***кара**лу, **кара**лату, **кара**-кучкыл, **кара**бодай, **кара**күл, **кара**кош, **кара**лау, **кара**лы, **кара**күз.*

***Кара** урманга кергәч чакта,*

*Кисеп алдым ак каен(җыр).*

*Көлдә пешкән бәрәңгене әрчегәндә **карала** кул (Р.Фәйзуллин).*

*Ай урагы кебек кашларыңны*

*Кем бәхтенә шулай **каралттың** ? (җыр).*

***Каракошның** оясы коры булмас(мәкаль).*

Татар теле агглютинатив характердагы тел. Биредә сүзнең лексик яки грамматик мәгънәсе тамырга яңа кушымчалар ялгану нәтиҗәсендә үзгәрә бара. Кушымчалар, ягъни суффикслар күптөрле, алар бер-берсенә ялганып сүз ясалыш чылбырын хасыйл итәләр. Белгәнебезчә, татар телендә кушымчаларның мөмкинлеге бик зур, биредә бер үк тамырга төрле кушымчалар ялганып дистәләгән яңа сүзләр ясала ала. Һәм алар, кагыйдә буларак, бер сүз ясалыш оясына кайтып калырга тиеш. Ясалма сүзнең мәгънәсен билгеләүдә дә сүз ясалыш оясын белү ярдәм итә ала.

Мисаллардан күренгәнчә, омонимлык күренеше сүз ясалышының төрле өлкәләрендә күзәтелә торган күренеш. Аеруча лексик мәгънәгә ия булган ясагыч кушымчалар арасында омонимлык күренеше киң колач алган.

Омонимия мәгънә белән бәйле булган лингвистик күренеш булганлыктан, аның бары тик лексикада гына күзәтелгәнлеге һәркемгә мәгълүм. Әмма безнең тикшеренүләребез омонимлыкны телнең лексикасында гына түгел, аның гаять тә катлаулы булган грамматикасы, аерым алганда, сүз ясалышында да төп урыннарның берсен алырга хаклы булганлыгын күрсәтте.

**Әдәбият**

1. Бала бишеге – гомер ишеге. Башлангыч сыйныф укытучылары, балалар бакчаларында, милли төркемнәрдә тәрбиячеләр, ата-аналар өчен халык авыз иҗаты әсәрләре җыентыгы. 3 нче басма: Яр Чаллы, “Идел-йорт” нәшрияты, 2002. – 96 б.
2. Ганиев Ф.Ә. Хәзерге татар әдәби теле: Сүзъясалышы. – Казан: Мәгариф, 2000. – 271 б.
3. Закирова Р.М. Антонимы в татарском языке // Проблемы лексикологии и лексикографии татарского языка. - Вып. 4. - Казань: Фикер, 1999. – Б. 63-69.
4. Мөхәммәдиев М. Шәриф Камал әсәрләрендә фразеологик синонимнар һәм антонимнар // Татар теле һәм әдәбияты. – Казан: Татар кит. нәшр., 1959. – Б. 178-185.

5. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология / Ф.С.Сафиуллина. – Казан: Хәтер, 1999. – 288 б.
6. Сафиуллина Ф.С. Татар телендә парлы сүзләр һәм синтаксик мөнәсәбәтләр // Фәнни язмалар. – 2003. – Казань: РИЦ “Школа”, 2004. – Б. 201-207
7. Сафиуллина Ф.С. Парлы сүзләрнең яңа төрләре // Мәгариф. – 2006. - № 7. – Б. 6-7.
8. Татар халык мәкальләре. I том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959.
9. Татар шигърияте: 1980-2000 еллар. – Казан: Мәгариф, 2003. – 352 б.

# NON-TERMINOLOGICAL WORDS IN THE NORTHERN DIALECTS OF THE AZERBAIJANI LANGUAGE

Samedova Konul Ibrahim
Azerbaijan State Pedagogical University
samedovakonul74.@ mail.ru

*Работа выполнена при финансовой поддержке Фонда развития науки при Президенте Азербайджанской Республики - Грант № EIF / MQM / Наука и образование-1-2016-1 (26) -71 / 07/5-M-23.*

**Rezume.** Words in the Northern dialects of the Azerbaijani language are non-terminological. In the Northern dialects of the Azerbaijani language, terms are derived from nouns, generation names, disease, agricultural instrument names, size and weight names, numerical words, day and month names, tax-related words, children's play names, and so on. Each of the words used here has its own history.

Names of Tribes and Generations: Uruğ. This word is found in the dialects of groups of shamakhs, Derbents and Mugan in the sense of family, tribe, community, tribe. In Derbent dialect, this word is used in terms such as uruğ-turuğ // uruğ-tırığ // uruğlu-tırığlı // urruğ-turığ. In Zagatala, Balakan, Gakh, Oguz and Gabala regions, options such as urvatdı are used. In the Baku dialect, it is used in the form of ülğaç-culğa. In the Mugan scriptures, the word uruğ can also be found in the word muruğ (muğ - leader + ruğ - community, tayfa - leader of the tribe). Currently, the word ruğ // uruğ is found in many Turkic languages. The word is used in the Turkmen language as uruq [13,s.290], in the Uzbek language in the form uruğ [12,s.744], in the Bashkir ırıu [11.536] and in the Kyrgyz language in the form uruu [9,s.583].

The same word is used in the language of the legends of "Kitabi Dede Korgud" (Aslan uruğu, sultan qızı), as well as in the Kashghari, Ibn-Muhanna, and XII-XIII centuries Central Asian commentaries. H. Zarinzade writes about it: “Uruq-hər bir şeyin toxumu.Uruğ əkdi. Qohumlar da buna oxşadılaraq onlara uruğ-turığ deyilir ”[7, p.127]. This word is used in the Zakatala-Gakh dialects in the same meaning as the word urdu. Apparently this word is of the same root with the word *uruğ*. In our language we use phrases such as *aruğ-urug//arıx-tırıx*, which mean completely different meaning than *arıq.*

Com. In the Mugan dialects it is used in the sense of tribes and relations. For example, the coms in Mursalli village are: 1) Mürsəlli comi; 2)Xələfli comi; 3) Abduhüserıni comi; 4) Cavaddı' comi; 5) Aqaşdı comi; 6) Zeynallı' comi and others. In addition, in these dialects, the word *com-com* is repeated, and it is used in the sense of tribes and relations. The etymology of this word can be found when researching other Turkic languages is involved. This word is çon in Tuva and Khakas literary languages, and in the Kachin dialect of the Khakas language, it means *xalq, ulus.*

As a result of passing c> k, the word coma may also be here. [8, p.333]

Tabun. This word is used in Zagatala-Gakh in the sense of tribes and relations. For example, the tabuns in Ilisu: *baş tabun, begin tabun, sarılar tabun, qala tabun, dabiğ tabun, bucağ tabun, səngar tabun, taula tabun.*

The tabuns in the Gimir village of Zagatala: Hacolar, Dellehlər, Səmədlər, Hapıslar, Mazanlar, Mürsəllər, Baharçılar, Xəmətdər, Karsılar, Xaşıllar, Dişovlar, Həsənkoxalar, Sofular, yuxarə tabın, aşağı tabun, çaylax tabın and so on. In Kazakh language the word *tabun* is used in the meaning of *flock*: *kolxoz tabındarı, bir tabın k,az*[10,s.782].

The word is translated from Turkish to Russian and is used as a horse herd. In Bashkir language the word tabun was formed as the word tribe // uysun [5, p.141]. In the village of Qirmir of Zagatala, there are people whose names and homes are still preserved as pilgrims. An example is:

1. Hacı Mikayıl Əfəndi baba - was a saint who lived at the end of the eighteenth century, in the middle of the 20th century. There is a shrine in the village named after him.

2. Hacı Murad Əfəndi baba - It was a child who lived in the eighteenth century. There is a shrine named after him.

3. Sarıpir baba –was a saint, there is a huge shrine in his village named after him.

4. Hacı Yəhya Əfəndi baba – He was one of the saints of the 20th century. There is a shrine named after him.

There are also many people in Shaki who have earned the people's trust with their miracles: Veyis Baba, Pir Baba, Sheikh Baba, Majid Baba, Sadaddin Baba, Mutubillah Baba, Yunis Amre, Haji Salah Baba, Shaplan Baba, Qafur Baba, Mahmud Akhund Baba and others. Shaki is also the name of the mage. The name of the village. The name of the village. *Şəki də məhlə adı -dodu . Qışdax-Şəki də məhlə adı.Aldılar nəsil adı.Malax-Qax rayonunda kənd adı.*

*-Haralısan?*
*-Malaxlı.*
*-Aşi bişir qavaxlı.*
*Yiyax dadlı-damaxlı.*
*Yatax dallı –qavaxlı.*

*-Haralisən?*
*-Dəhnəli.*
*-Hardansan?*
*-Qıçdaxdan.....Burada Malaxlı,Dəhnəli,oba və kənd adlarıdır*[6,s.349-50].

The word *tabun* is used in the meaning of *herd* in Kazakh language.

The word is translated from Turkish into Russian and is used in the sense of horseherd. Shagga-is used in the meaning of as tribes orgenerations in Zagatala dialects. In literary language, in some dialects and syllables it is used as a part of a beast cut into pieces. Zagatalan's Gimir village is sometimes used with a slight word: It should be noted that in some villages of the district, the word for puzzles is used in a strong sense. In literary language, in some of the dialects it is used as a cut part of animal.

In the Gimir village dialect of Zagatala it is sometimes used in the meaning of *az-az*. It should be noted that in some villages of the district, the word *şaqqama* is used in the meaning of *güclü*.

**The names of the disease.** The accents of the northern dialect also contain interesting names. The most commonly used are: Innaf / innax (used when you catch cold), sitəlcəm, uzun azar//sil azarı, qızılçıx, çiçəx, maşara// qızıl yel, pis azar-vərəm, vurğun- severe acute illness (Shaki), sudden death of young person is called *vurgun vuruv* (Zagatala, Qax), tutma- ürək getmə, isal, qotur, sarı yara, çovan, kor çovan, sarılıx, ürək göveyin düşməsi and so on.

**Old tools used in agriculture.**

Names of vehicles and their parts: xış, şana, vel//vəl, kürex[1]kürəx[1], bel, qalax (belin ağac hissəsi), ağaş mala, demir//dəmir mala, urax//orax, yava, arava, daşqa, fırğın//furqun and so on.

Car parts: kötixı//kötxı, qol, ulama, gəvəhin, çəmbərə, dəsdə//dəsdeh, kōğa, boyunturux, samı//səmi, sambağı, tiyə and so on.

Instrument Names: Dərgaz, xış, cüt, ulama, cəhrə, kirkirə, kərki, dərzi, çin, şalqı, yeyə, çapacax və s. mərdanə//duax//dördayaq - "rolling-pin", salabey -"baton", arkən -"type of tree", çəpiηda -"sparrow", aveem - "feed grinding mill", sacayaq –a tool used to put the pot on the hearth-"the entrance of the door",agıl- " a place where animals are kept", çalğı -" tool for mowing grass", çətmə -"trap", "fırıx"- a long rod made of a branch of a tree", kərki// -hoe -"kəfkir", ləngəri "ləyən, tas", mağara -"sap", məzər-"önlük", çeşqi-" small pot with medium depth", süzgəc- "colander", neiveçi-"nəlbəki", çökür-" large, wooden boiler with holes in the back", kərsən-" wooden dishes", dünc-" sticks used to beat meat" and so on.

*–O vaxtı hindiki kimi döyüldü ki,ağacdan tehnəmiz varıydi, ağacdan çökür qayrılardı, çömçə qayrılardı, ağacdan kərsən qayrılardı* [6,s.275] .

Şana-fork, yava-grass cutting tool, duzun dakkası-wooden salt pan.çöçə -copper pot // (çöçə Sweets in Nakhchivan) , dakqa-An iron pot weighing approximately 8 kg., Formerly used as a unit of measurement, deyə-koma, dünc-kötük (In the past, when meat machine was not available, they beat the meat on the bush.) guyüm- sparrow.

Tenbur // danbur string instrument name., Hayla is the name of the music. Researcher Z. Mansimova notes that songs in the ashug environment of Zagatala are called "hayla". The word of hayla means to move and to speak. In khakas, altai, shore, canvas, baskets, saga is said to be a "kayak" or "Kayla", the person who retells saga is called "kayçı", "hayçı".

Danburun simi nazih,
Qolumda var bilerzih.
Elə bir yar sevmişəm,
Barmaxdan beli nazih. [4,s.27]

**Size and weight names, numerical words.**

From the accents of the northern dialect, a number of words in the Sheki dialect mention the names of the oldest weights and units. These words can be found in the speech of older people. Məs.: tağar (twenty poods), daqqa (one thirds of pood), basdı (A.Göy., B.G.öy) //başlı (Or,Zəy.) – bir daqqa, canax; ara çanağı (Or..Zəy.)//qayız (Or.)

–two poods, girvəngə (400 q.), çetver (100 q.), misqal ərşin (Aş.Göy., B. Göy, BİI.), səcin (B.Göy.), qulac, çərəx’, uruf (Qşl., B.Göy., A.Göy.) – about one-quarter of an hour, 15 minutes. In general, the following weight names are found in the accents of the Northern dialect.

Batman – weighing 8kq, girvənkə – weighing 400 gr, taqqa – wooden crate basket. In Sheki dialect it is daqqa Eight kilogram weighing plates (*– Hər dakqiyə bi dənə çöçə düşür*), *saqam* (Zaq.) //*saqat//təhnə* – container for bread as well as for grain. *Qapan* – 60 kq -lıq ölçü vahidi. *Qulac* – 1,5- 2 m., *tağar, verst, çərəx, qulac, səkləm, cuval, çanax* and other words that are used as units of measure.

*Şahad* “grain given to the miller as wage”: *– Qoy, çatım, üyüdüm,verim. Allah rəhmət eləsin atana,atan heç olmasa üyüdüf alıydi* ***şahadı,****sən çatincə alısan* [ 6,s.210].

*Metro* “metr”: *– Məhlədə bi iyirmi-otuz* ***metro*** *odun olufdu,****Unuqayə*** (hal adam )*bunu yığdıriy, malın peynin tullatdıriy* [2,s.31].

*Saqat*-This lexical unit is used as saqam in Zagatala dialect –1)wooden dish with barley and wheat; 2) in the form of containers in which bread is placed [1,s.244].

**Day and Month Names:** Before the Soviet rule was established in Azerbaijan, literary language and dialects and accents used the names of the months associated with Islam. Example: chaban, Ramadan, mahram etc. Some of the day names are Persian words. For example: *seşənbə, yekşənbə, düşənbə, pəncşənbə* və s.

However, before Islam, many months and days names associated with the farm were used in our language, after which some of these words came out of our language under the influence of Islam. Nevertheless, some of these words are still used in the vocabulary of our dialects and accentss. Such words as chill (big, small), crunchy, dark, tail-bearing (B., Mug.) // tailed duck (Snow), autumn // gazelle next month (2nd fall), vegetable month (3rd fall) (Mug.), cherry month (cherry ripening month), torrential month (spring), months of incarnation, lunar month (March), crescent months (fall), named // adna, market, single words may be included.

The names associated with past migrant life are: salt day (day of salt) and milk day (day of milk).

In the accents of the northern dialect, "erkən" is used early in the morning, and “*ilkindi*" in the evening. " *Xas günü* " Tuesday, " *şəmmi*" refers to Saturday. (Zaq Baz, Qax . Qul.)

Different forms are also found in the dialects of the northern dialect of the Shaki district; bȫx’ çillə (the first 40 days of winter), kiçix’ çillə// bala çillə (the last 20 days of the second month of winter), çi̱llə veçə (last month of the winter), keçiqıran (March), qarıborcu, qora bişirən ay (August), quyrux doğan ay (second half of August), noruz (early spring), qara yaz (early spring); şəmmə, bazar, bazaretəsi, xas (Tuesday), çərçəmmə, adına (Thursday), cuma // cumay (in most villages).

In the passive vocabulary of our dialects and syllables, we also find traces of words that indicate the relationship of feudalism and capitalism. This type of phrase includes a number of words that indicate tax, rank, position, layers, and trade.

M. Kashghari's dictionary contains Persian names. He mentions this name as one of the twelve years of the Turks and explains his history. The Turks took twelve names of animals and named twelve years. They calculate the age of the children, the

dates of the war and other things as the years go by. This is the history of it. One of the Turkish kagan wanted to learn about a war that had taken place before him, and he made a mistake in the date of the war. In this case, hagan has convened a council for this task, saying that those who come after us will be mistaken as we have been in this history. So let us name the every year for twelve bourgeois and twelve months, and let us know our account over the years. It will be a memorable memory for us." The nation also accepted this offer. M. Kashghari shows that hagan ordered to chase animals with the dog to Ilisu. Only twelve animals cross the river. These animals are named after them. Mouse was the first that crossed the river. Therefore, the first of the years is called a mouse. Then they are named in successive animals.

*Ud yılı*-cattle year, cow year, Pars yılı –tiger year, Tavışğan yılı- rabbit year, Nək yılı- crocodile year, Yund yılı- horse year, Koy yılı - sheep year, Biçin yılı-monkey year, Takağu yılı-hen year, İt yılı-dog year, Tonquz yılı-pig year.

The Turks, considering that there is wisdom in each of these years, have looked at them with their fortresses and have shown the characteristic features of these years as follows:

In the year of the cattle, the number of wars increases, and if in the hen year there is plenty of food, the confusion between the people increases. Because the feed of a hen is grain, and in order to find its food it mixes crap, crumbs of derbies. In the crocodile year there is much rain and abundance, and in the year of Pig, much snow and cold, and confusion. The Turks have no names for seven days of the week, as the concept of the week emerged after Islam.

As for the names of the months, M. Kashghari notes: "Immigrants and non-Muslim Turks divide the year into four chapters. Every three months there is a name, and the year is known by this. After Novruz, the spring is called the "Capricorn" month, and then the "ulug oğlaq." Because in this the second time part the Capricorn is growing. Then comes uluğ month, because it is the middle of summer. Blessings abound on the earth, animals grow, milk is abundant. M. Kashghari does not name the following chapters because numerous of them are noot üorked on[3, Vol., Pp. 354-556].

The word "Turk" is also used in the meaning of time in the dictionary. The middle of the time when all fruits are ripe. " Türk üzüm ödi - it's time to grape".

"türk kuyaş ödi –noon, "türk yiğit – a young man in the middle of his youth . The word is used in the middle term, or in the middle of the sun, and even in the zenith, which is indirectly used in the afternoon meaning "boy of the sun" [3, I, p. 359].

**Tax related words:**

*bidəx'* (Ağ.), *dinməver* (Bal.), *vaxmı* (land tax), *çöpbaşı* (property tax), *mənzil* (no pledge) (Ord.), *saldat puli//əsgər puli, biyar, su vergisi, tüstü vergisi, torpağbasdı, qəllə* (Bakı.), (beşdə bir), *töyçü//təvci, bəhrə, canpulu // başpulu, yerpulu, desetin pulu, otbaşı* (pasture tax), *mesref* (tax collected for the village itself), *zəyin* ( free service to the landowner) (Qaz.), *istac*"the fare".

In Sheki dialects töycü (in all villages), müx’ tax (B.Gün), soldier money (B.Kün)//sallat pulu (K., Or.), medicine tax, tüsdü pulu (Bil., İnc.)//dəstəndaz (Baq.Zəy.), forester money (Bid.), qol pudu ( Şə.İ.), miraf tax(B.Kəl.).biyar-// biqar.work done for a bay for free charge .ərəntə-leased land.

**Names of children's (teenage) games:** mofqalax, qalaqurma, dürədöymə, calğa-calğa, həyrənbaba, çiligağac, aşıx-aşıx, keseyen-bişix[1], yeşinbaac// yeşinbaba// yeşinbabaş (gizlənpaç), eşşex[1]beli, bənō̄vşə-bənō̄vşə, iynə-iynə, üzüy-üzüx[1], molla-molla, dennəmədaş//beşdaş, təkəyax//birinci, qolçax-qolçax//gəlin-gəlin, top-top, cüt-cüt, pır-pır, moraxa, keçisoyma, tullanbac, gözbağlıcı.

## References


1. Derbend dialect of the Azerbaijani language. Baku, Science, 2009, 448 p.
2. Hajiyeva G.A The language is a memory of our history. Baku, Araz, 2008, 199 p.
3. Kashghari M. Divani Dictionary - it is Turkish. Published by B. Atalay, Ankara, 1939, 511 p.
4. Masimova Z. Zagatala ashug environment. Institute of Folklore, Baku, Science and Education, 2014, 216 p.
5. Orucova Sh. Kipchak group ethnonims in Turkic languages. Kipchak group lexicon of Turkic languages. Baku, Volume III, ANAS, 2012. 468 p.
6. The paper L. Sheki folklore samples. Book II. Baku, Science and Education, 2014, 408 p.
7. Zarinzadeh H. Words of Azerbaijan in Persian: The Safavid Period, Baku, Az.SSR.EA, 1962, 436 p.
8. Baskakov N.A., Inkizhekova A.N. Phonetic features of the Khakass language, Proceedings of the Institute of Linguistics, Volume IV, Moscow, 1954.
9. Kyrgyz-Russian Dictionary, Moscow, 1965.209
10. Malov S.E. Monuments of ancient Turkic writing, Moscow-Leningrad, publishing house, Acad. Science of the USSR, 1951, 451 [1] p.
11.Russian-Bashkir dictionary. Moscow, 1948.958 c.
12. Russian-Uzbek dictionary. Tashkent, publishing house, Acad. Science of the USSR. 1950, T 1, A-F, 520 s; 1953 T 2, ZL, 480 s. ; 1953, T3, M-O, 582 p .; 1954, T 4, P-R, 720 p .; 1955, T5, S-Z, 735 s.
13. Baylıyev X., Karrıyev K., Türkmence-rusca sözlük. Aşxabad, 1940.

# ТАТАР ҺӘМ РУС ТЕЛЛӘРЕН ЧАГЫШТЫРМА ӨЙРӘНҮ: АКТИВ ҺӘМ ПАССИВ ТӨЗЕЛМӘЛӘР КУЛЛАНЫЛЫШЫ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Саттарова М.Р.
Казан федераль университеты,
m-sattarova@mail.ru

**Аннотация**. Статья посвящается сопоставительному анализу особенностей употребления активных и пассивных конструкций на материале татарского и русского языков. Активные и пассивные конструкции, будучи функциональным видом синтаксических синонимов, обогащают язык, совершенствуют стилистические особенности и являются одним из особенных явлений сопоставляемых языков.
**Ключевые слова**: сопоставительное языкознание, активная конструкция, пассивная конструкция, татарский язык, русский язык.

Әлеге мәкаләдә телне баету, сөйләм матурлыгын арттыру һәм стильне камилләштерү өчен кулланыла торган синтаксик синонимнарның бер функциональ төре – актив һәм пассив төзелмәләрнең татар һәм рус телләрендә кулланылыш үзенчәлекләре карала.

Тел гыйлемендә әлеге күренешләрне өйрәнүнең үз тарихы бар. Мәсәлән, В.П.Сухотин, М.Ф.Палевская, Ш.Ханбикова, Л.Максимов һ.б. хезмәтләрендә бу мәсьәлә өйрәнелгән. Татар теле материалында синтаксик синонимнарның барлык төрләрен дә өйрәнгән телче галим булурарак С.Ибраһимовны әйтергә кирәк.

Чагыштырыла торган телләрдә актив һәм пассив төзелмәләрнең асылын ачыклаганда аларның, беренчедән, чынбарлыктагы күренешләрнең бердәй бәйләнешен һәм мөнәсәбәтен чагылдырып, төзелешләре белән аерыла торган конструкция; икенчедән, бер төзелмәне икенчесе белән алмаштыру мөмкинлеген; өченчедән, синтаксик мәгънәләре туры килеп, бары бәйләүче чаралар белән генә аерылуын истә тотарга кирәк. Бу берәмлекләрне тел белемендә синтаксик синонимнар дип атау да шуның белән бәйле [2, 26].

Бу конструкцияләрнең синтаксис белән бәйлелеге җөмләдәге ия, хәбәр, тәмамлыкның субъект, предикат һәм объект буларак кулланылышында. Ике телдә дә җөмләдә ия – башкаручы, хәбәр – эшне һәм төшем килешендәге туры тәмамлык объектны белдерсә, актив конструкция була. Мәсәлән, *Балалар китап укый – Дети читают книгу*. Пассив конструкциядә ия объектны, кыек тәмамлык эш башкаручы затны белдерә. Мәсәлән, *Китап балалар тарафыннан укыла – Книга читается детьми*, ягъни әлеге фигыльләр мәгънә эчтәлеге белән субъектның пассивлыгына ишарәли.

Актив һәм пассив төзелмәләр морфология өлкәсе белән дә бәйле, чөнки пассив төзелмә юнәлеш категориясеннән башка була алмый. Юнәлеш категориясе – татар һәм рус фигыльләрен чагыштырма аспектта өйрәнгәндә аерым игътибар сорый торган күренешләрнең берсе. Татар телендә биш

юнәлеш булса, рус телендә төп ‘действительный’, төшем ‘страдательный’ юнәлешләре карала. Болардан тыш рус телендәге күпмәгънәле *-ся* постфиксы да юнәлеш мәгънәсен бирә. Әлеге берәмлекнең этимологиясе ‘себя’ алмашлыгының винительный падеж формасына барып тоташа. Бу берәмлек күчемле фигыльгә форма ясагыч буларак ялганып, төшем юнәлеше мәгънәсенә ия булган кайтымлы фигыль формасын барлыкка китерә. Ә фигыльгә сүз ясагыч *-ся* постфиксы ялганганда, яңа мәгънәле кайтымлы фигыль ясала. Мәсәлән, *‘бриться’* (брить), *‘обниматься’* (обнимать), *‘веселиться’* (веселить), *‘запасаться’* (запасать), *‘бодаться’* (бодать) һ.б. Юнәлеш мәгънәсенә ия дип караган фигыль белән ясагыч нигез арасында һәрвакытта да лексик мәгънә берлеге сакланмый, шул сәбәпле, бу күренеш өлешчә сүз ясалышы белән бәйле һәм грамматик категория буларак каралмый.

Төшем юнәлеше, ике телдә дә күчемле фигыльләрдән ясалган формаларда гына күзәтелә. Күчемле фигыльләргә төзелә, ясала, барлыкка китерелә, үзгәртелә, юк ителә, сизелә, тоела торган предметларга юнәлдерелгән эш-хәрәкәтләрне белдерәләр [7, 236; 4, 242]. Татар телендә төшем юнәлешен *-л, -ыл, -ел* кушымчалары белдерә, нигез *-л, -ла-/-лә*-гә тәмамланганда – *-у/-ү* ялгана һәм *-н-* кушымчасы ярдәмендә белдерелә: *ал-у – алыну, саклау – саклану, алдау – алдану, уку – укылу, бөгү – бөгелү* һ.б. Рус телендә исә несовершенный видтагы төшем юнәлеше гадәттә кайтымлы форма, совершенный видтагылары – төшем юнәлешендәге хәл фигыль белән белдерелә: *Рабочие строят дом – Дом строится рабочими. Рабочие построили дом – Дом построен рабочими.* Алда әйтеп үтелгән *-ся* формалы вариантлар белән чагыштырганда, хәл фигыль формасы белән белдерелә торган төшем юнәлеше һәрвакытта да ачык, өстәмә мәгънә белдерми. Гомумән, рус телендә фигыль юнәлеше татар телендәге кебек кушымчаларга карап кына билгеләнә алмаска мөмкин. Мәсәлән, *Андрей уже много лет строится.* Биредә мәгънәгә игътибар итү мөһим, Андрей – эш башкаручы субъект булып тора.

Төшем юнәлешенең шактый өйрәнелгән булуы аның үзенчәлекле грамматик табигате, катлаулылыгы белән аңлатылса кирәк. К.Зиннатуллина күп кенә телләрдә фигыльнең актив һәм пассив формаларының каршы куелуын юнәлеш категориясе буларак каралуын әйтә [1, 123]. Рус телендә бу нәкъ менә шулай [3, 53]. «Татар грамматикасы»нда актив һәм пассив төзелмәләрне махсус өйрәнгән бүлек юк, шулай да төшем юнәлешенең нигездә күчемле фигыльләрдән ясалуы искәртелә.

Процессны башкаручы нинди чара ярдәмендә бирелүгә карап, С.Ибраһимов пассив төзелмәләрне берничә төргә бүлә [2, 137]. Шул бүленешкә нигезләнеп, ике тел материалын чагыштырып карыйк.

1. Билгесез килештәге исем яки иялек килешендәге алмашлык янында *тарафыннан* бәйлек сүзе килә. III зат күплек сандагы алмашлык иялек килеше кушымчасы алмый. Мәсәлән, *Мәкаләләр Фәрит тарафыннан язылалар иде – Статьи писались Фаритом. Факультет Советы тарафыннан сайланып, коллегабыз бүләкләнде – Коллега была избрана и награждена Советом*

*Факультета. Билетлар автобус йөртүче тарафыннан тукталышларда гына сатыла – Билеты продаются водителем только на остановках.*

2. Процессны башкаручы пассив төзелмә төшем юнәлешендәге фигыльгә *белән* бәйлеге аша иярә. Мәсәлән, *Җил белән кырылып беткән агачларга гаҗәпләнеп карап торды ул – Он удивленно смотрел на скошенные ветром деревья.*

3. Процессны башкаручы сүз пассив төзелмәдәге фигыльгә *өчен* бәйлеге ярдәмендә иярә. *Барыбыз өчен дә уртак дошман саналган ул сүзне (интеллигент сүзен) яңадан бер мәртәбә ишетергә теләмичә, секретарьга ризалык бирдем* (Ф Хөсни) – *Не желая еще раз услышать считаемое для всех нас общим врагом это слово (слово интеллиент), я дал секретарю свое согласие.*

4. Үтәүчене белдерә торган сүз пассив төзелмәдәге фигыльгә *чыгыш килеш кушымчасы* ярдәмендә иярә. Мәсәлән: *Тулай торактагы тәртип җаваплы кеше Алсудан тикшертелә – Порядок в общежитии проверяется ответственным за это человеком – Алсу.*

5. Пассив төзелмәләрдә процессны башкаручы төшем юнәлешендәге фигыльгә *юнәлеш килеш кушымчасы* белән ялгана. *Өзлексез яңгыраган күк күкрәүдән колаклар тона – Из-за непрерывно грохочащего грома звенело в ушах.*

6. Кайбер җөмләләрдә процессны үтәүче аерым сүз белән бирелә алмый, шуңа күрә мондый җөмләләрне үтәүчесез бер составлы дип атарга мөмкин. *Яшьлек үтте, инде картаелды; Яшим хәзер читтә, ышыкта*. (М.Җәлил). – *Молодость прошла, уже состарилось...* Күчемсез фигыльнең төшем юнәлешендәге төре шулай ук үтәүченең аерым сүз белән тәмамлык рәвешендә бирелүен таләп итми. *Бөтенесе дә гадәт буенча гына, акылдан тыш, теләктән тыш эшләнә иде. (Ә.Еники) – Все делалось по привычке, без задумок и размышлений.*

Рус теленнән татар теленә тәрҗемә иткән вакытта бу төзелмәләрне куллану үзенчәлекләренә игътибар итү кирәк. Аерым очракларда турыдан-туры тәрҗемә бөтенләй урынсыз булырга да мөмкин. Рус телендәге актив төзелмәләрне татар теленә пассив итеп тәрҗемә итү еш очрый. Әлеге төзелмәләрнең берсен генә артык күп куллану чагыштырыла торган телнең икесендә дә яңгыраш һәм аңлаешлылыкка зыян китерергә мөмкин. Шуңа күрә процессны башкаручыны конкрет күрсәтергә кирәк булганда актив конструкция кулай. Мәсәлән: *Бу уку елы безнең группа тарафыннан уңышлы тәмамланды, имтиханнар яхшы билгеләргә генә бирелде. Курс эшләре вакытында язылып, якланып бетелде – В прошедшем учебном году нашей группой были успешно сданы все экзамены. Своевоременно написаны и защищены курсовые работы.* Бу рәвешле җөмләләрне рәттән тезеп китү әлеге текстны кабул итүне кыенлаштыра. Тезелеп киткән пассив төзелмәләрне мөмкин кадәр күбрәк төр синонимнар белән алыштыру ике телдә дә текст яңгырашлырак итәчәк.

Ике телдә дә актив һәм пассив төзелмәләр сөйләм аңлаешлылыгы, кыскалыгы, җөмләдән аңлашылган процессны башкаручы белән шул процесс арасындагы мөнәсәбәтләрне төрле юллар аша күрсәтүгә хезмәт итә.

Әдәбият

1. Зиннатуллина, К.З. Залоги глагола в современном татарском литературном языке. – Казан: Таткнигоиздат, 1966. – 232 с.
2. Ибраһимов, С. Татар телендә синтаксик синонимнар. – КДУ нәшр., 1976. – 168 б.
3. Сафонова, С.С. Лекции по современному русскому языку. – 2008. – 198 с.
4. Современный русский литературный язык. Учебник для студентов высших учебных заведений. обучающихся по специальности “Филология”. Издание 3-е, исправленное. / авт. Лекант П.А., Гольцова Н.Г. и др. – М.: Высшая школа, 1996. – 462 с.
5. Сопоставительная грамматика русского и татарского языков. Морфология. / авт.-сост.: Р.Р.Замалетдинов, М.Р.Саттарова, С.С.Сафонова, О.А.Чупрякова, З.Ф.Юсупова; под ред. проф. Р.Р.Замалетинова. – Казань: Изд-во Казан ун-та, 2017. – 180 с.
6. Сопоставительная грамматика русского и татарского языков. Синтаксис. / авт.-сост.: Р.Р.Замалетдинов, С.С.Сафонова, Г.А.Набиуллина, О.А.Чупрякова; под ред. проф. Р.Р.Замалетинова. – Казань: Издательство Казанского университета, 2019. – 190 с.
7. Татар грамматикасы. Морфология. Т. II. / Н.Б.Борһанова, Ф.А.Ганиев, М.З.Зәкиев һ.б. – М.: «ИНСАН», Казан: «ФИКЕР», 2002. – 448 б.

# ТУГАН ТЕЛ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ТАТАР СҮЗЛЕКЛӘРЕ

Сафина Э. И.
ТР ФА ның Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
7idillia@mail.ru

**Аннотация.** В статье дается обзор упражнений из учебников, которые используются на уроках по изучению родного (татарского) языка. Объектом изучения стали задания, ориентированные на использование словарей на уроках языка.

Проведенный анализ показал, что современная методика изучения родного языка в значительной мере строится на работе с различными словарями татарского языка (межъязыковыми, толковыми, орфографическими). К словарям учитель обращается при изучении собственно лексикографических тем и на занятиях по другим темам. Ученики получают задания найти перевод слова, проверить его лексическое значение в словаре, сравнить описание слова в разных словарях – такие упражнения помогают им лучше усвоить лексику, расширяют словарный запас, развивают навыки поисковой и аналитической работы, воспитывают интерес к изучению родного языка.

**Ключевые слова:** Лексикография, словари, учебники родного языка, методика преподавания, татарский язык.

Укучыларга туган телебезнең камил, төзек, бай тел булуын аңлату, аларда ана телебезгә мәхәббәт уяту өчен дәресләрдә сүзлекләр куллану нәтиҗәле алым булып тора. Сүзлекләр белән эшләү иҗади фикерләргә, белемне башкалар белән уртаклашырга өйрәтә, күзәтү, хәтерләү, игътибар итү сәләтен үстерә. Лексикографик чыганаклар кулланыла торган дәресләрнең максаты – тел өйрәнүдә сүзлекләрнең әһәмиятен ассызыклау, телнең бөтен байлыгын, тулылыгын, төрлелеген күрсәтү.

Мәктәптә сүзлекләр белән эшне башлангыч сыйныфлардан ук оештырганда, укучыларда туган телләрен өйрәнүгә кызыксыну уятырга, сакчыл караш тәрбияләргә мөмкин. Гадәттә, татар теле кабинетларында русча-татарча, татарча-русча сүзлекләр, татар теленең аңлатмалы сүзлекләре, синонимнар сүзлеге, фразеологик, диалектологик, энциклопедик, орфографик сүзлекләр була. Шул ук вакытта, туган тел (татар теле) дәреслекләренең һәрберсендә кушымта буларак «Татарча-русча сүзлек», «Русча-татарча сүзлек», «Орфографик сүзлек», «Орфоэпик сүзлек», «Синонимнар сүзлеге», «Антонимнар сүзлеге», «Фразеологизмнар сүзлеге», «Аңлатмалы сүзлек» һ.б. бар. Сүзлек белән бәйле биремнәрнең кайберләре әлеге кушымта белән эшләүне күз уңында тотып уйланылган.

Сүзлекләр белән эш төрле сыйныфларда төрлечә алып барыла. Мәсәлән, беренче сыйныфта укучылар үзләре сүзлек дәфтәрләре булдырып, һәр лексик теманы үткән саен, яңа сүзләрне шунда язалар. Башта дүрт-биш сүз язсалар, соңрак сүзләр саны арта бара. Икенче-өченче сыйныфларда укытучылар

алдында укучыларга сүзлекләр турында кыскача мәгълүмат бирү һәм алар белән эшләргә өйрәтү бурычы тора. Мисал өчен, «Татар телендә төрле сүзлекләр бар. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә сүзнең мәгънәсе аңлатыла. Сүзләрне бер телдән икенче телгә тәрҗемә итү өчен дә сүзлекләр кулланыла. Мәсәлән: русча-татарча сүзлек, татарча-русча сүзлек, татарча-русча-инглизчә сүзлек» дип, сүзлекләр турында мәгълүмат бирелеп кенә калмый, балалар үзләре «Русча-татарча сүзлек»тән *сказка, поэт, рассказ, стих, книга* сүзләренең тәрҗемәләрен эзләп табып, башваткычны чишәргә тиеш булалар [4, 76]. Укучыларга җайлы булсын өчен, дәреслек ахырында татарча-русча сүзлек (116-122 бб.) бирелгән.

Өченче сыйныфта укучылар сүзлекләр белән тагын да активрак эшлиләр. «Сүзлектә сүзләргә аңлатма яки тәрҗемә бирелә. Сүзләр алфавит тәртибендә урнаша. Бу – сүзне тиз эзләп табарга ярдәм итә. Беренче хәрефләр бертөрле булса, икенче, өченче хәрефләрне карарга кирәк: *җәй, Җәүдәт, җиләк*» [6, 16]. Үзләреннән сүзлек төзетү алымы укучыларның сүзләрнең лексик мәгънәләренә игътибарын арттырырга ярдәм итә. Мисал өчен, *авыл, сад, диңгез, ракушка, күл, бакча, озеро, кабырчык, деревня, море* кебек сүзләр бирелә һәм укучылар шул сүзләрне дөрес урнаштырып, татарча-русча сүзлек төзи [6, 16]; «Сүзләрне һәм аларның аңлатмаларын дөрес урнаштырып, сүзлек төзе: *алма – алмагачның җимеше, урман – агачлар күп булып үскән урын; әби – әтинең яки әнинең әнисе*» һ.б. [6, 16].

Татар телендә башлангыч гомуми белем бирүче мәктәпләрнең 3 нче сыйныфы өчен дәреслек сүзлекләр белән эшләүгә юнәлтелгән биремнәрнең тагын да күп һәм төрле булуы белән игътибарны җәлеп итә. Билгеле, беренче чиратта әлеге күнегүләр дәреслек ахырында бирелгән бай сүзлекчәләргә нигезләнеп башкаруны күз уңында тота. Мисал өчен, «Тотрыклы сүзтезмәләр сүзлеге»ннән *кызыл кар яугач* сүзтезмәсенең мәгънәсен ачыкла» [3, 12] һ.б. Бер үк вакытта ике төрле сүзлек белән эш итәргә өйрәтә торган күнегүләр дә очрый: «*Охшый* һәм *ошый* сүзләре бер-берсенә охшашмы? *Охшый* һәм *ошый* сүзләрен кертеп, җөмлә төзеп яз. «Дөрес яз сүзлеге»ннән *охшый* һәм *ошый* сүзләренең дөрес язылышын тап. «Аңлатмалы сүзлек»тән бу сүзләрнең мәгънәләрен ачыкла. Истә калдыр» [3, 57]. «Аңлатмалы сүзлек» белән эш итүгә багышланган күнегүләр түбәндәгечә: «*абзац* сүзен табып, мәгънәсен укы» [3, 71], «*салма, тути* сүзләренең мәгънәсен табып укы» [3, 94] һ.б. 108-109 битләрдәге «Дөрес яз сүзлеге»ндә *авыр, акбур, җиһаз, көянтә, рөхсәт, ятьмә* һ.б. бик күп сүзләр урын алган. Әлеге биремнәр билгеле бер сүзнең язылышына игътибар юнәлтү, аны истә калдыру өчен: «Дөрес яз сүзлеге»ннән *чәкчәк* сүзенең дөрес язылышын тап һәм истә калдыр» [3, 62] һ.б.

Дүртенче сыйныфта русча-татарча сүзлек, аңлатмалы сүзлекләр белән актив эш алып барыла. Мисал өчен, *смородина, природа, свербига, борщевик, дети* сүзләре бирелгән һәм «Русча-татарча сүзлек ярдәмендә башваткычны чиш» [7, 14]; *эшләпә, кәбестә, эскәмия* сүзләре бирелгән һәм «Рус һәм татар телләрендә бертөрле әйтелгән сүзләрне билгелә. Аңлатмалы сүзлектән аларның мәгънәләрен табып укы» кебек эшләр кушылган [7, 46]. 80-85 битләрдә «Сүзлек

эше» өлешендә алдагы сыйныфлардагы кебек, бай сүзлек китерелә. Укучылар өчен бу дәфтәрләренә күчереп язу, истә калдыру, кирәк вакытта тиз генә карап алу һәм дәреслектә бирелгән күнегүләрне, биремнәрне эшләү өчен бик җайлы.

Бишенче сыйныф дәреслеге орфографик сүзлекләр ярдәмендә эшләнергә тиешле күнегүләргә бай. Мәсәлән, «Орфографик сүзлекчәдән [h] һәм [x] тартыклары кергән сүзләр язып ал һәм ике җөмлә уйлап яз» [1, 47]. Укучылар үзләре уйлап мөстәкыйль рәвештә эшли торган проект буларак, «Безнең проект» өлешендә «Орфографик сүзлек төзибез» дигән бирем бар. Укучыларга «Орфографик сүзлек турында нәрсәләр беләсең? Без кайчан орфографик сүзлеккә мөрәҗәгать итәбез?» дигән сораулар бирелә һәм «Сүзләрне укып, хаталарын төзәтеп яз һәм орфографик сүзлекчәдән үзеңне тикшер», «Дөрес язу кагыйдәләрен искә төшер. Бер кагыйдәне сайла һәм, шул кагыйдәгә караган сүзләрне туплап, сүзлекчә төзе. Сүзләрне дәреслектән, сүзлекләрдән, газета-журналлардан сайлап ал һәм алфавит тәртибендә яз» [1, 93] кебек биремнәр ортологик сүзлекләр белән дөрес эш итәргә өйрәтә. Шул ук вакытта, дәреслекнең графика һәм орфография темасында орфографик сүзлекләр турында мәгълүмат бирелсә тагын да яхшырак булыр иде. Билгеле, дәрестә укытучы бу хакта сөйли, укучыларга сүзлекләрне күрсәтә дип аңларга кирәк, әмма дәреслектә дә җыйнак гына мәгълүмат артык булмас. Мисал өчен, шул ук дәреслектә аңлатмалы сүзлекләр турында болай диелә: «Сүзләрнең мәгънәләре махсус сүзлекләрдә аңлатыла. Алар аңлатмалы сүзлекләр дип атала. Әлбәттә, телдәге сүзләрне санап бетерү мөмкин түгел, шуңа күрә аңлатмалы сүзлеккә татар теленең барлык сүзләре дә кергән дип булмый. Аңлатмалы сүзлекләр зур күләмле булалар. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә 58 меңгә якын сүзнең мәгънәсенә аңлатма бирелгән. Сүзлектә сүзләр алфавит тәртибендә бирелә. Сүзлекләрдә, шулай ук, сүзләрнең язылышы, әйтелеше, мәгънәләре, килеп чыгышы да бирелә. Сүзлекләр төзү турындагы фән лексикография дип атала» [1, 96]. Дәреслектә аңлатмалы сүзлекчәдән файдаланырга өйрәтүгә юнәлтелгән биремнәр дә шактый: «Аңлатмалы сүзлекчәдән өч сүзне (исем, сыйфат, фигыль) сайлап ал. Аларның лексик мәгънәләрен укы, җөмләләр төзе» [1, 98]; «Аңлатмалы сүзлекчәдән берничә мәгънә белдерә торган 2-3 сүз табып яз. Алар белән сүзтезмәләр төзе. Сүзтезмәдә сүзнең лексик мәгънәсе ачык чагылсын» [1, 100] һ.б. шундыйлардан. Дәреслектә синонимнар һәм антонимнар сүзлекчәсе [1, 103], тәрҗемә сүзлекләр («Русча-татарча сүзлекчәдән файдаланып, текстны татарчага тәрҗемә итеп яз») [1, 96], фразеологик сүзлекләр белән эшләү дә каралган. Шулай ук, фразеология темасын үткәндә фразеологик сүзлекләр турында мәгълүмат бирү отышлы булыр иде.

Мисаллардан күренгәнчә, һәр сыйныфта сүзлекләргә игътибар зур, алар ярдәмендә эшләнергә тиешле биремнәр, күнегүләр күптөрле. Мәкалә кысаларында барлык туган тел (татар теле) дәреслекләреннән дә мисаллар китереп, анализ ясау мөмкин түгел. Шуңа, югары сыйныфлар өчен дәреслекләрнең бары берсенә – унынчы сыйныф укучылары өчен төзелгән уку әсбабына гына тукталырбыз. Күнегүләрдән күренгәнчә, 10 нчы сыйныфта сүзлекләрнең төрле типтагыларына игътибар юнәлтелә. Беренче урында,

әлбәттә, аңлатмалы сүзлек. Биремнәр түбәндәгечә: «*Кар* сүзенең төп мәгънәсен «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ннән карагыз, күчерелмә мәгънәдә килгән очраклар белән җөмләләр төзеп языгыз» [2, 64], «Текстта кулланылган 5 сүзнең синонимик оясын төзеп языгыз. «Синонимнар сүзлеге»ннән дөреслеген тикшереп карагыз» [2, 73], «*Сүзлек* сүзе «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә һәм «Татар теленең этимологик сүзлеге»ндә ничек бирелгән, нәтиҗә ясагыз» [2, 117]; «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н карагыз. Ике бер мәгънәле һәм дүрттән күбрәк мәгънәсе булган ике күп мәгънәле сүзне күчереп языгыз» [2, 119] кебек биремнәрдән күренгәнчә, дәреслектә төп игътибар аңлатмалы һәм телара сүзлекләргә юнәлтелә. Яңалык буларак, этимологик сүзлек белән эшләү өстәлә. Дәреслекнең 188-189 битләрендә орфографик-орфоэпик сүзлекчә, антонимнар сүзлекчәсе китерелә.

Төрле типтагы сүзлекләр белән эшләүне күздә тоткан биремнәр, күнегүләрдән күренгәнчә, туган тел (татар теле) дәреслекләрендә татар сүзлекләренә зур игътибар бирелә. Дәресләрдә аеруча русча-татарча, татарча-русча, аңлатмалы, орфографик, фразеологик сүзлекләр белән актив эш алып барыла. Һәр дәреслек ахырында орфографик, аңлатмалы, татарча-русча, орфоэпик һ.б. сүзлекчәләр бар. Билгеле, күпчелек очракта укучылар күнегүләрне дәреслектәге шул сүзлекчәләр ярдәмендә генә дә эшләп куярга мөмкин. Димәк, укучыларны чын сүзлекләр, галимнәр төзегән лексикографик чыганаклар белән таныштыру укытучылар җаваплылыгында кала. Мәктәпләрдә аңлатмалы, ортологик, фразеологик, телара һ.б. сүзлекләр белән эш һәрдаим алып барылырга тиеш. Бары тик татар сүзлекләре генә туган телебезнең бөтен байлыгын, тулылыгын, төрлелеген күрсәтә һәм укучыларда туган телгә мәхәббәт, сакчыл караш тәрбияли ала.

**Әдәбият**

1. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 5 нче с-ф. / Р.Р.Шәмсетдинова, Г.К.Һадиева, Г.В.Һадиева; [рәссамы Л.Хисамова]. – Казан: «Мәгариф – Вакыт» нәшр., 2015. – 175 б.

2. Татар теле: рус телендә урта гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 10 нчы с-ф. / Р.К.Сәгъдиева; [рәссамы Л.Хисамова]. – Казан: «Мәгариф – Вакыт» нәшр., 2016. – 167 б.: рәс. б-н.

3. Татар теле: татар телендә башл.гомуми белем бирү мәкт. 3 нче с-фы өчен д-лек. 2 нче кисәк / И.Х.Мияссарова, К.Ф.Фәйзрахманова: рәссамы Л.Хисамова. – Казан: «Мәгариф – Вакыт» нәшр., 2013. – 111 б.: рәс. б-н.

4. Туган тел (татар теле). 2 сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). / М.М.Шәкүрова, Л.М.Гыйниятуллина, О.Р.Хисамов; [рәссамы Диләрә Нәүрузова]. – Казан, 2020. – 126 б. : рәс. б-н.

5. Туган тел (татар теле). 2 сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган

тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). / М.М.Шәкүрова, Л.М.Гыйниятуллина, О.Р.Хисамов; [рәссамы Диләрә Нәүрузова]. – Казан, 2020. – 112 б. : рәс. б-н.

6. Туган тел (татар теле). 3 сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). / М.М.Шәкүрова, Л.М.Гыйниятуллина, О.Р.Хисамов; [рәссамы Андрей Шляпкин]. – Казан, 2020. – 104 б. : рәс. б-н.

7. Туган тел (татар теле). 4 сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). / М.М.Шәкүрова, Л.М.Гыйниятуллина, О.Р.Хисамов; [рәссамы Андрей Шляпкин]. – Казан, 2020. – 88 б. : рәс. б-н.

# ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ СӨЙЛӘМ ТЕЛЕН ҮСТЕРҮ ҺӘМ КАМИЛЛӘШТЕРҮ ЧАРАСЫ БУЛАРАК КРОССВОРДЛАР

Сәлахова Р. Р.
Казан федераль университеты
*Ruzilya5@mail.ru*

**Аннотация.** В данной статье рассматриваются различные подходы к формированию речевого компонента профессиональной культуры в процессе подготовки специалиста к будущей профессиональной деятельности, отмечаются преимущества использования кроссвордов в формировании умений и навыков профессиональной коммуникации на татарском языке.
**Ключевые слова**: татарский язык, профессиональная культура, профессиональная коммуникация, речевая деятельность, кроссворд.

Сөйләм – кеше эшчәнлегенең төп компонентны булып тора, аның үсеше сөйләм эшчәнлегенең башка төрләрен үзләштерүгә юл яра. Өйрәнә торган телдә сөйләргә өйрәтү элек-электән тел дәресләренең төп бурычларыннан саналды. Әгәр анализаторлар эшчәнлеген күзәтсәк, сөйләгәндә сөйләм-мотор анализаторы, тыңлаганда ишетү анализаторы актив роль уйнаганны күрербез, әмма һәр ике очракта да сөйләм органнары хәрәкәттә була. Сөйләгәндә сөйләм органнары хәрәкәт итә. П.П Блонский бу хакта болай дип яза: Сөйләүче белән тыңлаучы икесе дә сөйли, ләкин берсе – кычкырып, икенчесе – эчтән”[3, 56].

Сөйләм телен үстерү күнекмәләрен формалаштыруның рациональ методикасын эшләү өчен психолингвистик анализ ясау зарур. Психологик күзлектән караганда, сөйләүнең өч фазасы бар:

- хәбәрнең максатын ачыклау;
- фикерне тел ягыннан формалаштыру;
- хәбәрне әйтү.

Шушы фазалардан чыгып, сөйләм эшчәнлегенең әлеге төренә кагылышлы сәләт һәм күнекмәләрне билгеләп була:

- татар сөйләменең авазларын оештыру сәләте;
- татар теле чараларын автоматик рәвештә һәм кирәкле күләмдә куллана белү, ягъни, аралашу максаты һәм ситуациясенә туры китереп, татарча сөйләм оештыру механизмын куллану сәләте[1, 129].

Һөнәри белем бирү уку йортларында тел дәресләренә куелган төп бурыч – булачак белгечләрнең сөйләм телен үзләштерелә торган һөнәренә бәйле рәвештә үстерү, камилләштерү, һөнәри сөйләмгә осталык һәм күнекмәләр формалаштыру. Һөнәри осталык һәм күнекмәләргә булачак белгечнең белем дәрәҗәсе, фикерәү сәләте, һөнәри әзерлеге һәм коммуникатив осталыгы керә.

Югарыда санап киткән осталыкларны формалаштыруда кроссвордлар куллану отышлы чараларның берсе булып тора. Кроссворд сүзе инглиз теленнән алынган, ул “сүзләр киселеше” дигән мәгънәгә ия [2, 8], аны чишү мавыктыргыч һәм файдалы шөгыль, ул балаларга да, урта буын кешеләренә дә, өлкәннәр дә ошый. Башлангыч һәм урта мәктәптә аерым сүзләрне, аларның

мәгънәләрен яки тәрҗемемәләрен үзләштерү өчен кулланылса, югары мәктәптә һөнәри сөйләм күнекмәләрен булдыру, сөйләм телен камилләштерү максатында кулланылып, студентларның үзләштерелә торган темага карата кызыксынучанлыгын арттыруга сәләтле. Студентлар укытучы тарафыннан алдан әзерләнгән кроссвордны чишәргә яки аны үзләре төзергә мөмкиннәр. Гадәттә, судентларга әзер кроссвордларны чишү ошыйрак төшә, чөнки аларга билгеле бер телдә бәйләнешле хәбәрләмәләр төзүгә караганда, сорауларга җавап бирү күпкә җиңелрәк. Әмма кроссвордны укытучы белән бергәләп чишү мөһим, чөнки укытучы студенттан кроссворд җавапларына хас кыска (бер сүзле) җаваплар түгел, ә тулы җавап таләп итәргә тиеш. Биредә студент тарафыннан монологик сөйләм формасы үзләштерелә һәм аның мөстәкыйль фикерләү сәләте алгы планга чыга. Әмма студент җавабын дөрес формалаштыру өчен укытучының соравын да игътибар белән тыңларга (аудирование) һәм аңларга тиеш, шул рәвешчә, укытучы белән студент арасында диалог формалаша. Методик әдәбиятта диалогның иң киң таралган билгеләмәсе якынча болайрак яңгырый: ("якынча" дибез, чөнки без берничә билгеләмәне берләштердек): "Диалог ул – мәгълүмат алмашу, максаты белән ике яки берничә әңгәмәдәшнең фикер алышуы. Бу вакытта берәү сөйләм реакциясе уята, икенчесе җавап бирә, шуның нәтиҗәсендә үзара функциональ бәйләнеш гамәлгә ашырыла"[5, 78-79].

Шулай итеп, кроссворд чишү барышында телдән сөйләмнең ике формасы – диалог һәм монолог гамәлгә ашырыла.

Уку процессында кроссвордлар куллануның нәтиҗәлелеген арттыру өчен түбәндәге таләпләр үтәлергә тиеш:

1. Беренчедән, кроссвордларны чишү артык күп вакыт алмаска тиеш, чөнки нинди генә кызыклы тоелмасын, бер төрлелек ялыктыра, кызыксынуны киметә, икенчедән, әлеге таләпне үтәлмәсә, бер дәрес кысаларында телнең төрле аспектлары һәм сөйләм эшчәнлегенең башка төрләрен дә кулануга ирешеп булмый. Кроссвордның оптималь күләме, безнең күзлектән караганда, 5-15 бирем чикләрендә (материалның катлаулылыгына карап, төркем әзерләү, укыту этабы).

2. Кроссворд биремнәре аңлаешлы булырга һәм андагы сораулар студентның алдан үзләштергән материалларына нигезләнергә тиеш. Крссвордта аңлашылмый торган сүзләр яки терминнар булмау зарур.

3. Кроссворд биремнәрендә җиңел һәм катлаулы сорауларны аралаштыру мөһим. Катлаулы сораулар студентларның фикерләү сәләтен үстерү белән беррәттән, аларның әлеге эшкә кызыксынуын арттыра, тиз арада чишелә торган кроссворд кызык түгел, ул уйландырырыга тиеш. Әмма җиңел биремнәрсез дә булмый, алар, үз чиратында, һәр студентка дәрестә катнаша алу, ягъни фикерләрен туплап, үз җавап вариантын тәкъдим итү мөмкинлеге бирә, чөнки җиңел сорауларга җавапны һәркем дә белә.

Кроссвордлар чишү төрлечә оештырырыга мөмкин:

1. Индивидуаль мөстәкыйль эш: а) бөтен төркем бер үк вакытта; б) студентларның бер өлеше кроссворд чишә, шул ук вакытта калганнары сөйләм күнекмәләрен арттыру юнәлешендәге башка эш төрләре белән мәшгуль.

2. Төркем ике командага бүленә, аларның һәркайсына бер үк төрле кроссвордлар тәкъдим ителә. Кроссвордны чишү вакыты чикләнелми, әмма “Кем тизрәк чишә?” дигән шарт куела.

3. Ярышта бер үк төрле кроссвордлар чишәргә тиеш булган өч һәм аннан да күбрәк команда катнаша. Кроссвордны чишүгә чикләнгән вакыт бирелә.

Югарыда санап үтелгән вариантлар һәркайсы үз өстенлекләренә ия. Беренчесе студентны индивидуаль рәвештә эшләвенә уңай шартлар тудыра, шул ук вакытта укытучыга аның теге яки бу лексиканы үзләштерү дәрәҗәсен аңларга мөмкинлек бирә. Калган формаларның үзенчәлеге студентларның төркемләп эшләве белән аңлатыла, биредә конкурентлык сәләте алга чыга. Әлбәттә, бу очракта әзерлек дәрәҗәсе түбән булган студентлар эшнең нәтиҗәсен киметергә мөмкин, әмма аларның кроссвордны чишү барышында үз җавап вариантыларын тәкъдим итүләре, шул рәвешле аларның элеге эштә катнашулары, активлык күрсәтүләре шулай ук зур әһәмияткә ия.

Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында “Музыка” белгечлеген үзләштерүче студентлар белән татар теле дәресләрендә кроссвордларны еш чишәбез. Мәсәлән, “Танылган композиторлар” темасын үзләштергәннән соң түбәндәге кроссворд тәкъдим ителгән иде.

1. Кроссвордны чишегез. Җавапларны һәр баганага астан өскә таба языгыз

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| М | О | Т | Р | И | Б |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

1. Әлеге музыкант 4 яшендә клавир өчен көй иҗат итә. Бу көй уйнар өчен бик катлаулы, әмма бик матур була, аны Европаның иң виртуоз башкаручылары да уйный алмый. Сүз кайсы композитор турында бара? Фамилиясен языгыз.

2. Бу композитор танылган химик Менделеев Дмитрий Ивановичның дусты һәм фикердәше була, композиторлыктан тыш, ул фән белән шөгыльләнгән, фәнни ачышлар ясаган, медицина фәннәре докторы булган, химия лабораториясен җитәкләгән. Әлеге шәхеснең тулы исем-фамилиясен атагыз. Фамилиясен языгыз.

3. Яңа көй язар алдыннан әлеге композитор башын бозлы салкын су салынган ләгәндә чылата торган булган. Бу гадәт аның гомеренең соңгы көннәренә кадәр сакланып калган. Әлеге шәхеснең тагын бер үзенчәеге – ул саннарны тапкырлый белмәгән. Сүз кем турында бара? Фамилиясен языгыз.

4. 1991 нче елда, йөз еллык юбилее уңаеннан, әлеге композитор сурәте төшерелгән көмеш акча чыгарыла. Санкт-Петербург шәһәрендә һәр ел саен аның исемендәге Халыкара конкурс үткәрелә. Бу конкурста композиция, симфоник дирижерлык һәм фортепиано кебек өч белгечлек бәяләнә. Бу шәхеснең тулы исемен атагыз. Фамилиясен языгыз.

5. Бу музыкант иҗатының башлангыч чорында Максим Горький белән бер үк вакытта хорга язылып карый. Тыңлаулардан соң, Максим Горкькийны хорда җырларга кабул итәләр, әмма әлеге музыкант хорга алынмый. Сүз кем турында бара? Фамилиясен языгыз.

6. Әлеге музыкант 5 нче буын музыкантлар гаиләсендә туган Аның 50 гә якын туганы музыка иҗаты белән шөгыльләнгән. Үзенең ике баласы да танылган композитор була. Әлеге шәхеснең исемен языгыз.

Кроссвордтагы җаваплар: 1. Моцарт; 2. Бородин; 3. Бетховин; 4. Прокофьев; 5. Шаляпин; 6. Себастьян [8].

Күргәнебезчә, әлеге кроссворд структурасы ягыннан әлләни авыр түгел, мондый кроссвордны командага бүленеп чикләнелгән вакыт аралыгында чишү өчен тәкъдим итәргә мөмкин. Биредә сүзләр киселеше юк диярлек, аркылы юлда язылган биремнең җавабы бар. «Мотриб – музыкант. Понятие обобщающего значения, получившее широкое распространение в культурах мусульманского Востока, начиная с раннего средневековья. Одна из наиболее чсто встречающихся категорий в старотатарской литературе» [4, 83]. Бу сүз кроссворд чишүне бераз җиңеләйтә һәм әгәр студент әлеге сүзнең нәрсә аңлатканын әйтеп бирә алса, команда өстәмә балл алу мөмкинлегенә ия була.

Студентка кроссвордны үзеннән төзетү дә сөйләм эшчәнлеген үстерүдә үзенчәлекле эш төрләренең берсе булып тора. Ул студенттан мөстәкыйльлек, иҗадилык таләп итә. Биредә әзер материалдан да, өстәмә материалдан да файдаланырга мөмкин. Өстәмә материал рус телендә булган очракта, студент татарчага дөрес итеп, төзек җөмләләр белән тәрҗемә итәргә тиеш була. Студентлар тарафыннан төзелгән кроссвордлар түбәндәге критерийләр буенча бәяләнә:

1. Кроссворд нинди максат белән төзелүе.
2. Кроссворд темасының укыту программасына туры килү-килмәве.
3. Кроссоворд төренең дөрес сайланышы
4. Кроссвордның аерым кисәкләре төзелеше.
5. Өстәмә материал кулланылышы.
6. Бәяләү критерияләре.
7. Кулланылган сүзләрнең исемлеге.
8. Кроссворд биремнәренең (сораулары) төзеклеге.
9. Кроссворд биремнәренең орфографиясе.
10. Кроссвордның презентациясе.

Укытуда яңа технологияләр куллану – заман таләбе. Мондый дәресләр укучыларны да, студентларны да битараф калдырмый киресенчә, аларның кызыксынучанлыгын арттыра. Кроссвордлар чишүне дә яңа технологияләр аша оештырырырга була. Бу юнәлештә кроссворд төзү өчен махсус сайтлар, онлайн сервислардан файдаланырга мөмкин. Шундыйларның берсе – Фабрика кроссвордов[8]. Бу бик уңайлы сервис, биредә таблицалар ясап утыру ихтыяҗы юк, сайлап алынган сүзләрне әзер шакмакларга дөрес итеп урнаштырырга гына кирәк. Әлеге сервис ярдәмендә теләсә нинди структурага ия булган кроссвордларны эшләү мөмкинлеге бар. Төзеп бетергәч, аны бастырып чыгарасы гына кала. Дәресләр дистанцион форматта укытылган очракта, студентларга алдан төзелгән кроссвордның сылтамасы бирелә һәм студент мөстәкыйль рәвештә әлеге сылтама аша кереп, кроссвордны чишә ала.

Кроссворды онлайн в Online Test Pad [6] сервисында кроссвордның бик күп төрләре тәкъдим ителә, биредә кроссворд конструкторы бар, аның ярдәмендә япон кроссворды, филворд яки сканфордлар да төзеп була. Әмма артык катлаулы структуралы башваткычлар дәрестә киенренкелекне арттырырга мөмкин, шуң күрә биредә чама хисен югалтмау сорала.

Cross: составь свой кроссворд онлайн [9] сервисын аеруча игътибарга лаек. Биредә кроссвордның сүзләрен (җавапларын) кертү һәм үлчәмен билгеләү таләп ителә, соңыннан әзер (тутырылган) кроссвордны Word форматында компьютерга йөкләргә кирәк. Әеге сервис ярдәмендә төзелгән кроссвордны дәрестә файдалану өчен кроссворд шаблонына хәбәрләмәләрне (сорауларны) кертергә һәм кирәкле күләмдә (экземпляр) бастырып чыгарырга була.

Йомгаклап әйткәндә, татар теле дәресләрендә кроссвордлар кулланылышы укытуның нәтиҗәлелеген арттыруда һәм студентларның белем дәрәҗәсен, һөнәри сөйләм телен үстерү, камилләштерүдә мөһим чара булып тора. Аларны дәресләрдә дөрес һәм урынлы итеп куллану әһәмиятле бурычлардан санала. Кроссвордлардан файдалану укытучылар алдына куелган күп төрле бурычларны хәл итәргә ярдәм итә: уку материалын аңлаешлы һәм кызыклы итеп җиткерергә; белемнәрне системага салырга булыша, укучыларның иҗади үсешен тәэмин итә, үзлектән белем алуны яхшырта, яңа темага җиңелрәк төшенергә мөмкинлек тудыра.

**Әдәбият**

1. Әсәдуллин А.Ш., Юсупов Р.А. Рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен укыту методикасы нигезләре. Казан: Мәгариф, 1998. 151 б.

2. Волков В.В. Использование методики кроссворд-тестирования при изучении гуманитарных и социально-экономических дисциплин // Актуальные проблемы гуманитарных и социально-экономических наук. 2019. Т. 13, №8. С. 8–14.

3. Пассов Е.И. Основы коммуникативной методики обучения иноязычному общению. Москва, 1989. 218 с/

4. Сайфуллна Г.Р. Категория татарской традиционной музыкальной культуры: аннотированный словарь. Казань:Тат.кн.изд-во, 2009. 176 с.

5. Сафиуллина Ф.С. Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре.- Казан, 2001. 383 б.

6. Кроссворды онлайн в Online Test Pad // URL: https://onlinetestpad.com (дата обращения 10.02.2021 г.)

7. Культурология. https://kulturologia.ru/blogs/091213/19462/(дата обращения: 15.01.2021 г.)

8. Фабрика кроссвордов // URL:https://puzzlecup.com/crossword-ru/ (дата обращения: 10.02.2021 г.).

9. Cross: составь свой кроссворд онлайн // URL:http://cross.highcat.org/ru_/ru (дата обращения: 10.02.2021 г.).

# ПЕРВЫЕ ШАГИ В ОБУЧЕНИИ КРЫМСКОТАТАРСКОМУ ЯЗЫКУ
(группа старшего возраста, неспециалисты)

Селендили Л.С.
Крымский федеральный университет им. В.И. Вернадского
lemara2002@hotmail.com

**Аннотация.** В статье рассматривается содержание начального этапа обучения крымскотатарскому языку, последовательность обучения фонетике, лексикологии, грамматике неспециалистов группы старшего возраста, приводятся примеры, обеспечивающие использование таких классических методов обучения как эвристический метод, сопоставительный, метод подстановки, прямой метод, грамматико-переводной метод обучения, аудиовизуальный и аудиолингвальный методы, коммуникативный метод. Обучение базируется на знаниях опорного языка и направлено на формирование начальной коммуникативной компетенции для свободной и эффективной речевой деятельности на языковом, речевом, дискурсивном, культурологическом и риторическом уровнях.
**Ключевые слова:** крымскотатарский язык, непрерывное образование, содержание образования, коммуникативная компетенция, фонетика, морфология.

Крымскотатарский язык – язык коренного населения Республики Крым. Это один из тюркских языков, традиционно относится к кыпчакско-половецкой подгруппе кыпчакских языков. Имеет три диалекта: южнобережный диалект, который относится к огузской группе, степной диалект - к кыпчакско-ногайской подгруппе и средний – микс-диалект, который в 1928 году на I Всекрымской научной конференции был принят за основу современного крымскотатарского литературного языка: «переходной от кыпчакского типа к огузскому, диалект Бахчисарайского и прилегающих к нему районов, восходящих к куманскому (кыпчакскому) языку и близких к нему племенным языкам северного Причерноморья, с охватом многих элементов как южного, так и северного диалектов» [4].

В связи с депортацией 1944 года крымскотатарский язык долгое время находился под запретом, в научном плане изучался фрагментарно, система образования на крымскотатарском языке и система изучения крымскотатарского языка были разрушены. После репатриации крымскотатарского народа на Родину были разработаны учебные программы по крымскотатарскому языку и литературе для школ с русским языком обучения и школ с углубленным изучением крымскотатарского языка и литературы, созданы учебники. Реалии современного Крыма меняются. В соответствии с принятой в 2014 году Конституцией Республики Крым крымскотатарский язык стал государственным языком республики.

Придание статуса языку, изменяющиеся реалии современного Крыма требуют таких же перемен в образовательных системах, методике преподавания крымскотатарского языка, дифференциации содержания языкового курса в зависимости от уровня преподавания. Наступило время говорить не только об изучении родного языка, но, прежде всего, об открытости крымскотатарской национальной картины мира другим народам. Взаимопонимание и межнациональное согласие базируется на простом понимании людей в процессе ежедневного общения. Обучение крымскотатарскому языку должно быть разноуровневым и непрерывным. Это обусловлено тем, что потребность изучать крымскотатарский язык может возникнуть у людей разных национальностей и разного возраста, для которых этот язык является родным или неродным.

Современная методика преподавания крымскотатарского языка должна базироваться на существующих актуальных концепциях обучения, методах и технологиях – как традиционных, так и новаторских. Здесь вполне применимы такие классические методы как эвристический метод, сопоставительный, метод подстановки, прямой метод, грамматико-переводной метод обучения, аудиовизуальный и аудиолингвальный методы, коммуникативный метод [6], метод погружения в языковую среду [7], кейс-методы в обучении [5].

В нашем докладе мы хотели бы остановиться на проблеме дифференциации содержания курса крымскотатарского языка на первом этапе в процессе обучения людей старшего возраста, неспециалистов, приоритетным языком общения для которых является, например, русский язык.

Обучаемые старшего возраста – это категория обучаемых, которые уже не являются школьниками или студентами вузов, не имеют филологического образования, но компетентны в русском (или ином) языке (далее опорный язык) для свободной и эффективной речевой деятельности на языковом, речевом, дискурсивном, культурологическом и риторическом уровнях [8]. Под *непрерывностью обучения языку* мы понимаем процесс развития коммуникативного потенциала личности, который не имеет временных границ и возрастных ограничений. Вопрос заключается в том, чему обучать на начальном этапе и в какой последовательности. Теоретической основой обучения может явится учебное пособие на русском языке: Меметов А. М., Мусаев К.М. Крымтатарский язык. Ч. 1. Общие сведения о языке ; Ч. 2. Морфология: учеб. пособие. –Симферополь : Крымучпедгиз, 2003. –287с.

Базовая коммуникативная компетенция в опорном языке важна для нас в плане коммуникативной преемственности и последовательности в обучении новому языку: важно иметь языковую базу, с которой будет сопоставляться изучаемый язык. Первый шаг - стоит показать именно те сходства и различия между языками, которые мотивировали бы обучаемого к изучению крымскотатарского языка и указывали бы на наличие у него начальной коммуникативной компетенции в этом новом для него языке.

Приведу примеры общей лексики:

• тюркизмы русского языка (известное выражение «поскреби любого русского — найдёшь татарина» в полной мере относится и к нашему языку): чердак - чардакъ, кафтан - къафтан, арбуз – къарпыз, казан – къазан, ишак – эшек, хан-хан, султан- султан, арба – араба, башка – баш, утюг - утю и даже «ура!»;

• крымскотатарские топонимы: Аю-Даг - Аювдагъ, Бахчисарай – Багъчасарай, Джанкой - Джанкой;

• интернационализмы, которые попали в крымскотатарский язык посредством русского языка: асфальт, радио, телевизор, чайник, газета;

• традиционные блюда крымских татар: манты, чебуреки, самса, пахлава, кобете

можно рассматривать как показатель начального уровня компетенции в крымскотатарском языке.

На примере общей лексики уже стоит показать разницу в алфавите русского и крымскотатарского языков - наличие специфических букв гъ, къ и дж, обратить внимание на конечные звуки: сонорные - л, м, н, р; парные глухие и звонкие согласные – к-г, къ-гъ, п-б; звонкие согласные «б, в, д, з, ж, г, гъ, дж» и глухие согласные «п, т, ф, с, ш, ч, къ, х», твёрдые и мягкие гласные – «а, ы, я, о, у» и «и, е, э, ӱ»; объяснить особенности словесного ударения (в тюркизмах падает на последний слог, в заимствованных словах остается как в языке-доноре или языке-посреднике), вопросы редукции гласных звуков.

По морфологическому типу крымскотатарский язык агглютинативный, словообразование и словоизменение происходит путём последовательного присоединения аффиксов: слева направо от корня к требуемому показателю, например: эв (корень слова - «дом»)+лер (показатель числа)+и (показатель принадлежности)+ н (протеза) +де(падежный показатель) +ки (показатель относительности).

Аффиксы имеют звуковые варианты. Для того, чтобы правильно выбрать соответствующий аффикс необходимо знать правила сингармонизма. Кратко правила сингармонизма можно объяснить так: твердому гласный к твердому, мягкий - к мягкому, губной - к губному; звонкий согласный к звонкому, глухой - к глухому. Для этого мы используем уже полученные знания о гласных и согласных звуках крымскотатарского языка и вводим новые гласные и согласные крымскотатарского языка на примерах русского (или иного опорного) языка: губные гласные мягкие - ӧ – как в слове тёрка, ӱ – как в слове тюлька , губные гласные твердые - о – как в слове дом, у – как в слове дума, специфическая буква нъ, обозначающая сонорный [нг] – как в слове сингармонизм.

Второй шаг: сопоставления – личные местоимения, наречие, прилагательное, можно на примере известной фразы из песни Роберта Рождественского:

Я, ты, он, она, Мен, сен, о

Вместе – целая страна, Берабер – бутюн девлет,
Вместе – дружная семья… Берабер – дост аиле…

Переводная пара местоимений «он, она - о» требует третьего шага: обратить внимание на отсутствие грамматической категории рода в крымскотатарском языке и показателях гендерной дифференциации в именах существительных: имена собственные - Селим (муж.) – Селиме (жен.), Зеки – Зекие, Джевхер – Джевер, Заир – Заира, нарицательные – шаир – шаире, оджа – оджапче, саип – саибе, огълан бала – къыз бала. Вводим имя существительное: категории числа (аффиксы -лар/-лер), категорию принадлежности, склонение имен существительных:

| Название падежа | Вопросы | Твёрдый вариант | Мягкий вариант |
|---|---|---|---|
| Именительный падеж | Кто? Что? | - | - |
| Родительный падеж | Чей? Чья? | -нынъ | -нинъ |
| Дательный падеж | Кому? Чему? Куда? Когда? В какое время? | -гъа/-къа | -ге/-ке |
| Винительный падеж | Кого? Что? | -ны | -ни |
| Орудийный падеж | Кем? Чем? | -нен, …иле, -нен берабер | -нен, иле, -нен берабер |
| Местный падеж | Где? У кого? В какое время? | -да/-та | -де/-те |
| Исходный падеж | От кого? От чего? Откуда? С какого времени? | -дан/-тан | -ден/-тен |
| Послеложный падеж | О ком? О чём? | …акъкъында | …акъкъында |

Изученный ранее лексический и теоретический материал можно повторить в процессе склонения имен существительных. Обучаемые письменно, без помощи гаджетов, фиксируют изученную лексику в личный словарь в той последовательности, в которой они его получают (так легче воспроизводить в памяти полученный ранее лексический материал).

Четвёртый шаг – прилагательное: неизменяемая часть речи, располагается препозитивно по отношению к слову (дост (друг, дружный) + аиле (семья)), которое оно определяет. Здесь уместно сказать о синтаксической позиции и функциях имени существительного, местоимения, прилагательного и наречия, односоставных и двусоставных предложениях с этими частями речи, словообразовании и разрядах прилагательных, местоименных прилагательных, их отличии от притяжательных местоимений, о понятиях «много»-«мало», числительных и основных принципах их образования, завершить знакомство с личными местоимениями и познакомить со склонением местоимений:

| Название падежа | Вопросы | 1-е лицо | 2-е лицо | 3-е лицо |
|---|---|---|---|---|

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Именительный падеж | Кто? Что? | мен биз | сен сиз | о олар |
| Родительный падеж | Чей? Чья? | меним бизим | сенинъ сизинъ | онынъ оларнынъ |
| Дательный падеж | Кому? Чему? Куда? Когда? В какое время? | манъа бизге | санъа сизге | онъа оларгъа |
| Винительный падеж | Кого? Что? | мени бизни | сени сизни | оны оларны |
| Орудийный падеж | Кем? Чем? | -нен, …иле, -нен берабер | -нен, иле, -нен берабер | -нен, иле, -нен берабер |
| Местный падеж | Где? У кого? В какое время? | менде бизде | сенде сизде | онда оларда |
| Исходный падеж | От кого? От чего? Откуда? С какого времени? | менден бизден | сенден сизден | ондан олардан |
| Послеложный падеж | О ком? О чём? | …акъкъында | …акъкъында | …акъкъында |

Пятый шаг: вводим глаголы наличия – олмакъ, бар/ ёкъ, глаголы чувств, движения и речи: севмек, юрьмек, кельмек, кетмек, айтмакъ, инфинитив, три основных времени глагола: настоящее, прошедшее и будущее, раскрываем синтаксическую позицию и функцию глагола; объясняем категорию сказуемости именных частей речи, строим предложения по схеме: подлежащее+сказуемое, определение+ подлежащее+сказуемое. Знакомство с оригинальным текстом на крымскотатарском языке. В качестве примера приведу отрывок из произведения Юсуфа Болата: «Айшечик беш яшында олса да, къартанасындан дюнья къадар шей огренди: ятса – геджелер хайыр, турса – сабалар хайыр; софрагъа отурса – бисмилля, софрадан турса – кисенъизге бинъ берекет; мусафир кельсе - хош кельдинъиз, эвге буюрынъыз, кетселер – огъурлы ёллар, кене келинъиз, тиземе, алама, эмджеме, дайыма селям денъиз…» (последовательность: обучаемый читает весь текст, слушает оригинальное прочтение слов, словосочетаний, предложений, всего текста; обучаемый читает, делает фонетические пометы, выписывает незнакомую лексику, слушает оригинальное прочтение, расширяем запас лексики и основных речевых формул, вводим термины родства, уменьшительно-ласкательные аффиксы имен существительных, условное наклонение глагола, повелительное наклонение глагола).

Базовые 5 шагов пройдены. Теперь обучаемый готов к освоению лексико-семантической информации, изучению и самостоятельному построению микротекстов, тематику и грамматическое сопровождение лексики для которых мы предлагаем в «Русско-украинско-крымскотатарского учебном словаре

«Шире круг» [1; 2; 9]. Изучение тематических групп лексики (их 185) в сочетании с изучением микротекстов, их построением и заучиванием сопровождается ситуативным введением речевого этикета [3].

## Литература


1. Богданович Г.Ю. Полилингвокультурный феномен: русско-украинско-крымскотатарский учебный тематический словарь как объект лингвистического описания [Электронный ресурс].- Режим доступа: https://cyberleninka.ru/article/n/polilingvokulturnyy-fenomen-russko-ukrainsko-krymskotatarskiy-uchebnyy-tematicheskiy-slovar-kak-obekt-lingvisticheskogo-opisaniya (дата обращения: 10.02.2021)
2. Богданович Г.Ю., Новикова Т.Ю., Балашова И.Г., Буц Н.В., Селендили Л.С., Девлетов Р.Р. Шире круг: русско-украинско-крымскотатарский учебный тематический словарь. – Симферополь: Феникс, 2011. – 244 с.
3. Богданович Г.Ю., Новикова Т.Ю., Балашова И.Г., Буц Н.В., Селендили Л.С., Девлетов Р.Р. Речевой этикет: русско-украинско-крымскотатарские соответствия. Учеб. пособие.– Киев: Педагогічна думка, 2012. – 200 с.
4. Меметов И. Периодизация истории развития крымскотатарского литературного языка [Электронный ресурс].- Режим доступа: http://dspace.nbuv.gov.ua/bitstream/handle/123456789/94738/31-Memetov.pdf?sequence=1(дата обращения: 18.01.2021)
5. Мицкевич И.М. План-конспект урока английского языка «Проживание в старом или новом доме» с применением технологии case-study; 10 класс [Электронный ресурс].- Режим доступа: https://pedsovet.su/load/111-1-0-51548 (дата обращения: 18.01.2021)
6. Муртаза А.Ш. Современные методики преподавания английского языка в высших учебных заведениях [Электронный ресурс] // Вестник КазНУ.- Алматы, 2016.- Режим доступа: https://articlekz.com/article/16319) (дата обращения: 12.02.2021)
7. Муртазина Л.Р. О некоторых вопросах преподавания татарского языка в РТ на современном этапе [Электронный ресурс].- Режим доступа: https://cyberleninka.ru/article/n/o-nekotoryh-voprosah-prepodavaniya-tatarskogo-yazyka-v-rt-na-sovremennom-etape
8. Сальникова О.А. Что включает в себя коммуникативная компетенция? [Электронный ресурс].- Режим доступа: http://www.school2100.com/upload/iblock/142/1422ec1747d648de7d80b4516963e8fd.pdf (дата обращения: 10.02.2021)
9. Селендили Л.С. Лексико-семантические и синтморфологические особенности конструктов крымскотатарского предложения (формальный и прикладной аспекты): дис. ... д-р. филол. наук: 10.02.02 –«Языки народов Российской Федерации (урало-алтайские языки)». - г. Симферополь, 2015. – С.110-130. [Электронный ресурс].- Режим доступа: https://iling-ran.ru/theses/selendili_full.pdf (дата обращения: 10.02.2021)

# ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ИНТЕГРАЛЬ АЛЫМНЫҢ РОЛЕ

*Сибгаева Ф.Р.*
*Казан федераль университеты*
*FiruzaRS@mail.ru, ruzilya5@mail.ru*

**Аннотация.** Образование сегодня направлено на формирование интеллектуально развитой личности с целостным гармоничным мировоззрением, с пониманием глубины взаимосвязи явлений и процессов окружающего мира. В свете современных проблем комплексного развития личности учащегося на базе общего среднего образования проблема интеграции и межпредметных отношений приобрела принципиально важное социально-педагогическое значение. Интеграция между учебными предметами не отменяет систему предметов, а, скорее, улучшает ее и позволяет углубить взаимозависимость между различными дисциплинами.

Необходимо выявить особенности и отбор контента при интеграции - интеграция материалов из традиционных, классических предметов и включение в интеграцию материалов нового школьного контента. На пересечении этих подходов могут быть разные результаты: а) появление совершенно новых предметов (курсов); б) разработка новых курсов, обновление содержания в рамках одного или нескольких предметов; В) создание отдельных блоков уроков, объединяющих материал одного или нескольких предметов, существующих параллельно с уроками учебной программы; г) проведение разовых интегративных уроков.
**Ключевые слова:** интеграция, татарский язык, интегративное обучение.

Мәгариф системасын модернизацияләү бурычын тормышка ашыруда мөмкин булган юлларның берсе – традицион укыту чараларын заманча мәгълүмати һәм интеграция алымнары белән берлектә куллану.

Мәгълүмати һәм интеграция алымнарын куллану укучы шәхесен формалаштыру, вариативлык, мәктәп программасын индивидуальләштерүгә ярдәм итә. Шулай ук өйрәнелә торган предметны актив һәм иҗади үзләштерүдә мөһим роль уйный, материалны яңа югарылыкта аңлату, укыту процессын заман таләпләренә туры китереп оештыруда да яңа мөмкинлекләр ача.

Татар теле дәресләрендә интеграль алымны куллану берничә факторга бәйле. Иң элек, балаларның яшь үзенчәлеген исәпкә алырга кирәк. Интеграль дәрес мәктәп курсында традицион булмаган интерактив метод-алымнар куллану буларак та карала.

Дәресләрне интегральләштерүнең төп максаты – укучыларда яңа заман кешесенә хас булган фәнни фикерләү сәләте үстерүгә, дөньяны яңача күзаллауга йогынты ясау. Уку-укытуны интегральләштерү ул – укучыларда предметларны үзара бәйләнештә өйрәнүләре аша дөньяга караш тәрбияләү.

Интегральләштерелгән дәрес – төрле фәннәр буенча белемнәрне берләштерү һәм нинди дә булса проблеманы чишү өчен махсус оештырылган дәрес. Мондый дәресләр укучыларга файдалы. Алган белемнәрне системага салырга мөмкинлек бирә, фәнгә карата кызыксыну уята. Дәрес барышында укучылар белән индивидуаль эшләргә, хаталарны вакытында төзәтергә мөмкинлек туа [11, 29].

Интеграль дәрес структурасы төгәллеге, дәрес материалының эзлеклелеге, предметларның үзара бәйләнеше, мәгълүматлылыгы буенча традицион дәрестән аерылып тора.

Мондый типтагы дәресләрне оештыру өчен укытучы төп максатны билгели, максатка ярашлы материал сайлап ала.

Интеграль дәресләрне оештырганда, түбәндәге формаларны куллану нәтиҗәле: лекция, әңгәмә, конференция, семинар һ.б. Күбесенчә конференция, семинар дәресләр еш үткәрелә. Фәнни-популяр әдәбият белән эшләү, таблиацалар, схемалар төзү укучыларда анализлау, гомумиләштерү, системалаштыру сәләтен үстерә. Дәрес барышында укучылар яңа материалны үзләренең белемнәре белән чагыштыралар, шуңа күрә мондый укыту нәтиҗәле була.

Интегральләштерүне горизонталь, вертикаль төрләргә бүлеп карала. Горизонталь интегральләштерү вакытында мәктәп программасы буенча укытыла торган предметлар интегральләштерелә. Вертикаль интегральләштерү бер предметның төрле елларда өйрәнелгән материалын үз эченә ала [2, 36].

Интегратив алымга нигезләнгән дәрес структурасы түбәндәгедән гыйбарәт:

1. Әзерлек этабы. Укытучы максатны билгели, танып-белү бурычларын, дәресне үткәрү формасын, метод-алымнарны билгели, әдәбият сайлап ала. Укучылар белән әзерлек эшләре үткәрелә. Төркемнәргә бүленә, темалар бирелә. Һәркем бер-ике атна үз темасы өстендә эшли.

Интеграль дәресләрне үткәрүгә әзерлек этабында төрле материал кулланыла. Коллектив укыту методлары зур роль уйный. Группаларда эш укучыны шәхес буларак формалаштыра.Укытучы җыелган материалның эчтәлеген карый, коррекцияли, кирәк дип санаса, терәк конспект әзерләргә тәкъдим итә.

2. Дәресне үткәрү. Укытучы эшне төркемнәрдә оештыра. Төркемнәр бер-бер артлы чыгыш ясыйлар. Материалны фәнни, эзлекле сөйләүгә игътибар ителә. Төп теманы аерып алу, чыгышны эксперимент белән бәйләп алып бару, күрсәтмәлелектән файдалану уңышлы санала. Төркемнәр чыгышында укучылар актив катнаша, һәр укучы чыгышыннан төркемнең эшчәнлеге бәяләнә. Эшне диалог формасында оештырырга мөмкин. Төркемнәрнең эшен сыйныфтан билгеләп куелган бер җитәкче укучы контрольдә тота.

3.Дәресне йомгаклау. Интегральләштерелгән материал гомумиләштерелә. Укучылар ике яки берничә предметтан билге алалар. Җыелган материал тапшырыла [2, 31].

Интеграль дәресләрнең уңышлылыгы төрле шартларга бәйле. Дәресләр расписаниесен җайлау, охшаш темаларның бервакытта үткәрелүе, методик ярдәмлекләрнең аз булуы һәм башка шундый мәсьәләләр интеграль дәресләрне үткәрүдә проблемалар китереп чыгарырга мөмкин. Уку-укыту процессында интегральләштерү төрле формада булырга мөмкин.

Гомуми кагыйдәләр белән таныштыруны беренчел дәрәҗәдәге интегральләштерү дип атарга мөмкин. Төшенчәләр формалаштыру, мәгълүмат алу чараларын берләштерүне шартлы рәвештә икенчел дәрәҗәдә интегралләштерү дип карыйлар.

Өченчел дәрәҗәдә интегральләштерү материалны чагыштырма характерда өйрәнү белән бәйле һәм укучыларда чагыштыра белү, анализлау күнекмәләрен үстерүгә нигезләнгән. Әгәр бу дәресне бер генә укытучы үткәрсә, дәреснең дәвамы буларак, бу дәрестә кузгатылган проблемалар, фактлар анализлана. Шуңа күрә педагогик эшчәнлектәге хаталарны төзәтү өчен укытучыларның бер-берсенең дәресләренә йөрүләре дә мөһим [1, 37б.]

Дүртенчел дәрәҗәдә интегральләштерү укучыларның актив эшчәнлекләрен үз эченә ала. Укучылар мөстәкыйль рәвештә анализлый алалар, үзләренең алган белемнәрен нәтиҗәле файдаланалар. Бу этапта укучыларның фикерләү дәрәҗәсен контрольдә тотарга кирәк, бигрәк тә укытучыга укучыларның фикер йөртүгә ихтыяҗы тууын аңлау мөһим. Эшнең нәтиҗәсен күрү, башкарылган эшнең уңышлы булуы турында сөйли.

Интеграль дәресне бер генә укытучы да үткәрә ала. Икенче предмет укытучысы интеграль дәресләр системасын төзүдә, максат-бурычларны билгеләүдә, дәрес өчен материал туплауда катнаша. Яңа материал өйрәнү дәресләрен генә түгел, белем-күнекмәләрне системалаштыру, кабатлау дәресләрен интеграль итеп үткәрү дә отышлы.

Интеграль дәресләр төрле формада була. Күбесенчә стандарт булмаган дәресләр үткәрелә.

Дәресләрне зачет, иҗади проект яклау формасында үткәрергә була. Интеграль дәресләр ике яки берничә укытучының актив эшчәнлеген тәэмин итә. Укытучыларның роле дәреснең формасына карап үзгәрә. Бер дәресне берничә укытучы алып барырга мөмкин.

Яңа мәгълүмат хәбәр итү дәресләрендә укучылар төркемнәрдә эшлиләр.Һәр укучы үзенең темасы буенча төркем алдында чыгыш ясый.

Иҗади эзләнү дәресләрендә укучылар куелган мөстәкыйль рәвештә проблеманы чишү юлларын эзлиләр. Эзләнү алымнары алдан әзерләнеп куела. Мондый дәресләр уңышлы һәм әһәмиятле: 1) газета яки фәнни альманах чыгару. Укучыларга аерым темаларга эзләнү характерындагы эшләр бүлеп бирелә. Шул эшләрнең нәтиҗәсе буларак газета яки альманах чыгарыла; 2) контроль дәресләр иҗади проектлар яклау яки зачет тибында үткәрелергә мөмкин; 3) зачет-олимпиада, зачет-экзамен зачет-конкурс, зачет-аукцион үткәрү кызыклырак һәм уңышлырак санала.

Интеграль дәресләрне даими оештыру өчен фәннәрне интегральләштерүнең билгеле бер системасын булдырырга кирәк. Предметлар

буенча уку планнарын килешенеп төзү, гомуми төшенчәләрне, охшаш темаларны аерып алу, аларны өйрәнүнең бер вакытын билгеләү, бергәләп консультацияләр үткәрү һ.б. Аннан соң интеграль дәресләрнең планын, конспектын төзү.

Татар телен татар әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты, чит тел, тарих, география, музыка һ.б. фәннәр белән интегральләштерергә мөмкин.

Инглиз теле белән татар теле һәм әдәбиятын интегральләштерү психологик, педагогик һәм эстетик яктан да үзен аклый. Чит ил әдәбияты, культурасы, гореф-гадәтләре укытучы өчен дә, укучы өчен дә бай материал тупларга мөмкинлек бирә, башка халыкларның мәдәниятына, теленә, гореф-гадәтләренә хөрмәт тәрбияли. Чит ил мәдәнияте бөтендөнья мәдәниятенең бер өлешен тәшкил итә.

Татар теле дәресләрендә татар язучыларының әсәрләреннән файдалану, шигырьләрне сәнгатьле уку; грамматик категорияләрне кабатлаганда мәкаль-әйтемнәрне, табышмакларны, җырларны файдаланырга була. Татар теле белән рус телен, татар әдәбияты белән рус әдәбиятын интегральләштерү күп мәсьәләләрне хәл итәргә мөмкинлек бирә.

Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына, рус балаларына татар телен өйрәтүдә мондый дәресләр алыштыргысыз, чөнки грамматик категорияләрне чагыштырма характерда аңлату укучыларның материалны җиңел үзләштерүенә китерә. Язучыларның биографиясен, әдәби әсәрләрне өйрәнү дәресләрендә темасы, стиле буенча туры килгән әсәрләрне татар һәм рус телләрендә чагыштырып өйрәнү дәресләрне нәтиҗәле, кызыклы үтүен тәэмин итә.

## Әдәбият

1. Камаева Р.Б. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә яңа педагогик алымнар. – Алабуга: АИ КФУ нәшрияты, 2012. – Б. 136.

2. Пассов Е.И. Коммуникативный метод обучения иноязычному говорению: Пособие для учителей иностранных языков. – М.: Просвещение, 1985. – С. 208.

3. Сафиуллина Ф.С. Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан, 2001. – 424 б.

4. Чегвинарцева О. Дәресләрдә яңа педагогик технологияләрне куллану // Мәгариф. – 2007. – № 11. – Б. 21-24.

# МЕТРИЧЕСКИЕ ЗАПИСИ XIX – НАЧАЛА XX ВВ. О ТОБОЛЬСКИХ БУХАРЦАХ КАК ИСТОРИКО-ЛИНГВИСТИЧЕСКИЙ ИСТОЧНИК

Исследование выполнено при финансовой поддержке РФФИ в рамках научного проекта № 20-412-720008 р_а_Тюменская область.

Файзуллина Г.Ч.
Тобольский педагогический институт им. Д.И. Менделеева (филиал) ТюмГУ
utgus@mail.ru

**Аннотация.** В статье рассматриваются неопубликованные и неисследованные документы архивных фондов мечетей Тобольской губернии, хранящиеся в Государственном архиве г. Тобольска.
**Ключевые слова:** метрические записи, тобольские бухарцы, историко-лингвистический анализ, источник

Одна из стратегических задач государства – сохранение и развитие языков народов Российской Федерации, так как в настоящее время многие языки находятся на грани исчезновения. К таким языкам, по данным ЮНЕСКО, относится и язык коренного тюркского народа Западной Сибири – сибирских татар. В настоящее время лингвистическая наука обладает достаточно широкими и разноплановыми сведениями о диалектных особенностях устной речи сибирских татар. В то же время многие памятники письменной речи, хранящиеся в архивных фондах, до сих остаются неизученными. Объект исследования – рукописные метрические книги «на записку родившихся, о браках, разводах и смерти» Тобольского уезда Тобольской губернии XIX – начала XX вв. Хронологические рамки исследования – 30-е годы XIX – начало XX вв. Необходимо отметить, что анализ метрических книг позволит не только расширить и актуализировать лингвистические данные для целостного представления о развитии языка сибирских татар (становление речевых и языковых норм, как устных, так и письменных, особенности диалектного произношения и др.), но и рассмотреть факты влияния языка бухарцев на становления языка сибирских татар.

Материалом научной работы являются неопубликованные и неисследованные документы архивных фондов мечетей Тобольской губернии, хранящиеся в Государственном архиве г. Тобольска. В архиве содержатся фонды 32 мечетей разных населенных пунктов (юрт) Тобольской губернии, общей численностью 489 единиц хранения, при этом одно дело может достигать до 600 страниц рукописного текста.

В Государственном архиве Тобольска хранятся метрические записи, охватывающие период с 1830 по 1917 гг. и содержащие сведения по следующим юртам, в которых проживали бухарцы: Аремзянские (Ф.И639), Байгаринские (Ф.И645), Вагайские (Ф.И647), Вершинские (Агитские) (Ф.И511), Вершинские (Ф.И632), Епанчинские (Ф.И643), Иртышские (Ф.И644), Исеневские (Ф.И638), Иштамакские (Ф.И520), Казылбаевские (Ф.И646), Комаровские (Ф.И641), Кульмаметские (Ф.И649), Лайминские (Ф.И510),

Медянские (Ф.И640), Митькинские (Ф.И518), Салинские (Ф.И650), Саусканские (Ф.И635), Супринские (Ф.И648), Тоболтуринские (Ф.И513), Чебургинские (Ф.И514, Ф.И633).

Зачастую бухарцы поселялись в одних селениях с другими этническими группами Сибири. Так, уже во второй половине XIX в. в Тобольском округе совместно с ясачными и служилыми татарами выходцы из Средней Азии проживали в сорока семи населённых пунктах. В редких случаях бухарцы создавали и собственные монопоселения. К таковым относят селения в округе города Тобольска, именуемые юрты Комаровские (Комарау) и Ми/еримовские (Коллар).

Основной объем сохранившихся книг относится к периоду с 1831 года по 1862 год (этим годом датируется наибольшее количество сохранившихся страниц). Необходимо отметить, что внешнее качество рукописей отнюдь не зависит от продолжительности хранения, а является следствием условий хранения. Период с 1863 года по 1917 год характеризуется значительным снижением объема сохранившихся рукописей. Более того, сведения за 17 из 55 лет отсутствуют, а именно утрачена информация за 1863-1864, 1866-1869, 1874-1878, 1880, 1892, 1900, 1903, 1907, 1909 гг.

Отметим только несколько особенностей, характерных для сибирских рукописей.

Ныне в, ф, җ, һ, х в тоболо-иртышском диалекте субституируются согласными, близкими им по артикуляции или месту образования, или совсем не произносятся. С другой стороны, в некоторых говорах, например, заболотном, отчасти тевризском, появляются согласные х, ф как позиционно-комбинаторные варианты фонем *қ (ғ)* и *б* [Тумашева, 1977, с. 53]. В метрических книгах в написании имен девушек с компонентом *бикә* наблюдается вариативность *б / ф / п*: نیازفیكه *Нийазфикә* ‘Ниязбика’, نیازبیكه *Нийазбикә* ‘Ниязбика’; هاروپیكه *Һарупикә* ‘Харубика’.

В рукописях в начале слова встречается *соответствие й~җ*: *Кыз тарафыдин **йизнәсе*** یزناسی *Әхмәд Хуҗа углы вәли вәкил булды* ‘Со стороны невесты доверенным был зять Ахмад сын Хужа’; یانسلطان *Йансолтан* ‘Жансолтан’, یانباقی *Йанбакый* ‘Жанбакый’.

Сохранение согласного [*ғ*] в середине и в конце слов наблюдается в лексемах *туғ-, уғыл,* т.е. дается традиционное написание: *Тубыл губернасы, шулук өйәзе, Күкрәнде илендә **тугды**; кыз* اوغلان ***углан*** ‘дочь, девочка’, *ир* اوغلان ***углан*** ‘сын, мальчик’, *Шул ук өйәз Кундан иленең Исхак Нийаз* اوغلی نا ***углына.***

Традиционная архаичная форма [г] вместо [w] современного татарского литературного языка встречается в написании слова *агырыклык* (авыру) ‘болезнь’: *баш **агырыклыгы*** آغریقلغی ‘головная болезнь’.

Книги «на записку родившихся» содержат следующие данные о новорожденном:

1) пол и имя: *ир углан Мөхәммәдша* ‘ребенок мужского пола (досл. мужчина ребенок) Мухаммедша’, *кыз углан Ханифә* ‘ребенок женского пола (досл. девочка ребенок) Ханифа’;

2) дата рождения: *гыйнварның 21 нче йәүмендә* ‘двадцать первого дня января’, *фивральнең 5 нче йәүмендә* ‘пятого дня февраля’, *априлнең 9 нчы йәүмендә* ‘девятого дня апреля’, *нуябернең 10 нче йәүмендә* ‘десятого дня ноября’. Названия некоторых месяцев имеют вариативное написание *аугуст* / *афгуст* ‘август’, *үктәбер* / *үкдәбер* ‘октябрь’, *дикәбер* / *тикәбер* ‘декабрь’. Необходимо отметить, что в книгах Чебургинских юрт используется только арабский вариант *йәүмендә* ‘дня’, а, например, в Саусканских – оба варианта *йәүмендә* и *көнендә* ‘дня’;

3) данные об отце: *атасы йасаклы Халид* ‘отец его ясачный Халид’, *атасы сарт Габдевәли* ‘отец его сарт Габдевали’, *атасы казак Ишмөхәммәд* ‘отец его казак Ишмухаммед’. В книгах о рожденных и «для записки сочетания браков и разводов» содержатся сведения о социальном статусе и этнической принадлежности. В XIX – начале XX вв. наблюдается неоднородность в этническом плане: *атасы йасаклы Халид* ‘отец его ясачный Халид’, *атасы йасаклы Габденасыйр* ‘отец его Габделнасыр’, *казак Моратбакый* ‘казак Муратбаки’, *астабунай* (< рус. *отставной*) *казак Әлмөхәммәд* ‘отставной казах Альмухаммед’ или *осдабуяб* (< рус. *отставной*) *казак Корбанбакый* ‘отставной казак Курбанбаки’, *сарт Габделказый* ‘сарт (бухарец) Габделкази’ или *сәртия Мөхәммәдеррәхим* ‘сарт (бухарец) Мухаммедеррахим’, *имам әлмөслимин Гомәр* ‘мусульманский священнослужитель Гумер’, *указной мулла Гомәр Кызылбай углы* ‘указной мулла Гумер сын Кызылбая’;

4) данные о матери: *анасы Мафирүзә* ‘мать его Мафируза’, *анасы Рабига* ‘мать его Рабига’, *анасы Мәстүрә* ‘мать его Мастура’;

5) место рождения: *Тубыл губернасы шулук өйәз Күкрәнде илендә тугды* ‘родился в деревне Кукранде (Чебургинские) того же уезда Тобольской губернии’, *Тубыл губернасы шулук өйәз Кундан карьядә тугды* ‘родился в деревне Кондан (Конданские) того же уезда Тобольской губернии’. Лексемы *ил, авыл, карья* ‘деревня’ выступают синонимами: *аул* ‘деревня’ [Гиганов, 1804, с. 121], *ил, авул* ‘село’ [Гиганов, 1804, с. 534], лексема «*карья* ‘деревня, селение’ (< араб. *қарӣā*) активно использовалась в прежнем татарском литературном языке. При этом лексемы *ил* (семантический диалектизм *ил* ‘деревня’ и *карья* используются в записях Чебургинской мечети. Следовательно, в данном случае в записях Чебургинских юрт зафиксированы синонимы, относящиеся к территориально ограниченным и устаревшим.

Книги «на записку о браках» содержат следующую информацию:

1) данные о сочетающихся браком: *Тубыл өйәзе Игәй авылының сарт Аллайар Исәнйар углының кызы Мәрйәмне шул ук авылның сарт Очкуртгә Сөендек углыга никах укылды* ‘Дочери сарта Аллаяра сына Исаняра Марьям из деревни Игеевские Тобольского уезда сыну Суендека сарту Очкурту из той же деревни читали никах’;

2) дата: *майның 11 нче йәүмендә* ‘11 дня мая’, *ийүлнең 9 нчы көнендә* ‘9 дня июля’, *априлнең 10 нчы йәүмендә* ‘10 дня апреля’;

3) доверенные от невесты и жениха: *Кыз тарафындан иткәсе Садыйк Осда углы вәли вәкил булды вә кияү тарафындан Уразбакый Кылау углы вәли*

*вәкил булды, зәүҗәеннең ризалыгының шаһидләре шул ук илнең Мөхәммәд Көчүк углы әлимса кылдым. Бугай Әмрат углы әлимсам кылдым* ‘Со стороны невесты доверенным был отец Садык сын Осды и со стороны жениха доверенным был Уразбаки сын Кылау, согласие супругов я, их шахит Мухаммед сын Кучука, скрепил подписью. Я, Бугай сын Амрата, поставил подпись’;

4) сумма денег, которую передает жених родителям невесты: *Мәһәре мөсәммә йөз илле сум барчасын үтәмәклүкүм өчүн кияү Исхак Нийаз углы әлимса кылдум вә һәм мәзкүрә кызым Мәликә өчен вәли вәкил иткәсе Садыйк Осда углы әлимза кылдым* ‘За передачу денег в размере 150 рублей жених Исхак сын Нияза ставлю подпись и за вышеназванную мою дочь Малику доверенный отец Садык сын Осды ставлю подпись’;

5) имя муллы, заключившего брак: *Тубыл губернасы шул ук өйәз Күкрәнде иленең мәншүрле мәхәллә имамы мулла Зөлкарнәин Нийаз углы никах хөтбәсен укудукыма әлимза кылдым* ‘В подтверждение прочтения мной никаха поставил подпись имам Зулькарнай сын Нияза из деревни Чебурга Тобольской губернии того же уезда’.

В метрических книгах «на записку о смерти» приводятся следующие данные об умершем:

1) половозрастной статус и личное имя: *ир Шаһмирза* ‘мужчина Шахмирза’, *хатун Мәхфүзә* ‘женщина Махфуза’, *ир углан Йәдегәр* ‘мужчина ребенок Ядегар’, *кыз углан Зәлҗамал* ‘девочка ребенок Залджамал’;

2) дата смерти: *мартның 7 нче йәүмендә* ‘седьмого дня марта’, *үктәбернең 7 нче йәүмендә* ‘седьмого дня октября’, *нуйәбернең 9 нче йәүмендә* ‘девятого дня ноября’;

3) возраст: *6 йәшендә* ‘в 6 лет’, *алтмыш йәшендә* ‘в шестьдесят лет’, *йите айлык* ‘семимесячная’, *ике ай ун көндә* ‘в два месяца десять дней’, *бер ай үтәсе көндә* ‘месячный’;

4) причина смерти: указывается, при каких условиях наступил летальный исход (*дәрьяда һәлак булып* ‘в воде умерши’, *углан зәхмәте* (досл. болезнь ребенком) ‘при родах’) или название заболевания (*чикутка зәхмәте* ‘чахотка’);

5) место смерти: *Тобол губернасы шул ук өйәзе Ләчек илендә дәфен булды* ‘погребение состоялось в деревне Тахтагул Тобольской губернии того же уезда’, *Тубыл өйәзе Аригкүл авылында дәфен улынды* ‘погребение состоялось в деревне Аригкул Тобольского уезда’. Лексема *дәфен* арабского происхождения – *дӓфн*.

Таким образом, исследование мусульманских метрических (мечетных) книги в лингвокультурологическом аспекте позволит дать более полную историко-культурную характеристику сибирских бухарцев как этносословной группы и расширит научные представления о культуре и истории Западной Сибири в целом.

# ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ
# УКУЧЫЛАРНЫҢ ТЕЛ БАЙЛЫГЫН ҮСТЕРҮ

Фаттахова Р. Ф., Шәмсетдинова Р.Р.
ГАОУ ДПО «Институт развития образования РТ»
faruzilya@mail.ru, tnd@rambler.ru

**Аннотация.** В работе освещается проблема развития лексического запаса учащихся при обучении татарскому языку как неродному с применением коммуникативных технологий. На уроках выполняются виды работ, которые должны быть направлены на формирование устной речи и совершенствование речевой культуры учащихся: работа по тексту, составление диалогов, коммуникативные игры, ситуативные задания.
**Ключевые слова:** национальное образование, коммуникативный подход, устная речь, словарный запас, лексические единицы, речевая деятельность, текст, диалог, игра, ситуативные задания.

Мәгариф системасы озак еллар традицион укыту методикасына нигезләнде. Бүгенге көндә һәр укытучы үзенең дәресләрен кызыклы, нәтиҗәле итеп оештырырга, укучыларны үз дәресе белән кызыксындырырга, һәр укучыга уңыш ситуациясе булдырырга тырыша. Милли мәгариф өлкәсендә рус төркемнәрендә татар телен укыту актуаль мәсьәлә булып тора. Бертуктаусыз татар теленең грамматик кагыйдәләрен өйрәнүгә, грамматик күнегүләр эшләүгә корылган дәресләр заман таләбенә җавап бирми. Рус төркемнәрендә татар теле дәресләрен үткәрүдә традицион бертөрлелектән арынып, коммуникатив технологияләрне куллануга таба борылыш ясау ихтыяҗы барлыкка килде. Бу максатта укытучыларны коммуникатив укыту методикасы белән коралландыру, аларның квалификацияләрен күтәрү системасын камилләштерү, шулай ук коммуникатив характердагы укыту-методик әсбаплар чыгару отышлы чаралар булып күзаллана. [1, 198 б.]

Телгә өйрәтүдә коммуникатив технологияне куллану тарафдарлары грамматиканы начар белүгә караганда сүз запасының ярлылыгы телне белү дәрәҗәсенә җитдирәк йогынты ясый дигән фикердә торалар. Сүзлек запасы кешенең телне ни дәрәҗәдә яхшы белүе күрсәткечләренең берсе булып тора. Тел байлыгы кешегә үзенең фикерләрен төгәлрәк җиткерергә ярдәм итә. (И. Я. Лернер, М. Н. Скаткин, Ю. К. Бабанский, М. И. Махмутов, Е.И. Пассов, М. Л. Вайсбурд, П. Я. Гальперин, А. Р. Лурия, И. А. Зимняя, Китайгородская һ.б.).

Кешенең туган теленең уртача сүзлек запасы 50 мең дип исәпләнә. Әгәр кеше сыйфатлы югары белем алса, бу күрсәткеч 30-40% ка артырга мөмкин.

Кеше телне чит тел буларак үзләштергәндә, төрле мәнфәгатьләрдән чыгып, сүзлек запасы төрлечә формалаша: көндәлек аралашу өчен 2,5 мең сүз белү кирәк; актив аралашу, газета һәм әдәбиятны укып, яңалыкларны карап аңлау

өчен, ким дигәндә 5 мең сүз белү зарур; сигез меңнән артык сүз белү чит телдә ирекле аралашу мөмкинлеген бирә.

Коммуникатив технологиягә нигезләнеп татар теленә өйрәтү укучыларның бу телдә тиешле дәрәҗәдә сүз запасы барлыкка килүен, сөйләмне ишетеп аңларга өйрәнүләрен, иркен аралашуларын тәэмин итәчәк.

Мәкаләнең максаты - гомуми белем бирү оешмаларының рус төркемнәрендә укучыларның татар теленнән тел байлыгын арттыру эшчәнлеген коммуникатив технологияләр нигезендә күрсәтү.

Телгә өйрәтү 4 бурычны

- укырга
- язарга
- сөйләшергә
- сөйләмне ишетеп аңларга өйрәтүне күз алдында тота. [2, 112 б.] Татар телен коммуникатив технологияләр нигезендә өйрәткәндә әйтелгән бурычларны үтәүгә юнәлдерегән түбәндәге күнегүләр башкарыла:
- текст буенча эш;
- диалоглар төзү;
- коммуникатив уеннар;
- ситуатив биремнәр.

Текст белән эшләүне оештыруда төп шартларның берсе - дөрес текст сайлау. Уңышлы тәкъдим ителгән текст укучыларның тел эшчәнлеген максималь рәвештә стимуллаштыра һәм аларны белем алу эшчәнлегенә этәрә. Текст аңлаешлы, актуаль, яңа, кызыклы мәгълүматка ия булырга, укучыларның белем дәрәҗәсенә һәм кызыксыну сфераларына туры килергә тиеш. [2, 111 б.] Текстта укучыларга таныш сүзләр, фразалар белән бергә үзләштерү өчен яңа лексик берәмлекләрнең дә булуы зарур. Текст буенча эш текст уку, текст буенча сорауларга җавап бирү, текст буенча сораулар төзү, эчтәлек сөйләү, төп теманы билгеләү, план төзү, конспектлаштыру, аннотация язу, анализлау һ.б. биремнәрне үз эченә ала. Тексттан соңгы этапта текст буенча диалогик һәм монологик сөйләм оештырыла. Текстта очраган яңа сүзләр белән сүзлек эше, аларны сөйләмдә активлаштыру күнегүләре башкарыла.

Дәрестә оештырылган диалогик сөйләм барышында вакытында ике укучы арасында мәгълүмат тапшырыла. Диалогта катнашучылар бер-берсенә чиратлап сорау/җавап, раслау/инкяр итү, шик белдерү, ышанмау, риза булу/риза булмау, үтенү, киңәш бирү формаларында репликалар әйтәләр, шулар аркылы татар теленең аерым грамматик формаларын өйрәнү, сүзлек запасын тулыландыру, дөрес әйтелеш нормаларын үзләштерү тормышка ашырыла. Укучыларны диалогик сөйләмгә өйрәтү күнегүләре күптөрлелеге һәм кызыклы булуы белән аерылып тора. Алар укучыларга белемнәрен кабатларга, аларның интеллектуаль фикерләвен, коммуникатив сәләтен үстерергә ярдәм итә. Әлеге төр сөйләмгә караган күнегүләргә түбәндәге мисалларны китереп була: диалогны башлау; диалогны тулыландыру; диалогны дәвам итү; диалогны тәмамлау; билгеле бер ситуациягә караган диалог төзү; үрнәк буенча диалоглар төзү; билгеле тема буенча диалог төзү; диалоглардагы хаталарны табу;

монологны диалогка үзгәртү; диалогны монолог итеп язу; рәсем, картина буенча диалог төзү; схема буенча диалог төзү.

Укучылар диалог төзегәндә, алган белемнәрен ныгыталар, мәгълүмат туплыйлар, лексик берәмлекләрнең иң кирәклесен сайлап алалар, грамматик формаларны дөрес кулланырга өйрәнәләр, гомумиләштереп нәтиҗәләр ясыйлар. Әлеге төр эшчәнлек вакытында балаларның интеллектуаль фикерләү һәм коммуникатив осталыклары үсеш ала. [4, 421 б.] Диалог аша укучылар татар сөйләм этикеты үрнәкләрен, тотрыклы сөйләм гыйбарәләрен, төрле репликаларны актив үзләштерәләр. Уку аралашуы көндәлек аралашуга китерсен өчен, балаларның үз фикерләрен төгәл һәм дөрес итеп белдерергә өйрәтү зарур.

Уен укучыга эмоциональ яктан йогынты ясый, телне өйрәнү өчен мотивацияләү чарасы булып тора, шәхеснең фикерләү, танып-белү аралашу мөмкинлекләрен активлаштыра. Уен белемнәрне, күнекмәләрне һәм төрле сәләтләрне ныгытырга, контрольдә тотарга һәм төзәтергә ярдәм итә, конкрет материалны өйрәнүдә уку күрсәтмәлелеген тәэмин итә. Уен укучыларның интеллектуаль эшчәнлеген стимуллаштыра, кабул ителгән карарларның дөреслеген тикшерергә өйрәтә. Уен тулы фразаларны, җөмләләрне истә калдырырга ярдәм итә. Уенның психологик тәэсире татар телендә сөйләшү (аралашу) барьерын җиңүдә күренә. Кызыксыну һәм шатлык атмосферасы, биремнәрнең мавыктыргыч булуы - болар барысы да балаларга татар сүзләрен ирекле кулланырга комачаулый торган оялчанлыкны җиңәргә мөмкинлек бирә һәм белем бирү нәтиҗәләренә уңай йогынты ясый.

Уеннар уку максатлары һәм бурычлары, үткәрү формасы, оештыру ысулы, катлаулылык дәрәҗәсе, катнашучыларның саны белән характерлана ала. Уеннарда катнашучыларның саны буенча индивидуаль (бер кеше өчен) һәм парлы, төркемле, коллектив уеннарга бүленә. Уеннарны оештыру ысуллары буенча компьютер, имитация-модельләштерү, язма, телдән, хәрәкәтле һәм башкалар; башкарыла торган гамәлләрнең катлаулылыгы буенча гади һәм катлаулы төрләргә аерып карала. Үткәрү характеры һәм формасы буенча вербаль, хәрәкәтчән, сюжетлы, интеллектуаль (ребуслар, кроссвордлар, чайнвордлар, башваткычлар һ.б.), үзара аралашу (коммуникатив) һәм рольле уеннар, эшлекле уеннар аерылып чыга.

Уеннар өйрәтүнең максатлары һәм бурычлары буенча *телгә өйрәтү* (яки аспектлы) һәм *сөйләмгә өйрәтү* төрләренә бүленәләр. Тел уеннары, телнең төрле аспектларын (фонетика, лексика, грамматика) үзләштерергә ярдәм итәләр, фонетик, лексик һәм грамматик уеннар була. Тел уеннарын тел аспектына бәйле рәвештә бүлү шартлы күренеш, чөнки лексиканы фонетикасыз, грамматикасыз өйрәнү мөмкин түгел.

Коммуникатив технологиядә лексик уеннар укучыларның игътибарын лексик материалга юнәлтүгә һәм сүзлек запасын киңәйтүгә хезмәт итә, аралашу ситуацияләрендә сүзләрне дөрес, урынлы куллануны тәэмин итә. Мәсәлән, шарадалар, ребуслар, кроссвордлар, сканвордлар чишү автомат рәвештә яңа сүзләрне һәм аларның мәгънәләрен искә төшерергә ярдәм итә.

Ситуатив уен берничә этаптан тора: өйдә яки сыйныфта аңа әзерләнү, сыйныфта уенны оештыру, йомгаклау. Уенны оештырганда, укытучы берничә алшартны истә тотарга тиеш:

1) укучыларның коммуникатив эшчәнлеген активлаштыру, аралашу ихтыяҗы булдыру;

2) сөйләм эшчәнлегенең дәрәҗәсен истә тотып, балаларга рольләрне дөрес бүлеп бирү, укучыларның мөмкинлекләренә игътибар итү, ситуатив уеннарда барлык укучыларны да катнаштыру мәҗбүри;

3) укучының кәефен тоемлап, уңай нәтиҗәгә ирешүгә омтылу;

4) укучыларга яхшы таныш булган ситуацияләрне куллану;

5) үзара ярдәмләшү, телдән актив аралашу мохите булдыру, психологик комфорт халәте тудыру.

Ситуатив уеннар шактый зур яңа лексиканы тиз һәм продуктив хәтерләүгә ярдәм итә, балаларны конкрет ситуациядә әлеге лексиканы кулланырга өйрәтә. Мәсәлән, урта сыйныф укучылары өчен "Туган көн" проекты отышлы булачак. Балалар үзләренең туган көннәренә чакырулар язалар, нинди бүләк алырга теләүләре, бәйрәм менюсы турында теләкләр әйтәләр. Бәйрәм импровизацияләнгән чәй табыны артында сюжетлы-рольле уен рәвешендә уздырыла. Уенда катнашучыларның бер-берсеннән яшерен рәвештә алдан әзерләнгән бүләкләрен тапшыру күңелле сюрприз булып торачак. Шигырьләр, җырлар, күңелле котлаулар бәйрәм атмосферасын тагын да арттырачак.

Сөйләм ситуациясен оештырганда, сюжетлы рәсемнәрдән, мультфильмнар, фильмнардан алынган өзекләрдән файдалану яхшы нәтиҗәләр бирә. Мәсәлән, картина тәкъдим ителә, шул картина сюжетыннан чыгып, ситуатив уен оештырыла. Укучылар кызыксынып карый торган мультфильмнар, кинофильмнар тавышсыз гына күрсәтелә, аннан соң аларны “яңгырату” (озвучивание) эше оештырыла.

Ситуатив уеннарның тәрбияви әһәмияте дә зур: укучыларда игътибарлылык, ярдәмчеллек, үз-үзләренә ышанучанлык, үз уңышларына шатлану хисләре тәрбияләнә.

Рус телле укучыларда телдән сөйләм күнекмләрен үстерү системалы рәвештә алып барыла: даими лексик эшчәнлек, өйрәнелә торган материалны күп тапкырлар кабатлау, сүзлек эше, аралашу күнегүләре. Дәрестән тыш вакытта укучыларны социаль челтәрләрдә татар телендә аралашырга, татарча интернет-ресурслар кулланырга күнектерү, татарча үткәрелгән мәдәни, фәнни, спорт чараларына катнаштыру шулай ук нәтиҗәле булачак.

**Әдәбият**

1. Фаттахова Р.Ф. Рус төркемнәрендә татар телен укытуда коммуникатив технологияне куллану // Сборник материалов Международной НПК “Правовые основы функционирования государственных и региональных языков в условиях дву- и многоязычия. 11 декабря 2019 г. – Казань, 2019. – С. 198-200.

2. Фаттахова Р.Ф. Урок систематизации и обобщения знаний // Фәнни Татарстан. 2019. № 1. – С. 109-114.

3. Фаттахова Р.Ф. Пратический татарский язык. Методическое пособие для изучающих татарский язык. Издание второе, дополненное // Казань: Татарское книжное издательстово, 2012. – 176 с.
4. Шамсутдинова Р.Р., Фаттахова Р.Ф. Развитие творческих способностей учащихся на уроках татарской литературы // IV Андреевские чтения: современные концепции и технологии творческого саморазвития личности. Сборник статей участников Всероссийской научно-практической конференции с международным участием. 2019. – С. 419-422.
5. Шамсутдинова Р.Р. Татарский язык за 20 уроков // Казань: Магариф, 2001. – 98 с.

# ТЕЛЛӘРНЕ ЗАМАНЧА УКЫТЫЙК

Фәтхуллова К.С., Мөгътәсимова Г.Р.
Казан федераль университеты
kadria.kgu@mail.ru, gulnaz-72@mail.ru

**Аннотация.** В статье рассматриваются современные педагогические технологии, широко используемые в области языкового образования, в том числе при обучении татарскому языку. Среди них наиболее привлекательными считаются информапционно-коммуникационные, дистанционные, игровые технологии, а также технологии модульного, проблемного, интегрированного обучения, кейс-технология и проектная технология. Использование их способствует развитию коммуникативной компетенции студентов, которая понимается как способность порождать высказывание на изучаемом языке.
**Ключевые слова:** языковое образование, татарский язык; традиционная методика, современные технологии, коммуникативная компетенция.

Хәзерге шартларда татар теле укытучылары ия булырга тиешле методик компетенцияләр түбәндәгеләрдән гыйбарәт: «укытучы-укучы» системасы белән идарә итә белү; дәресне үткәрүгә методик үзгәрешләр кертү; шәхескә юнәлтелгән педагогик технологияләрдән файдалана белү; укучыларга мөстәкыйль белем алу өчен шартлар булдыру; импровизациягә сәләтле булу; белем бирүнең сыйфатын яхшырту һәм эшнең нәтиҗәлелегенә ирешү.

Методик хезмәтләрдә әйтелгәнчә, педагогик технология – укытучының эшчәнлеге белән бәйле һәм белем бирү максатларына ирешүгә юнәлтелгән билгеле бер эшләр бердәмлеге ул [1, 12]. Шуңа күрә дә заманча технологияләр белем бирүне уңышлы оештыру, максат-бурычларны, белемнәрне үзләштерү һәм коммуникатив күнекмәләр булдыру нәтиҗәләрен, дәресләрдә төрле алымнарны гамәлгә ашыруны үз эченә ала. Хәзерге вакытта телләргә өйрәтү өлкәсендә киң кулланыла торган технологияләргә түбәндәгеләрне кертеп карыйлар: мәгълүмати-коммуникацион технологияләр, проектлар технологиясе; проблемалы укыту технологиясе; уен технологиясе; үстерелешле укыту технологиясе; интегратив укыту технологиясе; модульләп укыту технологиясе; дистанцион беле бирү технологиясе; кейс технологиясе, интенсив укыту технологиясе һ.б. Бүгенге көн укучыларына татар теленнән сыйфатлы белем бирү өчен, әлеге технологияләрне системалы һәм урынлы файдалану мөһим. Заманча технологияләрне куллану укытучыга түбәндәге максатларга ирешү мөмкинлекләре тудыра:1) балаларда татар телен өйрәнүгә даими кызыксыну булдыру; 2) укучыларның танып белү эшчәнлеген активлаштыру; 3) укучыларның иҗади мөмкинлекләрен ачып бирү һәм иҗади үсешен тәэмин итү; 4) укучыларга җитәрлек мәгълүмат бирү; 5) уку материалын аңлаешлырак итеп җиткерү; 6) белемнәрне системага салу һәм гомумиләштереп күрсәтү; 7) үзлектән белем алу мөмкинлекләрен киңәйтү; 8) укучыларда эзләнү-тикшеренү эшләре алып бару теләге уяту; 9) предметара бәйләнеш булдыру.

Татар теле дәресләрендә укытучылар тарафыннан кулланыла торган заманча технологияләрнең кайберләренә тукталып һәм аңлатмалар биреп үтик.

Алда әйтелгәннәр арасында мәгълүмати технологияләр аерым урын алып тора, чөнки Интернет ресурсларыннан тыш телләргә өйрәтүне күз алдына китерү мөмкин түгел. Алар ярдәмендә уку-укытуга индивидуаль якын килү мөмкинлекләре арта, шул ук вакытта телгә өйрәтүне интенсивлаштыруга да юл ачыла. Төрле аралашу ситуацияләреннән чыгып, укучылар Интернеттан өстәмә мәгълүмат таба һәм хәбәрләмә булдыруда аннан файдалана ала.

Яңа технологияләр арасында методистлар икенче урынга телләрне дистанцион рәвештә укыту системаларын куялар һәм аларны башкача электрон укыту платформасы дип атыйлар, чөнки анда онлайн-курслар урын ала. Дистанцион курслар эчтәлеге, максатлары, күләме буенча аерылырга мөмкин, ләкин алар мәгълүматны төрле яклап җиткерергә ярдәм итә. Аларда барлык төр материаллар бирьюлы бирелә: видеосюжетлар, текстлар, график мәгълүмат, анимация һәм телдән сөйләм [4, 315]. Моның белән беррәттән укучы үзе теләгән вакытта кирәкле курстан актив рәвештә файдалана ала.

Проект технологиясе уку мәсьәләсен чишүгә юнәлтелгән гамәли характердагы иҗади биремнәрне үз эченә ала. Аның төп максаты – укучыларда кызыксыну уяту һәм аерым бер темага багышланган проект эше аша белемнәрне реаль аралашуда кулланырга өйрәтү. Проект эшен башкару барышында укучылар иҗади мөмкинлекләрен ачып бирү, мөстәкыйль рәвештә фикер йөртү, үзара хезмәттәшлек итү кебек күнекмәләргә ия булалар.

Проблемалы укыту технологиясенә килгәндә, аның төп эчтәлеге укытучы җитәкчелегендә укучыларның мөстәкыйль эзләнү эшчәнлеген оештырудан гыйбарәт. Элеге эшчәнлек нәтиҗәсендә аларның шәхси сыйфатлары, телне гамәли куллану мөмкинлекләре, мәсьәләне билгели һәм аны чишү юлларын эзләп табу күнекмәләре үсеш ала.

Белем бирүнең барлык баскычларында да киң кулланыла торган уен технологияләренең дә әһәмияте зур, чөнки алар укыту максатларына ирешергә юл ача: укучыларның танып белү һәм фикер йөртү эшчәнлеген активлаштыра; тел берәмлекләрен истә калдыру мөмкинлекләрен арттыра; укучыларга дифференциаль якын килүне тәэмин итә. Педагогик процесска бәйле рәвештә уеннарны түбәндәге төркемчәләргә бүлеп карыйлар: өйрәтү уеннары; тренинг үткәрү уеннары; тикшерү уеннары; гомумиләштерү уеннары һәм иҗади уеннар. Куллану ысулыннан чыгып, аларның берничә төрен билгелиләр: сюжетлы, рольле, эшлекле, имитацион уеннар.

Уку барышында конкрет бер ситуацияне анализлауга багышланган ысулны кейс технологиясе дип атыйлар. Ул укучыларда социаль активлык, аралашу осталыгы, эшлекле әңгәмәдә үз фикереңне белдерә белү кебек кирәкле сыйфатлар булдырырга ярдәм итә. Укытучы, әлеге технологияне кулланганда, укучыларны индивидуаль рәвештә дә, төркемдә дә кирәкле мәгълүматны анализларга, төп проблемаларны билгеләргә һәм аларны күмәк рәвештә хәл итәргә өйрәтә. Әлеге технология укучыларда интерактив күнекмәләр, үзара

теләктәшлек күрсәтү, уртак карар кабул итә белү, алган белемнәрне эшкә җигү кебек мөһим сыйфатлар булдыруга китерә.

Модульле укыту технологиясенең төп максаты: укучыларны үз эшләрен дөрес планлаштырырга, төрле чыганаклардан файдаланырга, чагыштыру, анализлау, системалаштыру кебек актив эш формаларын кулланырга өйрәтү. Шулай эшләгәндә генә, алган белемнәр төпле һәм ныклы була.

Интегратив укыту технологиясе (мәсәлән, инглиз һәм татар теле дәресләре) укучыларның белем алу потенциалын, актив рәвештә фикер йөртү һәм телләр арасындагы уртаклыклар белән аермаларны билгеләү күнекмәләрен үстерүгә китерә. Моның белән беррәттән алар тел берәмлекләрен төрле яклап бәяләргә, үз сөйләмнәрен эзлекле, аңлаешлы итеп оештырырга күнегәләр.

Тулаем алганда, яңа педагогик технологияләрне сайлау һәм куллану буенча берничә нәтиҗәне билгеләп үтә алабыз: беренчедән, укучыларның яшен, белем дәрәҗәсен һәм дәреснең темасын исәпкә алу; икенчедән, традицион һәм инновацион методларның бер-берсен тулыландыруын истә тотып эш итү; өченчедән, тел һәм сөйләм материалын визуаь рәвештә кабул итүнең мөһимлегенә аерым игътибар бирү. Бүгенге көндә телләрне укытуны яңача оештыру һәм укучыларны алган белемнәрен аралашуда кулланырга күнектерү – заман таләбе. Шуңа күрә дә КФУ ның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты базасында үткәрелә торган укытучыларның белемен үстерү курсларында да нәкъ шушы проблемаларга төп игътибарны юнәлтәбез, стажировка мәйданчыкларында алдынгы укытучыларның гамәли эшчәнлеге белән таныштырабыз.

Шулай итеп, яңа педагогик технологияләрне куллану һәм татар телен укытуны гамәли эшчәнлеккә нигезләнеп алып бару, белем бирү өлкәсендәге заманча үзгәрешләрне укытучыларга җиткерүне төп бурычыбыз дип саныйбыз.

### Әдәбият


1. Донецкая О.И. Интернет-технологии в обучении иностранным языкам. – Казань: Каз. гос. ун-т, 2009. – 79 с.

2. Камаева Р. Татар теленә өйрәтүдә заманча педагогик технологияләр //Мәгариф, 2014. – №11; № 12.

3. Кашлев С.С. Современные технологии педагогического процесса. – Мн.: Университетское, 2000. – 95 с.

4. Полат Е.С., Бухаркина М.Ю. Современные педагогические и информационные технологии в системе образования: учеб.пособие для студ. высш. учеб.заведений. – М.: Академия, 2007. – 368 с.

5. Фатхуллова К.С., Гусейнова Г.А. Современная модель дистанционного обучения татарскому языку // Научный Татарстан, 2015. – №2. – С. 140-143.

6. Шайхин А. Татар теле укытучысына Интернет ничек булыша? //Мәгариф. Татар теле, 2016. – № 4. – 40-42 б.

# «ПУШКИН ИЛӘ ЛЕРМОНТОВТАН ҮРНӘК АЛАМ…»
## (Г. ТУКАЙ ӘДӘБИ МИРАСЫНДА «ПУШКИННӘН МОКЪТӘБӘС» ИРЕКЛЕ ШИГЫРЬЛӘРЕНЕҢ ТЕЛЬ-СТИЛЬ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ)

Фәхриева Л.Х.
Казан шәһәренең 72 нче мәктәбе
leilya-lovely-fakhrieva@mail.ru

**Аннотация**. В данной научной статье рассматриваются стилистические и лингвистические особенности вольных переводов Г. Тукая из А.С. Пушкина. Представлен сравнительный анализ стихотворений А. Пушкина в переводах на татарский язык Г. Тукаем. Выявлены особенности переводов лексических средств выразительности, отмечены как некоторые неточности, так и удачи.
**Ключевые слова**: межлитературный диалог, вольный перевод, наследие Тукая, переводы стихотворений Пушкина, поэзия, перевод, особенности переводов лексических средств выразительности.

«Һәр халыкның үз бөекләре була. Бөеклек ул – рухи һәм акыл биеклеген билгеләүче күрсәткеч. Халкың бөеклегенең ни дәрәҗә биеклеген бүтән зур биеклекләр белән чагыштырып белеп була», – дип яза халык шагыйре Равил Фәйзуллин. Тукай һәм Пушкин – әнә шул чагыштыру эталонына әверелгән зур биеклекләр. Г. Тукай бары 27 (иҗат итү чоры 8 ел), А.С. Пушкин 37 ел гына яшәсәләр дә, аларнын гомере гасырлар белән исәпләнә. Чөнки аларның һәрберсе, кыска гына вакыт эчендә, олы һәм кабатланмас иҗади мирас калдырган шәхесләр. «Пушкин иҗаты үзеннән соңгы чор сүз сәнгатенең ныклы нигезен салган. Пушкиннан бөек үзгәрешләр башлана... Мондый мисал татар әдәбиятында да күзәтелә. Тукайдан соң башка халыклар алдында милли һәм татар әдәбиятларының әһәмияте артты», – дип бәяли танылган рус прозаигы М. Горький.

Пушкин белән очрашуның Тукай өчен әһәмияте зур була: шагыйрь үзен хаклы рәвештә Пушкинның укучысы дип санаган, аның белән горурланган һәм аңардан шигърият серләренә төшенгән. Әлбәттә, Пушкин Тукай өчен остаз гына булмый. Моның шулай икәнлеген Тукайның рус шагыйренә атап язган шигырьләреннән, истәлек-хатирәләреннән күрәбез: шагыйрьләр табигатенә генә хас булган аерым бер эчке җылылык һәм ягымлылык сиземләнә аларда.

Тукайның русча теле дә Пушкин, Лермонтов шигырьләре белән ачыла, Җаекта өчьеллык рус классын тәмамлагач та, Тукай рус әдәбиятын өйрәнүне ташламый. Крылов, Пушкин, Лермонтов, Кольцов, Толстой аның яраткан язучыларына әйләнәләр. Рус классикларының кайбер әсәрләрен ул шул вакытта ук тәрҗемә итә, ләкин татарча матбугат булмау сәбәпле, бастыра алмый.

Белгәнебезчә, татар әдәбиятында әдәби тәрҗемә милли әдәбиятның бер өлешен тәшкил итә. Татар теленә беренче әдәби тәрҗемәләр (ә алар ирекле тәрҗемәләр булганнар) урта гасырларда ук барлыкка килә. Тәрҗемәләр, кагыйдә буларак, ирекле рәвештә эшләнгән. Күп очракта оригинал әсәрнең

авторы яки исеме күрсәтелмәгән. Г. Тукайга килгәндә, шагыйрь һәр шигыренең исеменнән соң кемнең әсәреннән файдалануын күрсәтеп барган. Татар теленә тәрҗемә тарихы да нәкъ менә бөек шагыйрь Г. Тукай исеме белән бәйле. Тукай үзенең тәрҗемә эшчәнлегендә күренекле рус шагыйре А.В. Жуковскийны остаз итә, аның тәҗрибәсеннән файдаланып, татар әдәбиятында ирекле тәрҗемә мәктәбен нигезли. Тәрҗемәдә үз иҗат кысаларыннан чыгып эш итә, үз максатын һәм бурычларын куя.

Рус текстыннан читкә китү, аның кайбер әйләнмәләрен төшереп калдыру, кайберләрен бары тик татар теленә хас алымнар белән тәрҗемә итү, оригиналга теге яки бу детальләр өстәү – бу үзенчәлекләр барысы да Тукайның иҗат юнәлешенә һәм иҗтимагый карашларына бәйле.

Тукайның барлык тәрҗемәләре – нигездә ирекле тәрҗемәләр. Аларны шартлы рәвештә ике төргә бүлеп була: оригиналга якын һәм оригиналдан ераклашкан тәрҗемәләр. Беренчеләрендә рус текстларын тәфсилләп аңлату, киңәйтеп тәрҗемә итү очраса, икенчеләренең характеры төрлечә. Алар арасында шагыйрьнең үз строфалары кушылган өлешчә тәрҗемәләр бар. Бу тәрҗемәләрдә оригиналның кайбер строфалары, билгеле бер фактларның татар халкы тормышына, әдипнең үз иҗади рухына туры килмәве сәбәпле төшереп калдырылган. Оригиналдан ераклашкан тәрҗемәләр арасында Тукайның үз әсәрләре булып үсеп киткәннәре дә күп. Шагыйрь аерым бер шигырьләре белән нәзирә алымын иҗади яңарта, гасырлар дәвамында Көнчыгышка, рус һәм аның аша Европа поэзиясенә борып җибәрә; дөнья әдәбияты кебек рифма, жанрлар төрлелеген, кабатлауларны, рефрен, анафора, ялгауларны иркен куллана. Әмма ул Көнчыгыш әдәбияты казанышларыннан да баш тартмый.

Шагыйрь 1906 нчы елда үзенә кумир итеп А.Пушкинны алуын игълан итә. Шуңа да Тукайның әдәби мирасында Пушкиннан тәрҗемәләр яки аның иҗатыннан файдаланып язылган күп кенә шигырьләр булуы табигый. Таҗик язучысы С. Айнидан «Сез Пушкинның әсәрләре белән кайчан һәм ничек таныштыгыз? » – дип сорагач, «Тукайдан укыдык», – дип җавап бирүе мәгълүм. Мисал өчен, 1907 елны Пушкиннан тәрҗемә ителгән «Мәхбүс» («Узник») шигырен алыйк. «Тимер читлек»тәге тоткын һәм «ирек иркендә үскән яшь каракош» образлары ярдәмендә шагыйрь үзенең иреккә, азат тормышка булган мәхәббәтен бик ачык чагылдыра. Оригинал 3 строфалык шигырь, беренче һәм икенче, өченче белән дүртенче тезмәләр үзара рифмалашкан. Г. Тукай тарафыннан башкарылган тәрҗемә исә бер-берсе белән рифмалашкан 13 икеюллыклардан гыйбарәт. Шагыйрь эпитетларны да турыдын-туры, бер компонентын үзгәртеп, яисә өстәлмәләр белән тәрҗемә иткән: *орел молодой – яшь каракош, кровавую пищу – канлы калҗасын; в темнице сырой – тимер читлек эчендә (дымлы төрмәдә), мой грустный товарищ – моңлы иптәшем (моңсу иптәшем), криком своим – ят садасы (тавышы белән). Вольные птицы* эпитетын – *азатлык кошлары (ирекле кошлар)* дип, метафора аша биргән. *Белеет гора – зур таулар агара, синеют морские края – диңгезләр төтен күк, күм-күк* кебек сынландыруларны тәрҗемә итүдә дә иреклелек күзәтелүен

күрәбез. Әйтик, беренче мисалда, таулар сүзе алдыннан зур дигән ачыклаучы сүз өстәлсә, икенче мисалда оригиналдагы сынландыру поэтик чарасы татар укучысына тәрҗемәдә чагыштыру лексик сурәтләү чарасы аша тәкъдим ителә. Шигырьдә Г. Тукай тарафыннан гына кертелгән эпитетлар да бар: *каты кайгы, ачы хәсрәт, каты җирдә, яңа эш, ямь-яшел кырлар, болыннар, тавышсыз, тынсыз аулак һәр урыннар* шундыйлардан.

1906 нчы елда Тукай Пушкинның «Евгений Онегин» романының бер строфасы («Кого ж любить?»дип башланган, IV бүлек, XXII строфасы) мотивы буенча «Кемне сөяргә кирәк? » шигырен яза. Пушкинның Онегины – эгоист. Ул үзен генә ярата, мәхәббәттән баш тарта. Тукай да: *«Үзеңне сөй! Ярат үзеңне-үзең»,* –ди.

Пушкинның 4 строфалык «Поэту» шигыренең эчтәлек-формасын татар классигы 11 икеюллыктан торган «Киңәш» шигырендә ачып бирә. «Поэту» шигырен Пушкин 1830 нчы елда иҗат иткән. Ул шагыйрьнең җәмгыятьтәге роле, шигърият өчен ни дәрәҗәдә кирәк булуы турындагы уйланулары белән бүлешә. Әдип – ирекле. Аның үз юлы, кыйбласы булырга тиеш. Шагыйрь һәрдаим үзенең эшчәнлеген камилләштерсен, яңа үрләргә омтылсын, шул ук вакытта бүләкләүләрен дә көтмәсен; ул бәяне үзенә үзе бирә ала, дигән фикер үткәрә рус әдәбиятының күренекле вәкиле.

Г. Тукай «Киңәш» шигырендә шагыйрь дустына мөрәҗәгать итә һәм *«Кешеләргә сереңне сөйләмәс бул, эчеңдә нәрсә янганын үзең бел. Сереңбелгәч, кызартырлар йөзеңне»,* – ди. Хәтта *«Кача күр, кош кеби мактауларыннан»* да дигән киңәш бирә. Александр Сергеевичта *любовию народной, восторженных похвал, минутный шум, дорогою свободной, свободный ум, плоды любимых дум, свой высший суд, свой труд, взыскательный художник, твой огонь твой треножник, в детской резвости* кебек метафора-эпитетларны очратсак, Г. Тукайда *кош кеби, яшьрен хәзинәңне, артык сүз, тәмле-тәмле күз яше* кебек сурәтләү чараларын күрәбез.

Рус әдибенең «Я пережил свои желанья» (1821) шигыренә килгәндә, әлеге әсәр көньяк сөрген елларында язылган. Бу шигырь шагыйрьнең үз язмышы турында уйлануларын үз эченә ала. Ул әле яшь булуына карамастан, инде күпне күрергә өлгергән. Лирик герой үзен бәхетле санамый, яшәү көчен җуйган. Юкса, бу яшьтә (22 генә яшь) бәхет һәм мәхәббәт турында уйлар, хыялланыр чак. Тукай, үз чиратында, «Пушкиннән мокътәбәс» язылган «Теләү бетте» (1909) шигырендә *«Теләү бетте, фәкыйрь калдым хәзер: тормыш үзенең биргәнен алды; Күңел буш: анда калды тик авыр хәсрәт, ачы кайгы»,* – дип остазының фикерләрен иҗади дәвам иттерә. Өметсезлеккә бирелгән лирик «мин» үз алдына *«Кайчан тавыш-тынсыз гына бер көн бетәм инде?»* дигән риторик сорау куя һәм үзен *«туңып беткән агачның яп-ялангач бер ботагында»*гы *«соңга калган бер генә яфрак»* белән чагыштыра. Татар укучысына оригиналның идея-эчтәлеген җиткерүдә ирекле тәрҗемә тарафдары Г. Тукай *чиксез ихтыярымнан, гаҗәп ләззәтле, тәмле хыял, буш күңел, авыр хәсрәт, ачы кайгы, гүзәл чәчкәмне, явыз тәкъдир, каты тәкъдир, суык тәкъдир, актык дәкыйкамне, туңып беткән агачның яп-ялангач бер*

*ботагында, соңга калган бер генә яфрак* кебек лексик сурәтләү чараларын уңышлы файдалануга ирешкән.

Югарыда китерелгән шигырь юлларыннан күренгәнчә, текстның төгәллеге һәрвакытта да сакланмый. Каләм иясе, еш кына, әсәрнең бары тик идеясен, нигезен һәм төп образ-детальләрен генә алган һәм оригиналдан бик нык аерылып торган «яңа әсәрләр» иҗат иткән. Мондый ысул һәм чаралар исә аның шигырьләренә милли колорит биреп торалар.

**Әдәбият**


Гарбовский Н.К. Теория перевода: Учеб. для студентов вузов, обучающихся по спец. «Лингвистика и межкультур. коммуникация». – М.: Изд-во Московского университета, 2004. – С. 542.

Заһидуллина Д.Ф. Шагыйрь иҗатын өйрәнергә яңача караш // Мәгариф, 2006. – №4. – 12 бит.

Набиуллина Г.А. Перевод художественного текста (конспект лекций). – Казань, 2014. – С. 109.

Пехтелев И.Г. Тукай и русская литература. – К.: Татарское книжное издательство, 1966. – С. 182.

Пушкин А.С. Сайланма әсәрләр 2 томда: шигырьләр, поэмалар, «Евгений Онегин» романы, әкиятләр, драма әсәрләре. Т. 1. – Казан: Таткнигоиздат матур әдәб. ред-се, 1954. – 743 б.

Тукай Г. Сайланма әсәрләр: шигырьләр, поэмалар һәм чәчмә әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 480 бит.

# СИНОНИМИЧЕСКАЯ ПАРАДИГМА В ФИЛОЛОГИЧЕСКИХ ИССЛЕДОВАНИЯХ

Ферафонтова А.И.
Казанский федеральный универсиет
feraffarida@yandex.ru

**Аннотация.** В статье рассматривается теоретические вопросы синонимической парадигмы. Приводятся взгляды ученых, относительно этого термина.

**Ключевые слова**: синонимы, парадигма, лингвистика, лексика.

Язык – постоянно изменяющаяся система, изменению подвергается, прежде всего, словарный состав. В нем отражаются новые явления действительности, новые понятия, что находит выражение в синонимии. В научных исследованиях наблюдается высокий интерес к проблеме синонимии и синонимической парадигмы. Вопросы синонимии разрабатывались в трудах Д.Н.Шмелева, В.В.Виноградова, Ю.Д.Апресян, Л.В. Серебрякова, В.Н. Мигирина, В.А. Звегницева; синонимические словари русского языка создавали Клюева В.Н. (1856), Александрова З.Е. (1968), А.П. Евгеньева (1970), Н.Абрамов (1996), Горабчевич К.С. (1996), Ю.Д.Апресян (2000). В тюркском языкознании вопросы синонимии рассмотрены такими учеными как В.Г.Хангильдин (1940), В.Мескутов (1961), Абдуллаев Б.Т. (1961), Ш.Ханбикова (1961), Ф.С. Сафиуллина (1984) и др.

Согласно «Словарю лингвистических терминов» Т.В. Жеребило (2010), синонимическая парадигма – «синонимический ряд, в котором интегральным признаком является адекватность (тождественность), близость значений синонимов. Дифференциальные признаки синонимов в синонимичной парадигме – различия в звучании (написании) слов, в их значениях и функционально-стилевом употреблении. В синонимической парадигме выделяется доминанта». Основанием для объединения слов в парадигму служит тождество; лингвист Ф.де Соссюр отмечал, что «весь механизм языка зиждется исключительно на тождествах и различиях, причем эти последние являются лишь оборотной стороной первых» [4: 141]. При этом тождество в языке предполагает многообразие лексическое и грамматическое. Тождество выступает интегральным признаком, определяющим различия языковых единиц. Слова в языке образуют синонимический ряд, в котором слова обладают различными семантическими признаками. Синонимы обозначают одно понятие, каждый из них характеризует это понятие только с определенной стороны, но выполняет различные функции в парадигматическом ряду. Слова с самыми объемными и нейтральными значениями составляют доминанту синонимической парадигмы. Доминантой становится стилистически нейтральное слово, обладающее большой лексической сочетаемостью. Доминанта становится единицей сопоставления синонимов.

Синонимическая парадигма основана на том, что слова образуют группы, объединенные на основе их семантических свойств. В парадигме члены ряда взаимосвязаны, расположены последовательно; это особая система, представляющая собой объект филологического исследования. Между членами парадигмы существует семантическая связь, на основе которой осуществляется составление иерархической структуры синонимической парадигмы.

Значения синонимов не являются тождественными, совпадающими, но между синонимами в рамках парадигматического ряда существует семантическая связь. Члены парадигматического ряда обладают совпадающими и различающимися, дифференциальными компонентами. Дифференциальные признаки определяют существующие сходства и различия между членами синонимического ряда. В синонимический ряд могут быть объединены слова с предельно близкими значениями и минимально близкими значениями. Дифференциация синонимов в парадигме может быть осуществлена по семантике (содержание различных по отношению к доминанте сем), стилистическому признаку (содержание различных эмоционально-экспрессивных коннотаций), по отношению к различным стилям речи. Также производится структурное разделение синонимов (однокорневые, разнокорневые).

Синонимическая парадигма как объект изучения предполагает установление взаимосвязи между ее членами, определение семантики синонимов, степени их близости. Проводится анализ дефиниций по толковым и двуязычным словарям, выявляются дифференциальные признаки, позволяющие построить иерархическую структуру синонимической парадигмы.

В научных работах, проведенных отечественными учеными, широко рассматриваются суть и формы синонимических парадигм. Так, в исследовании Хоменко О.В. [5] исследуется моделирование синонимической парадигмы с доминантой «страх». Волкотруб Г.И. анализирует фразеологические антонимико-синонимические парадигмы современного русского языка [1]. В диссертации Казанцевой Е.А. [2] проводится когнитивно-сопоставительное описание синонимических парадигм с доминантами «to frighten» и «пугать». Однако существует необходимость проведения исследования синонимической парадигмы лексических единиц в башкирском и татарском языках, где монографические работы на сегодняшний день отсутствуют.

Таким образом, синонимическая парадигма, представляющая собой особую систему, в которой элементы объединены семантической связью, представляет собой объект научного исследования. Анализу подвергаются дефиниции слов, компоненты значений членов синонимической парадигмы, определяется тип связи между членами ряда.

**Литературы**

1. Волкотруб Г.И. Фразеологические антонимико-синонимические парадигмы современного русского языка: автореферат дис. ... кандидата филологических наук: 10.02.01. – Киев, 1991. – 22 с.

2. Казанцева Е.А. Когнитивно-сопоставительное описание синонимических парадигм с доминантами to frighten и пугать: автореферат дис. ... кандидата филологических наук: 10.02.20. – Краснодар, 1999. – 19 с.
3. Словарь лингвистических терминов: Изд. 5-е, испр-е и дополн.- *Н*азрань: Пилигрим, 2010.-*568 с.*
4. Соссюр Ф. Курс общей лингвистики. // Избранные труды по языкознанию. - М.: Прогресс, 1977. – 697с.
5. Хоменко О.Е. Моделирование синонимической парадигмы с доминантной "страх": Дис. ... канд. филол. наук: 10.02.19. - Ставрополь, 2006. – 184 с.

# ТАТАР ТЕЛЕҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ КУЛЛАНУ ӨЧЕН, LEARNINGAPPS.ORG СЕРВИСЫ ЯРДӘМЕНДӘ ИНТЕРАКТИВ БИРЕМНӘР ТӨЗҮ

Хәева Ф. Җ.
Казан шәһәре Киров районы 182 нче олитехник лицее
khaevafanuza@mail.ru

**Аннотация.** В статье представлены материалы проведения мастер-класса с педагогами-предметниками по изучению возможностей сетевого социального сервиса LearningApps.org. Охарактеризован веб-сервис LearningApps и раскрыты его возможности для создания интерактивных учебно-методических пособий по разным предметам, в том числе по татарскому языку. Слушатели научатся создавать с помощью онлайн - сервиса кроссворды, пазлы, тестовые задания, викторины, дидактические игры, адаптировать видео-файлы к использованию в учебном процессе.
**Ключевые слова:** LearningApps.org сервисы, виртуальный класс, интерактивное приложение, информационные технологии, онлайн-сервисы.

**Мастер – классның максаты:** татар теле һәм әдәбияты дәресләрен, заманча технологияләргә нигезләнеп, үткәрү мөмкинлекләрен күрсәтү; татар телен һәм әдәбиятын өйрәткәндә файдалану өчен, LearningApps.org сервисын кулланып төзелгән дидактик биремнәр тәкъдим итү.

**Мастер – класс барышы:**

Дистант укыту шартларында туган (татар) теле һәм әдәбяты укытучылары кыенлыклар алдында калды. Тәкъдим ителгән платформаларның күбесендә, туган тел һәм әдәбият дәресләрендә куллану өчен, методик ярдәмлекләр юк диярлек.

Шуңа күрә дә мин бүген сезнең игътибарыгызга балаларның белемнәрен актуальләштергәндә, яңа тема өйрәнгәндә һәм ныгытканда, **LearningApps.org** сервисын кулланып төзегән дидактик биремнәр (уеннар) тәкъдим итәм. Шундыйлардан кроссворд чишү, пазллар җыю, парын табу, сүзләрне (рәсемнәрне) төркемнәргә урнаштыру, төшеп калган сүзләрне урнаштыру, викторина һәм башка уеннарны санап китәргә була. Биремнәрне әзер килеш алып кулланырга да мөмкин, ләкин сайтта укытучы үзе теркәлеп эшләсә, укытучы өчен уңайлырак булачак. Укытучы өчен шунысы уңайлы: биремнәрне тиз арада үзгәртеп, төрле темага, төрле сыйныф өчен яраклаштырырга мөмкин.

Хәзер шул уеннарның берничәсен генә карап китик.

**“Пазл җыю” уены**

Бирелгән исемнәрне “Агачлар”, “Чәчәкләр”, “Җиләк-җимеш”, “Куаклар”, “Яшелчәләр”, “Үләннәр” дип исемләнгән лексик төркемнәргә дөрес итеп урнаштырыгыз.




Әгәр укучы биремне дөрес башкарса, пазллар астына яшерелгән рәсем килеп чыга, бала: “Афәрин! Син булдырдың!”- дигән сүзләр белән канатландырыла. Әгәр инде ялгышлык җибәрсә, “Уйлап кара!” яки “Яхшылап уйла!” кебек фразалар укучыны игътибарлы булырга өнди.

**“Кроссворд” уены**

“Кроссворд” уены исемнең билгеләмәсен, ялгызлык яки уртаклык исемнәрне, исемнең грамматик категорияләрен, синтаксик функцияләрен искә төшерү максатыннан файдаланыла.




*Бирем:* "Исем" темасы белән бәйле төшенчәләрне искә төшерегез, кроссвордны чишегез.

**“Парын тап” уены**

Мәсәлән, бу уенны мин парлы, кушма, тезмә исемнәрне яки исемнәрнең килеш белән төрләнешен искә төшерү максатыннан төзегән идем.







*Биремнәр:* 1. Кушма, тезмә, парлы исемнәр ясагыз, парларны дөрес итеп урнаштырыгыз. 2. Җөмләләрдә тиешле килештәге сүзне кулланыгыз.

**“Парлылар” уены**

Әлеге уенны 8 нче сыйныфта “Казан – спорт шәһәре” темасын үткәндә кулландым. Уенның асылы шунда: рәсем белән аның атамасын дөрес табарга кирәк. Карточкалар бер-бер артлы гына ачыла. Әгәр тәңгәл килсәләр, пар табылды дигән сүз һәм карточкалар ачык кала; әгәр тәңгәл килмәсәләр, карточкалар ябыла. Бу уен укучының игътибарын таләп итә һәм спорт корылмаларының атамаларын истә калдырырга ярдәм итә.




**“Тәртип буенча урнаштыр!” уены**

*Бирем:* репликаларны, диалог барлыкка килерлек итеп, тәртип буенча урнаштырыгыз.




**“Классификация” уены**

Бу уенны текстны укыганнан соң, аның эчтәлеген аңлауларын тикшерү максатыннан кулланырга яратам. Татар төркемнәрендә “Бәйлекләр”, “Теркәгечләр”, “Кисәкчәләр” темаларын үткәннән соң да тәкъдим иттем.







*Бирем:* җөмләләрне яки сүзләрне тиешле төркемнәргә урнаштырыгыз.

**“Дөрес җавапны сайлап алу мөмкинлеге булган викторина” уеннары**

Бу уеннарда укучы сорауга дөрес җавапны сайлап алырга тиеш. Уен тәмамланганнан соң, укучының  ничә сорауга дөрес җавап бирүе күрсәтелә. Шуңа күрә дә әлеге биремне мин укучыларның белемнәрен тикшерү максатыннан тәкъдим итү өчен отышлы дип саныйм.







Бу уеннар LearningApps.org сайтында урын алган. Без платформадагы уеннарның берничәсен генә крап киттек. Анда уеннар күптөрле. Алардан әзер килеш тә файдаланып була, ошамаса, уеннарның биремнәрен тиз арада үзгәртү мөмкинчелеге дә бар.

LearningApps.org платформасының укытучы өчен тагын бер отышлы ягы бар. Әгәр укытучы үзе теркәлеп эшләсә, укытучы бу платформада укучыларын терки алачак һәм тәкъдим ителгән биремнәрне укучылары ничек эшләвен күзәтә алачак. Моның өчен “Мои классы” вкладкасында һәр сыйныфны, анда укучы баларның исем-фамилияләрен күрсәтергә кирәк булачак, һәм платформа үзе һәр укучыга логин, пароль бирәчәк. Укытучыга бу логин-парольләрне укучыларга таратырга гына кирәк булачак.




Бу эшне башкарганнан соң укытучы һәр класс папкасына уеннарны урнаштыра ала һәм укучыларның биремнәрне башкаруын  статистика аша күзәтә ала.






Барлык алда сөйләнелгән материалга йомгак ясап, нәтиҗә ясыйк.

LearningApps.org сервисын мин бик яратып кулланам, чөнки уен кебек тәкъдим ителгән биремнәр теманы үзләштерүне җиңеләйтәләр, балаларга да кызыклы. Һәрбер уен темадан чыгып сайланырга тиеш, шул очракта гына ул телне өйрәнү процессында уңай нәтиҗәләр бирер дип ышанып әйтергә мөмкин.

Дәрестә уеннарны куллану өчен, укытучы зур методик әзерлекле булырга, уенны кызыксындырырлык, мавыктыргыч итеп оештырырга тиеш. Әлбәттә, һәр яңа эш вакыт таләп итә. Башта авыррак кебек тоелса да, эшли башлагач, укытучының үзенә дә бик кызыклы булачак. Мәкалә белән танышкан кеше, һичшиксез, **LearningApps.org** сервисын үз эшендә ошатып кулланыр дигән өметтә калам, чөнки әлеге сервис тиз арада уеннар төзергә, уенны кирәкле темага яраклаштырырга ярдәм итәчәк.

Уңышлар сезгә, хезмәттәшләр!

**Әдәбият**

1. Харисов Ф.Ф. Заманча белем бирү технологияләре: Аспирантлар, магистрлар һәм укытучылар өчен кулланма. – Казан, 2015. – 62б.

2. Харисов Ф.Ф. Научные основы начального обучения татарскому языку как неродному/ Под ред. проф. Л.З.Шакировой. – Спб.: филиал изд-ва «Просвещение», 2001. – 431с.

Электрон ресурслар

1. Методические рекомендации по созданию интерактивных заданий в сервисеLearningApps.//https://www.yamg.ru/images/files/dot/metodicheskie-rekomendacii/learningappsorg.pdf (мөрәҗәгать итү вакыты: 07.02.2021)

2. LearningApss.org – создание мультимедийных интерактивных модулей по готовым шаблонам.// https://learningapps.org/user/fanuzaz (мөрәҗәгать итү вакыты: 06.02.2021)

# РАЗВИТИЕ КОММУНИКАТИВНОЙ ОДАРЕННОСТИ УЧАЩИХСЯ ГИМНАЗИИ

Хаева-Хаметзянова В.Х.
Актанышская гуманитарная гимназия-интернат для одарённых детей
venerahaeva@yandex.ru
Фатхуллова К.С.
Казанский федеральный университет
kadria.kgu@mail.ru

**Аннотация.** В данной статье рассматривается педагогический опыт организации гуманитарного образования в школе-интернате для одаренных детей. Деятельность гимназии для одаренных детей направлена на личностно-ориентированное образование, воспитание социально активной и самостоятельной личности, развитие интеллектуальных, коммуникативных способностей и ключевых компетенций учащихся.

**Ключевые слова:** гуманитарное образование, полилингвальная среда, коммуникативная одаренность, педагогические инновации, творческая активность.

Современная лингводидактика акцентирует внимание педагогов на активизации познавательной деятельности учащихся. В связи с этим развитию у учащихся умения осуществлять речевую деятельность не только на родном, но и на других языках придается неоценимое значение. Содержание языкового образования в условиях реализации ФГОС общего образования включает в себя сферы коммуникативной деятельности; коммуникативные и социальные роли; языковой материал, правила его оформления и навыки оперирования им; комплекс речевых умений, характеризующих уровень практического владения языком как средством общения и познания в контексте диалога культур; этикетные формы речи и умение ими пользоваться в различных сферах речевого общения; широкий спектр транскультурной информации; общие учебные умения.

Содержание языкового образования ориентировано на становление следующих личностных характеристик выпускника общеобразовательной школы: знающий языки, уважающий культуру и духовные традиции; активно и заинтересованно познающий мир, осознающий ценность труда и творчества; умеющий учиться, осознающий важность образования и самообразования для жизни и деятельности, способный применять полученные знания на практике; социально активный, соизмеряющий свои поступки с нравственными ценностями, осознающий свои обязанности перед семьей, обществом, Отечеством; умеющий вести конструктивный диалог, достигать взаимопонимания, сотрудничать для достижения общих результатов; ориентирующийся в мире профессий, понимающий значение профессиональной деятельности для человека в интересах устойчивого развития общества и природы.

Исходя из задач совершенствования языкового образования в начале XXI века в нашей стране стали появляться общеобразовательные учреждения нового типа, в том числе гуманитарные гимназии для одарённых детей, деятельность которых направлена на личностно-ориентированное образование, воспитание социально активной и самостоятельной личности, развитие интеллектуальных, коммуникативных способностей и ключевых компетенций. Современное гуманитарное образование – это особое образовательное действие, и главное в этом действии заключается в возможности влияния человека на свое образование, участия в нем, выстраивании своих образовательной траектории. Педагогическое сообщество понимает необходимость изменений в отечественной системе языкового гимназического образования в условиях её интеграции в мировое образовательное пространство. Это, в свою очередь, требует внесения изменений в цели, содержание, технологии обучения, в организацию учебно-воспитательной деятельности школьников, в систему контроля и оценки уровня их языковой подготовки. Все больше очущается необходимость развития сети образовательных учреждений нового типа, учитывающих социальные перемены в обществе, так как своевременная реформа образовательной системы является одним из самых действенных мер для выживания всего человечества. Система образования – это базисный социальный институт, который определяет социально-экономический прогресс общества, его нравственно-психологическое состояние и культурное развитие. Одной из его функций является передача этнокультурных знаний, норм, ценностей, традиций, обеспечивающая этническую преемственность, сохранение и развитие этнической общности [3, с. 16].

Совет Европы в рамках проекта «Среднее образование для Европы» определил систему умений, которыми должны обладать сегодняшние выпускники школ: умение работать и сотрудничать в группе (в команде); умение свободно общаться на нескольких языках; умение решать проблемы, используя различные источники информации; умение использовать информационные компьютерные технологии; умение брать ответственность на себя при принятии решений и т.д. [1, с. 57].

В Республике Татарстан создана единая сеть гуманитарных гимназий-интернатов для одарённых детей. Первая такая гимназия была открыта в 2011 году в с. Актаныш Актанышского муниципального района [4]. Актуальность создания гимназии объясняется тем, что мир стремительно меняется, и система образования призвана быть той движущей силой, способствующей социально-экономическому росту республики. Языковая подготовка современных школьников должна отвечать изменяющимся потребностям времени. Миссия гуманитарной гимназии-интерната заключается в создании конкурентоспособного образовательного учреждения, отвечающего требованиям времени в условиях рыночных отношений. Стратегическая цель гимназии-интерната направлена на подготовку в условиях новых федеральных государственных образовательных стандартов интеллектуально и творчески

развитых учащихся, обладающих такими личностными качествами, как уважение и толерантность к другим народам, компетентность в межкультурном диалоге.

Укучыларда иҗтимагый-мәдәни компетенция булдыру белем бирүдә яңа юнәлешләрнең берсе булып санала. Әлеге мәсьәләнең уңай чишелеше телне милли һәм мәдәни яссылыкта өйрәтү белән бәйле. Бала дәресләрдә үзенең һәм башка халыкларның мәдәниятен хөрмәт итәргә, аны дөрес бәяләргә, төрле халыкларның мәдәни кыйммәтләрен үзара бәйләнештә карарга өйрәнсен. Әлеге материаллар телгә һәм мәдәнияткә кызыксынучанлык, башка милләт вәкилләренә сабыр һәм түземле мөнәсәбәт тәрбияли. Шуңа да тел дәресләрендә татар һәм рус халкының мәдәни традицияләре, гореф-гадәтләре, кыйммәтләре белән танышу өчен зур мөмкинлек тудырыла.

Шулай итеп, укучыларда иҗтимагый-мәдәни компетенцияне булдыруның һәм үстерүнең кирәклеге Стандартның эчтәлегеннән үк аңлашыла. Мондый юнәлеш телгә өйрәтүне милли һәм мәдәни яссылыкта алып баруның стратегиясен билгели. Кыскача гына әйткәндә, иҗтимагый-мәдәни компетенция булдыру хәзерге күптөрле мәдәниятләр яшәгән җәмгыятьтә үзара дустанә мөнәсәбәткә ия булган хезмәттәшлеккә әзерлекне дә аңлата. Укучыларда аны формалаштыру һәм үстерү уку-укыту процессына куела торган белем бирү, үстерү һәм тәрбияви максатларны да хәл итүгә юнәлтелгән.

Билгеле булганча, милли мәдәният өлкәсенә караган компетенция белән иҗтимагый-мәдәни компетенция үзара тыгыз бәйләнештә яши. Әлеге проблеманың бүгенге көндә аеруча актуаль булуын, татар теле укыту методикасына караган элеккеге һәм хәзерге хезмәтләрдә тиешле дәрәҗәдә чагылыш тапмавын истә тотып, бу компетенциягә киңрәк тукталдык.

**Әдәбият**

1. *Соловьёва Е. Н.* Методика обучения иностранным языкам: базовый курс. М: Просвещение, 2002. 256 с.

2. *Харисов Ф. Ф.* Рус телендә сөйләшүче балаларны татарчага өйрәтүнең башлангыч чоры. – Казан: КДПИ, 1996. – 48 б.

3. Харисов Ф.Ф. Татар теле: укыту теориясе һәм практикасы. – Казан: Ак бүре, 2018. – 448 б.

# ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ПРОЕКТ ЭШЧӘНЛЕГЕН ОЕШТЫРУ

Хәйретдинова Л.Н.
Казан шәһәре, Киров районының “182 нче политехник лицее
lyuziya77@mail.ru

**Аннотация.** В статье рассматриваются особенности проектной технологии, широко используемой учителями школ при обучении татарскому языку и литературе. Использование проектного метода способствует тому, что учащиеся в процессе работы над учебным проектом постигают реальные процессы и проживают конкретные жизненные ситуации. Они учатся применять полученные коммуникативные умения для решения практических и познавательных задач, развивают у себя исследовательские умения. Новые технологии дают возможность визуализировать изучаемый языковой и речевой материал, а также быстро, доступно и динамично организовать образовательный процесс.

**Ключевые слова:** татарский язык; современные технологии, проектная деятельность, виды проектов, классификация проектов.

Методик хезмәтләрдә әйтелгәнчә, педагогик технология – укытучының эшчәнлеге белән бәйле һәм белем бирү максатларына ирешүгә юнәлтелгән билгеле бер эшләр бердәмлеге ул [1, с. 12]. Шуңа күрә дә заманча технологияләр белем бирүне уңышлы оештыру, максат-бурычларны, белемнәрне үзләштерү һәм коммуникатив күнекмәләр булдыру нәтиҗәләрен, дәресләрдә төрле алымнарны гамәлгә ашыруны үз эченә ала. Хәзерге вакытта телләргә өйрәтү өлкәсендә киң кулланыла торган технологияләргә түбәндәгеләрне кертеп карыйлар: мәгълүмати-коммуникацион технологияләр, проектлар технологиясе; проблемалы укыту технологиясе; уен технологиясе; үстерелешле укыту технологиясе; интегратив укыту технологиясе; модульләп укыту технологиясе; дистанцион белем бирү технологиясе; кейс технологиясе, интенсив укыту технологиясе һ.б. Бүгенге көн укучыларына татар теленнән сыйфатлы белем бирү өчен, әлеге технологияләрне системалы һәм урынлы файдалану мөһим. Заманча технологияләрне куллану укытучыга түбәндәге максатларга ирешү мөмкинлекләре тудыра:1) балаларда татар телен өйрәнүгә даими кызыксыну булдыру; 2) укучыларның танып белү эшчәнлеген активлаштыру; 3) укучыларның иҗади мөмкинлекләрен ачып бирү һәм иҗади үсешен тәэмин итү; 4) укучыларга җитәрлек мәгълүмат бирү; 5) уку материалын аңлаешлырак итеп җиткерү; 6) белемнәрне системага салу һәм гомумиләштереп күрсәтү; 7) үзлектән белем алу мөмкинлекләрен киңәйтү; 8) укучыларда эзләнү-тикшеренү эшләре алып бару теләге уяту; 9) предметара бәйләнеш булдыру.

Татар теле дәресләрендә укытучылар тарафыннан киң кулланыла торган проект технологиясенә тукталып үтик. Проект методының асылы: укучылар укытучы җитәкчелегендә эзлекле рәвештә проектлар эшлиләр, эш барышында

өстәмә мәгълүмат туплыйлар. Укучы өчен проект эше нәрсә соң ул? Иҗади мөмкинлекләрен ачу; төркемдә эшләү күнекмәләре булдыру; үзе сайлаган кызыклы проблеманы (теманы) ачып бирү; үзенең эшен презентацияләү. Методик хезмәтләрдә әйтелгәнчә, проект төрләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт: тикшеренү; иҗади; мәгълүмати; социаль. Тикшеренү проектында хәзерге заманда актуаль булган тема алына; тикшеренү объекты һәм ысуллары күрсәтелә; нәтиҗә чыгарыла. Проектның асылы – белем алу шартларында туган проблеманы чишү ысулларын ачыклау. Эзләнүнең асылы – алган белемгә таянып, билгеле бер объектка юнәлтелгән теория һәм практиканы гомумиләштереп, фараз (гипотеза) яклау. Эзләнү эшчәнлегенең төп нәтиҗәсе – ул яңа белемнәр. Укучылар, теоретик белемнәрен гомумиләштереп, тупланган һәм эшкәртелгән мәгълүматларга таянып чыгыш ясыйлар.

Иҗади проектларга килгәндә, алар эш төренә билгеләнгән таләпләр буенча эшләнә. Моңа газета, буклетлар чыгару, презентацияләр әзерләү, сценарияләр язу керә. Мәгълүмати проектларның да үз аермалары бар. Нинди дә булса объект турында мәгълүмат җыю, анализлау (мәсәлән, шәһәребез музее, Кол Шәриф мәчете турындагы проект эшләре һ.б.). Проектларны фән юнәлеше белән бәйле рәвештә өч төргә бүләргә мөмкин: монопроект (программаның укучылар өчен катлаулырак өлешен алып, бер фән кысаларында гына дәрес вакытында эшләнә); фәнара проект (ике яки күбрәк фәнне үз эченә алып, дәрестән тыш вакытта үткәрелә); төп уку фәннәреннән тыш булган проект (бу төр мәктәптә фән буларак укытылмый торган юнәлешне үз эченә ала, дәрестән тыш вакытта оештырыла). Үткәрү масштабына бәйле рәвештә проектларны дүрт төргә бүлеп карыйлар: сыйныф проекты (бер генә сыйныфта үткәрелә); мәктәп проекты (мәктәп эчендә, бер фәннән дәрес вакытында үткәрелә); региональ проект (берничә мәктәп арасында оештырыла); халыкара проект (ике ил арасында үткәрелә). Проектта катнашучылар санына карап,  өч төрне билгелиләр: шәхси проект (бер кеше тарафыннан эшләнә); парлы (проект эшен ике кеше башкара); төркемдә (бер проектны бөтен төркем укучылары эшли). Проект «биш П»ны үз эченә ала диләр: проблема – планлаштыру – мәгълүмат эзләү (поиск) – продукт – презентация. Проект эшләүнең түбәндәге этапларын билгеләп үтәргә мөмкин. Беренче “П”: әзерлек этабы, аны “кереш өлеш” яки “проектка кереп китү” дип тә атарга мөмкин (проектның темасын, максатын һәм проблемасын билгеләү; проблеманың әһәмиятен нигезләү; проект башкару өчен укучыларның шәхси теләкләрен искә алып, төркемнәргә бүлү). Укытучы бу этапта укучыларга проект өчен төрле темалар тәкъдим итә, укучылар тәкъдим иткән темалардан үзләренә ошаганын сайлыйлар. Бу этап проектның иң демократик өлеше булып тора. Проект һәр укучы тарафыннан аерым яки иҗади төркемнәрдә эшләнергә мөмкин. Икенче “П”: эшчәнлекне планлаштыру һәм проблемаларны чишү этабы яки “эшчәнлекне оештыру” дип тә атап була (проблемалы ситуацияләрдән чыгу юлларын эзләү). Өченче “П”: мәгълүмат эзләү (киләчәк нәтиҗәне презентацияләү формасын һәм алымын сайлау. Укучылар бу этапта мәгълүмат эзлиләр, җыялар, тәртипкә китереп анализлыйлар; укытучы белән киңәшләшеп, киләчәк нәтиҗәне презентацияләү

формасын һәм алымын сайлыйлар; әзерлек һәм планлаштыру эшенә үзбәя бирәләр. Бишенче “П”: проектны яклау, проект эшчәнлегенең нәтиҗәләрен бәяләү этабы. Укучылар проектны презентациялиләр, башкаларны эш нәтиҗәләре белән таныштыралар, сорауларга җавап бирәләр, эшчәнлекләренә үзбәя бирәләр. Укытучы проект белән җитәкчелек итү барышында төрле рольләргә керергә тиеш була: эшне оештыручы консультант-киңәшче; вакытны дөрес бүлергә өйрәтүче җитәкче; хаталарын һәм җитешсезлекләрне күрсәтүче, сораулар бирүче; башкарылган эшне анализлаучы эксперт- тикшерүче. Проект эшенә ата-аналарны да җәлеп итү бик отышлы, ата-ана бала тормышында актив катнаша башлый. Проект эшчәнлегенә йомгак ясаганда, түбәндәге сорауларны биреп була: Проект эшендә нәрсәләр кызыклы булды? Аеруча нәрсә ошады? Нинди яңалыклар белдең? Бу теманы өйрәнүне дәвам итәр идеңме? Киләчәктә нинди темларга проект эшләре эшләр идең? һ.б.

Укыту тәҗрибәсенә нигезләнеп, төрле сыйныфларда укучыларга тәкъдим ителгән проект эшләре темалары белән таныштырып үтик: минем гаиләм (стенд); авазлар һәм хәрефләр (рәсемле таблица); килеш кушымчалары (ярдәмлек); милли киемнәр (презентация); татар һәм рус халыкларының бәйрәмнәре (мәкалә); туган ягыбызның истәлекле урыннары (доклад); безнең шәһәребез ( презентация); татар теленең үзенчәлекләре (чагыштырма схемалар); синоним сүзләр (сүзлекчә) һ.б. Югары сыйныфларда исә темалар тагын да катлаулана төшә: якташ язучыларыбыз (доклад –презентация); татарларның килеп чыгышы (альбом, мәкалә); сүзләр тарихы (сүзлекчә); татар телендә кушма җөмләләр (ярдәмлек); алынма сүзләр (доклад –презентация) һ.б.

Шуны дә ассызыклап үтәргә кирәк дип саныйбыз: татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә проектлар методын куллану укучыларның иҗади сәләтен устерүгә этәргеч булып тора. Укучыларда яңа проектлар эшләү теләге туа һәм фәнгә карата кызыксыну арта. Иҗади эшчәнлек тәҗрибәсенә ия булган саен укучыларның белем сыйфаты да үсеш ала.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, проект технологиясе уку мәсьәләсен чишүгә юнәлтелгән гамәли характердагы иҗади биремнәрне үз эченә ала. Аның төп максаты – укучыларда кызыксыну уяту һәм аерым бер темага багышланган проект эше аша белемнәрне реаль аралашуда кулланырга өйрәтү. Проект эшен башкару барышында укучылар иҗади мөмкинлекләрен ачып бирү, мөстәкыйль рәвештә фикер йөртү, үзара хезмәттәшлек итү кебек күнекмәләргә ия булалар.

### Әдәбият

1. Донецкая О.И. Интернет-технологии в обучении иностранным языкам. – Казань: Каз.гос.ун-т, 2009. – 79 с.

2. Камаева Р. Татар теленә өйрәтүдә заманча педагогик технологияләр //Мәгариф, 2014. - №11; № 12.

3. Кашлев С.С. Современные технологии педагогического процесса. – Мн.: Университетское, 2000. – 95 с.

4. Полат Е.С., Бухаркина М.Ю. Современные педагогические и информационные технологии в системе образования: учеб.пособие для студ. высш. учеб.заведений. – М.: Академия, 2007. – 368 с.

## ДӘРЕСЛӘРДӘ МУЛЬТИМЕДИА ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕН КУЛЛАНУ

Хәйруллин И.Р.
Казан шәһәре Киров районының "8 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе"
Ilhamqazan76@mail.ru

**Аннотация. В** статье рассматривается использование мультимедийных технологий на уроках.
**Ключевые слова**: презентация, слайды, компьютерная технология, мультимедиа.

Заманча компьютер технологиясе белем бирү процессын үстерү чен гаять зур мөмкинлекләр бирә. К. Д. Ушинский билгеләп үткәнчә, балаларның табигате күрсәтмәлелекталәп итә. Хәзер бу схема, таблица һәм рәсемнәр генә түгел, ә балалар табигатенә якын булган уен, хәтта фәнни-танып белү дә булсын. Мультимедиа - ул тцрле дщреслщрдщ беле малу чарасы. Ул кызыксынучанлыкны, коммуникатив сәләтләрне үстерүгә, фактик белемнәрне туплау күнекмәләрен алуга ярдәм итә, шулай ук мәгълүмати грамоталылыкны арттыруга ярдәм итә. Слайд, презентация яки видеопрезентация кебек мультимедиа чаралары күп вакыт дәвамында куллану мөмкинлеген бирә. Компьютер хәзерге вакытта тавыш һәм видеоны үзгәртергә, шул исәптән анимация ярдәмендә бердәм мультимедиа- презентацияне булдырырга ярдәм итә. Уку-укыту процессында күрсәтмә чараларын тиешенчә куллану укучыларның күзәтчәнлеген, игътибарын, сөйләмен, фикерләвен үстерүдә мөһим роль уйный.

Мәктәптә компьютер технологияләренең уку процессына кертүнең киләчәге – башлангыч чорда ни дәрәҗәдәуйланылып кертелүенә турыдан-туры бәйле.

Беренче адым. Төрле фәннәрдән медиатека булдыру. Һәрбер мәктәптә төрле дисклар бар, аларны үзөйрәткеч, белешмәлек буларак файдаланып була. Дәреснең эчтәлеген дөрес билгеләп, әзер дәресләрне бик уңайлы итеп файдаланырга, ә алар хәзер интернет битләрендә бик күп.

Укытучының үзе тарафыннан төзелгән презентация, компьютер дәресләре бигрәк тә укучыларда зур кызыксыну уята.

Нәтиҗә: дәрес нинди генә катлаулы булмасын, темасы кызыксыз булса да, материалны тавышлы һәм башка эффектлар белән тәкъдим ителсә, укучылар кызыксынып укуга омтылырлар.

Икенче адым. Укытучының дәрескә презентация ясау технологиясен үзләштерүе. Әлеге дәресләрдә Power Point ярдәмендә уңышлы башкарып була. Компьютер дәресләрен проектлау календарь-тематик планда темаларны билгеләп чыгудан башларга.

Шул ук вакытта өйрәнелә торган материалның эчтәлеге, уку йортында компьютер, программа һәм аудио-видео чараларның булуы; һәр баланың психологик һәм социометрик характеристикасы, компьютер чараларының төрләрен чиратлаштыру зарурлыгы һ.б исәпкә алына.

Компьютерны куллану тикшерүне көчәйтергә һәм тирәнәйтергә ярдәм итә. Моның өчен укытучы тарафыннан уен яки авторлык программасы эшләнелә.

Нәтиҗә: дәрес темасы буенча презентация яңа материалны аңлату барышында укытучыга тактага язудан азат итә һәм ныгытуга күбрәк вакыт сарыф ителә.

Өченче адым. Мультимедияле программа чаралары белән эшләү күнекмәләрен укучыларның үзләштерүе. Дәресләрдә укучыларның танып-белү эшчәнлеген активлаштыру алымнарының берсе – китап белән эшләү, ә компьютерда эшли белү – иң кирәкле эш төрләренең берсе. Технология проект формаларында үзләштерелә. Хәтта башлангыч сыйныф укчылары да гади проектны Mickrosoft Power Pointта башкара ала. Проект эшчәнлегендә укучы үз вазифасын аңлый – үзләре үзләштергән технологик алымнарның башка әһәмиятле якларын ача. Укучы кирәкле предмет эчтәлеген үзләштергәндә, сәләтне үстерү максатын куя, адымлы гамәлләр планын төзи, аннары аны эш слайдларында тормышка ашыра, ниһаять, нәтиҗәне һәм аңа китергән юлын анализлый.

Нәтиҗә: мультимедиа программа чаралары белән эшләү күнекмәләрен факультатив дәресләрдә яки кече төркем белән түгәрәкләрдә, иң яхшысы – дәрестән тыш вакытта формалаштырырга. Нәкъ менә шушы укучылар, алга таба үзләштерелгән программаларны кулланып, башка сыныф укучыларын кызыксындыра алалар, чөнки әлеге программа чаралары минималь чыгымнар белән мөмкин кадәр күбрәк уку мәгълүматын алырга мөмкинлек бирә.

Мультимедиаль дәресләр түбәндәге дидактик мәсьәләләрне хәл итәргә булыша:
- предмет буенча база (башлангыч) белемнәрне үзләштерү; - үзләштерелгән белемнәрне системалаштыру; - үз-үзеңне тикшерү күнекмәләрен формалаштыру; - укуга кызыксындыру формалаштыру; - уку материалын үзләштерүдә укучыларның мөстәкыйль эшләү күнекмәләрен үстерүдә укыту-методик ярдәм күрсәтү.

Дәрестә мультимедиа технологиясен кулланганда, дәрес структурасы тамырдан үзгәрми, бәлки, аларның вакытлыча билгеләмәләре генә үзгәреш кичерә. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: кызыксындыру этабы бу очракта арта һәм танып-белү йөкләнешенә ия. Белем алуның уңышлы булуы өчен төп шарт: укучыларда җитешмәгән белем-күнекмәләрен арттыруда иҗади эшчәнлекләре өстендә эшләргә кирәк.

**Әдәбият**

1. А. А. Гин. Приёмы педагогической техники: Пособие для учителя. М.: Вита – Пресс, 2005 г.

2. Актуальные научные вопросы и современные образовательные технологии: сборник научных трудов по материалам Международной научно-практической конференции, 28 июня 2013 г.: в 7 частях. Часть 5; М-во образования и науки РФ. Тамбов: Издательство ТРОО «Бизнес – Наука. Общество», 20213 г.

3. Е. Н. Степанов. Личностно-ориентированный подход в работе педагога. М. , 2006г.

# ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫ ӨЧЕН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ТӨЗЕЛГӘН ДӘРЕСЛЕКЛӘРДӘ ТОПОНИМИК МАТЕРИАЛНЫҢ КУЛЛАНЫЛЫШЫ

Һадиева Г.К., Кузьмина Х.Х.
Казан федераль университеты
gul-khadieva@yandex.ru, shirmanx@yandex.ru

**Аннотация.** Топонимическое образование в общеобразовательных организациях напрямую связано с вопросом формирования у учащихся национального самосознания, так как изучение названий населенных пунктов, городов, участие в процессе выяснения их этимологии, выполнение проектных работ о родном крае во внеклассных мероприятиях являются средством воспитания патриотизма, уважения к своему народу, культуре, истории. В статье представлен обзор учебников на татарском языке для общеобразовательных организаций, действующих на сегодняшний день при обучении родному (татарскому) языку, с целью уточнения степени использования топонимического материала.
**Ключевые слова:** татарский язык, собственные имена, топонимический материал, микротопоним.

Гомуми белем бирү оешмаларында туган (татар) телне аерым дисциплина буларак өйрәнү, башлангыч сыйныфларда башланып, урта һәм югары сыйныфларда системалы һәм эзлекле рәвештә дәвам итә. Укучылар, башлангыч сыйныфлардан башлап, туган (татар) телнең һәр бүлеге хакында мәгълүмат алалар. Алга таба әлеге мәгълүмат һәр сыйныфта тулыландырыла һәм яшь үзенчәлекләреннән чыгып, катлауландырыла: белем бирүнең эзлеклелеге һәм үстерешле булуы тәэмин ителә. Шуңа нисбәтле рәвештә, башлангыч сыйныфларда ялгызлык исемнәр, аерым алганда кеше исемнәре (антропонимнар), географик атамалар белән танышкан укучылар 5 нче сыйныфта «Морфология» бүлегенең «Исем» темасын өйрәнү барышында ялгызлык һәм уртаклык исемнәр турында белемнәрен ныгыталар һәм әлеге максатка буйсындырылган күп төрле күнегүләр башкаралар [6]. Шул ук вакытта әлеге теманы ачу өчен дәреслектә топонимик материалны гамәли куллану өчен тәкъдим ителгән күнегүләр дә тәкъдим ителгән. Мисал өчен, дәреслекнең 69 нчы битендә түбәндәге күнегү бирелә:

126 нчы күнегү. Уйлап әйтегез. Бирелгән атамаларга туры килгән ялгызлык исемнәрне языгыз.

*1. Шәһәр исемнәре: ... 2. Авыл исемнәре: ... 3. Елга исемнәре: ... 4. Район исемнәре: ... 5. Урам исемнәре: ...*

Әлеге күнегүне башкаруга ярдәмлек буларак Татарстан Республикасы топонимнарының электрон каталогын яки географик картаны тәкъдим итәргә мөмкин. Бу, үз чиратында, укучыларны татар телендәге электрон чыганаклар

белән таныштыру чарасы булып тора һәм аларда материал белән эшләү күнекмәләре формалаштыра.

Дәреслектә башка ялгызлык исемнәр, аерым алганда топонимнар турында мәгълүмат күзәтелми. Топонимик материал, аеруча Казан шәһәре атамасы кергән текстлар дәреслектә башка темаларны өйрәнү барышында шактый еш кулланылуы белән үзенчәлекле. Мисал өчен, дәреслекнең 64 нче битендә Кошәриф мәчете турында вакытлы матбугаттан алынган өзек тәкъдим ителә. Әлеге өзектә өлешчә Казан шәһәре, Кошәриф мәчете тарихы бәян ителә. Тексттан соң бирелгән биремнәр арасында Казан шәһәре, Кошәриф мәчете тарихы буенча сораулар тәкъдим ителә: *Казан шәһәренә кайчан нигез салынган? Колшәриф кем булган? һ.б.*

Сорауларга җавап бирү барышында укучыларга, яшь үзенчәлегеннән һәм әзерлек дәрәҗәсеннән чыгып, риваять-легендалар, тарих турында әдәбият тәкъдим итү уңышлы.

Татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен төзелгән 6 нчы сыйныф дәреслегендә топонимик материал, нигездә, башка темаларны өйрәнү барышында мисал буларак кулланыла [7: 9-10]. Бары тик «Исем»не ныгытып кабатлау темасында гына географик атамаларны ялгызлык исемнәр буларак билгеләүгә юнәлдерелгән күнегү тәкъдим ителә:

*16. Укыгыз.*

*1. Безнең сыйныф укучылары «Ялкын» журналын яратып укый. 2. Казанда балалар өчен «Сабантуй» журналы чыга. 3. Чистай шәһәрендә «Восток» сәгать заводы төрле механизмнар җитештерә. 4. Алабуга, Чаллы, Чистай шәһәрләре һәм күп кенә авыллар Кама елгасы буена урнашкан. 5. Казансу елгасы Иделгә койган урында киңәеп китә. 6. «Сәйяр» театр труппасы Г.Кариев һәм С.Гыйззәтуллина-Волжская тарафыннан оештырыла.*

*Биремнәр:*

*Уртаклык һәм ялгызлык исемнәрне әйтегез. Алар ничек язылган? һ.б.*

Дәреслектә тәкъдим ителгән күнегү, безнең фикеребезчә, шактый уңышлы, чөнки, бер яктан, күнегү ялгызлык исемнәр турында белемнәрне ныгыту чарасы булса, икенчедән, укучыларда бер дисциплина, безнең очракта, татар теле дәреслеге эчендә башка өлкәләрдән дә белем бирүе белән үзенчәлекле.

Татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен төзелгән 7 нче сыйныф дәреслеге эчтәлеге гади җөмлә синтаксисына басым ясалганлыктан, топонимнар аерым лексик берәмлекләр буларак өйрәнелми, топонимик материал исә шулай ук мисал буларак чагыштырмача аз кулланыла [5].

Татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен төзелгән 8 нче сыйныф дәреслеге кушма җөмлә синтаксисын өйрәнүгә багышланган. Шул сәбәпле, әлеге дәреслектә топонимик материалны куллану 7 нчы сыйныф дәреслегендәге топонимнарны куллану дәрәҗәсе белән тәңгәл [4].

Татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен төзелгән 9 нчы сыйныф дәреслегендә синтаксис, сөйләм культурасы һәм тел мәсьәләләренә басым ясала, тәкъдим ителә торган мәгълүмат катлаулылана, тирәнәя [2].

Әлеге дәреслекнең сөйләм культурасына багышланган бүлегендә микротопоним термины кулланыла: *«Алда китерелгән кульязмадан өзекне дәвам итик: Ягодный бистәсе үзе Ягодная Поляна авылыннан барлыкка килгән. Авылның исеме исә Ягодная Поляна (Җиләкле Алан) микротопонимыннан...»* [2: 92].

Өзектән аңлашылганча, китерелгән текстта бистә тарихы бәян ителә. *Микротопоним* термины текст эчендә генә бирелә, дәреслектә терминга аңлатма, аерым урын бирелми.

Дәреслекнең «Тел һәм тарих» бүлекчәсендә топоним термины кергән текст очрый: *«Халыкның борынгы исемнәрен (этнонимнарны), этнонимга нигезләнгән топонимнарның кайда саклануларын өйрәнү дә теге яки бу халыкның борынгыдан яшәгән урыннарын ачарга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, Татарстан һәм Башкортстан территориясендә Сөн (башкортча: Һөн) елгасының б.э.к. күп мең еллар агып ятуы сөн/һөн (русча хунны яки гунны) дигән халыкларның борынгыдан ук монда яшәгәнлекләре турында сөйли»* [2: 98].

Әлеге өзек туган (татар) тел дәресләрендә топонимик материалны куллану үрнәге дә булып тора. Безнең фикеребезчә, тел дәресләрендә мондый төр тарихи текстларны өйрәнүне башка галимнәрнең әлеге мәсьәлә буенча язылган фәнни мәкаләләре белән таныштыру белән бергә бирү дә уңышлы. Бу очракта, әлбәттә, укучыларның яшь үзенчәлекләрен һәм сыйныфның әзерлек дәрәҗәсен исәпкә алу таләп ителә.

Әлеге тексттан соң, дәреслектә укучыларга түбәндәге сорауга җавап бирү бирем буларак тәкъдим ителгән: *«Халык исемнәре һәм халык исеменнән ясалган топонимнар халыкның борынгы чорларда яшәгән җирләрен билгеләргә ярдәм итә алалармы?»*.

Дәреслекнең «Тел гыйлеменең әһәмияте һәм төп бүлекләре» бүлекчәсендә татар теле тармакларына аңлатма бирелә, ономастика һәм аның бүлекләре хакында кыскача мәгълүмат тәкъдим ителә. Теоретик өлештән соң, бирем буларак, «Белемнәрегезне тикшерегез» дигән күнегү кысасында укучыларга *«Топонимика фәне нәрсәне өйрәнә һәм аның нинди бүлекләре бар?»* дигән сорауга җавап бирү тәкъдим ителә. Безнең фикеребезчә, әлеге күнегүне эшләү барышында тел белеме сүзлеге белән эшләү алымын куллану да урынлы булачак.

Дәреслекнең 124 нче күнегүе, географик атамаларны, аерым алганда гидронимнарны, өйрәнүгә, әлеге өлкә буенча белемнәрне ныгытуга багышланып, туган (татар) тел дәресләрен топонимик материалны файдалануның яхшы үрнәге булып тора:

*124 нче күнегү. Географик атамалар турындагы ике текстны укыгыз. Гидронимнарны (су исемнәрен) язып алыгыз, мәгънәләренә аңлатма бирегез. Соңыннан үзегезнең тирә-яктагы су, авыл, чокыр, болын, тау, урман атамаларын язып, аларга аңлатмалар бирегез.*

Бу күнегү, җирле топонимнарга басым ясап, укучы шәхесенә индивидуаль якын килүне гамәлгә ашыруы белән дә әһәмиятле. Күнегүдән соң

мөстәкыйль нәтиҗә ясау өчен бирелгән биремнең түбәндәгедән гыйбарәт булуы моны тагын бер мәртәбә раслый:

*Бирем. Үзегезнең төбәктәге географик атамаларны кертеп, «Туган авылым» дигән темага инша языгыз.*

Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларының 10 нчы һәм 11 нче сыйныфлар өчен төзелгән дәреслек бер-берсен дәвам иткән ике сыйныф материалын үз эченә ала. Дәреслек ике ел дәвамында югары сыйныф укучылары өчен уку әсбабы булып тора.

Дәреслек тулысынча туган (татар) тел тарихы, телнең халык мәдәнияте белән үзара бәйләнешенә, бер-берсенә тәэсир итү процессын ачыклауга, төрки этнонимикага багышлануы һәм шактый саллы мәгълүматка ия булуы белән үзенчәлекле. Дәреслектә этнонимика һәм топонимикага зур урын бирелгән: топонимика ономастика фәненең бер тармагы буларак ачыла, аның тармаклары хакында укучыларга нәзари мәгълүмат бирелә [3: 142-143]. Теоретик мәгълүматның шунда ук гамәли эш – күнегүләр – белән ныгытылуы уңышлы. Мисал өчен, топонимика турында мәгълүмат бирелгәннән соң, дәреслектә күнегү буларак топонимик материал тәкъдим ителә:

*108 нче күнегү. Топонимнарның этнонимнардан гына түгел, ә башка сүзләрдән дә ясалуын күз алдына китерү өчен Азнакай топонимы турындагы өзекне укыгыз, аның нигезе турында әңгәмә корыгыз.*

Югарыда тәкъдим ителгән күнегү, ономаст Г.Ф. Саттаров авторлыгындагы Азнакай шәһәре турында ике битлек мәгълүматтан гыйбарәт булып, топоним турында гына мәгълүмат биреп калмыйча, укучыларда топонимнарга этимологик анализ ясау күнекмәләре дә формалаштыра. Әлеге күнекмә аларга фәнни эшләр, проект эшләре язу барышында әһәмиятле.

Дәреслектә теоретик мәгълүмат эчтәлекле топонимик материал белән гамәли ныгытылып бара. Дәреслектә бирелгән түбәндәге күнегүләр топонимнарга бай, топонимнар һәм аларның төрләре хакында белемнәрне ныгытуга юнәлдерелгән эчтәлекле текстлардан гыйбарәт:

*110 нчы күнегү. Укыгыз. Топонимнарның төрләрен әйтегез* [3: 149].

*111 нче күнегү. Топонимнарның этимологиясен төрлечә аңлатырга мөмкин дигәнне исбатлау өчен, Минзәлә топонимының этимологиясе турындагы өзекне укыгыз, әңгәмә үткәрегез* [3: 149-151].

Күнегүләр рәвешендә бирелгән топонимик материалларның, нигездә, Г.Ф. Саттаров хезмәтләреннән алынуы аеруча мөһим, чөнки укучыларны кызыксындыру өчен иң элек фактик материалга бай күнегүләр сайлау зарур.

Татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен төзелгән туган (татар) тел дәреслекләре белән бергә топонимик материалны туган (татар) тел дәресләрендә куллануда Г.Р. Галиуллина һәм М.М. Шәкүрова тарафыннан туган (татар) тел предметы буенча татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы 5-11 сыйныф укучылары өчен төзелгән үрнәк программа аерым игътибарга лаек [1]. Безнең фикеребезчә, үрнәк программада этномәдәни компетенциягә махсус урын бирелү топонимик материалны туган (татар) тел дәресләрендә куллануга шактый мөмкинлек бирер иде, чөнки

топонимик материал турыдан-туры халыкның үткәнен, мәдәниятен, яшәү рәвешен специфик чагылдыруы, бүгенге көндә актуаль булган укучыларда ватанпәрвәрлек хисләре тәрбияләүгә өлеш кертүе белән этномәдәни компетенцияне гамәлгә ашыру белән бәйле.

Шул рәвешле, югарыда язылганнарга нигезләнеп, гомуми белем бирү оешмалары өчен төзелгән татар теле дәреслекләрендә топонимик материал, нигездә, телнең төрле тармакларын өйрәнү барышында текстларда һәм күнегүләрдә чагыштырмача сирәк кулланыла. Югары сыйныфлар (10-11 сыйныфлар) өчен төзелгән дәреслек исә, уку-укыту максатына һәм дәреслекнең эчтәлегенең мәгънәви юнәлешенә бәйле рәвештә, топонимик материалга шактый бай булуы белән үзенчәлекле. Бу шулай ук топонимиканың шактый катлаулы өлкә булуы һәм әлеге тармакны аңлау, танып-белүдә яшь үзенчәлекләренең мөһим роль уйнавы һәм укучыларның махсус әзерлеге таләп ителү белән дә аңлатыла.

## Литература


1. Галиуллина Г.Р., Шакурова М.М. Татар телендә укыта торган гомуми урта белем бирү оешмалары өчен «туган тел (татар теле)» фәненнән үрнәк программа (5-9 сыйныфлар) http://mon.tatarstan.ru/primernye_rabochie_programmy.htm (Мөрәҗәгать итү вакыты: 24.02.2021).

2. Зәкиев М.З.Татар теле. 9 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / М.З. Зәкиев, С.М. Ибраһимов. – Казан: Тат.кит.нәшр., 2015. – 135 б.

3. Зәкиев М.З Татар теле. 10-11 сыйныфлар: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы / М.З. Зәкиев, Н.В. Максимов. – Казан: Тат.кит.нәшр., 2016. – 334 б.

4. Зәкиев М.З.Татар теле. 8 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / М.З. Зәкиев, Н.В. Максимов. – Казан: Тат.кит.нәшр., 2015. – 159 б.

5. Максимов Н.В. Татар теле. 7 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Н.В. Максимов, Г.Ә. Нәбиуллина. – Казан: Тат.кит.нәшр., 2015. – 159 б.

6. Харисова Ч.М. Татар теле. 5 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Ч.М. Харисова, Н.В. Максимов, Р.Р. Сәйфетдинов. – Казан: Тат.кит.нәшр., 2015. – 207 б.

7. Юсупов Ф.Ю. Татар теле. 6 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Ф.Ю. Юсупов, Ч.М. Харисова, Р.Р. Сәйфетдинов. – Казан: Тат.кит.нәшр., 2015. – 175 б.

# ВЗАИМОДЕЙСТВИЕ КАЗАХСКОГО ЯЗЫКА С КЫПЧАКСКИМИ И ОГУЗСКИМИ ЯЗЫКАМИ В КАЗАХСТАНЕ

Шаймердинова Н.Г.
Евразийский национальный университет
nurila1607@mail.ru

**Аннотация.** Статья посвящена взаимодействию казахского языка с тюркскими языками Казахстана. В эпоху независимого Казахстана функциональный потенциал казахского языка как государственного языка расширился и укрепился во всех сферах жизнедеятельности. В Республике Казахстан в настоящее время проводится гармоничная языковая политика владение тремя языками: казахским, русским, английским; создание условий для развития языков других народов, проживающих в Казахстане.

Автор статьи, на базе проведенных проектных исследований, раскрывает взамодействие и взаимовлияние казахского языка с некотоырми кыпчакскими и огузскими языками, в частности, с турецким, гагаузским и крымско-татарским. Языковые контакты казахского языка с указанными языками рассматриваются в фонетической, лексико-семантической аспектах, определяется языковой «микс», смешение в речевой деятельности коммуникантов, что характерно для языковой ситуации Казахстана.

**Ключевые слова:** казахский язык, взаимодействие, языковые контакты, фонетические особенности, лексические вкрапления, турецкий, гагаузский, крымско-татарский, языковая ситуация.

После обретения суверенитета в Республике Казахстан в стране кардинально изменилась языковая политика государства, направленная на развитие казахского языка как государственного языка и полноценного его функционирования во всех сферах деятельности, русского языка как языка межнационального общения, а также создание условий для развития языков других народов, проживающих в Казахстане. При этом сфера употребления государственного казахского языка значительно расширилась. За годы суверенитета выросло новое поколение людей, которые достаточно хорошо владеют казахским языком, 80-90 % садиков, школ, колледжей и вузов с казахским языком обучения. Казахский язык стал ведущим языком науки, здравоохранения, СМИ, сервиса, документации и законотворчества, внутренней и внешней политики государства. Чтобы быть успешным в социальном и в карьерном росте русские, немцы, поляки, татары, киргизы, башкиры, азербайджанцы, турки и многие другие народы, живущие в Казахстане, изучают и владеют казахским языком, хорошо знают казахскую культуру. Некоренным этносам Казахстана не нужно переводить казахские лексемы такие, как *астана, Ақорда, мәжліс Бәйтерек, хабар, әкім, акимат, наурыз, мектеп, нан, сүт, су, коже, қазы, той* и т.п., поскольку они прочно вошли в

повседневную коммуникацию, в активный лексический фонд всех народов страны.

Взаимодействие языков и культур народов Казахстана, в т.ч. казахского языка, нами были исследованы на базе двух проектов: 1) международного "Взаимодействие истории, культуры, языка тюркских народов в пост-советском Казахстане", осуществленного казахстанскими тюркологами совместно с учеными Берлинского Свободного университета и университета Франкфурт- на Майне им. Гёте (2015 – 2017 гг.);республиканского «Сохранение и развитие этнического культурного наследия кыпчако-огузских народов в условиях современного Казахстана» (2018 – 2020гг.). В рамках указанных проектов были проведены специальные социокультурные исследования истории, культуры, языка тюркских народов, проживающих в Казахстане; полевые экспедиции в южные, восточные и северные регионы Казахстана, интервьюирование респондентов, запись и документирование разноязычных текстов, анкетный опрос, создана базы данных. В республиканском проекте мы особое внимание уделили взаимодействию казахского языка с кыпчакскими и огузскими языками, и в данной статье излагаются некоторые аспекты этих языковых контактов. Кыпчакские и огузские народы в Казахстане – самые многочисленные тюркские диаспоры в республике, у которых есть национально-культурные центры, представители которых активно сотрудничают в Ассамблеи народов Казахстана, избраны в местные выборные органы, мәслихаты и даже в нижнюю палату высшего законодательного органа Мәжіліс Республики Казахстан.

Огузские народы в Казахстане представлены турками, гагаузами, азербайджанцами, туркменами, кыпчакские народы – татарами, башкирами, кумыками, каракалпаками, крымчаками, балкарами и др. Среди огузских народов – одной из многочисленных диаспор, диаспора турков, миграция которой, с одной стороны, складывалась исторически из-за депортации в годы Отечественной войны народов Кавказа в Казахстан, в т.ч. турков-ахыска, турков-лазов, турков- хемшил; с другой стороны, в современном Казахстане широко продолжается миграция турков из Турции. Общеизвестно, что именно Турция, одна из первых в 1991 году признала Казахстан независимой суверенной страной. С тех пор политические, экономические, культурно-туристические, научные, образовательные, личностные связи Казахстана и Турции имеют самый тесный характер[2, 139].

На речевую деятельности турков, живущих на юге Казахстана, влияние оказывает языковая система казахского языка в фонетическом, лексическом аспектах, и в меньшей степени в грамматической подсистеме. **Казахский и турецкий язык** относятся к разным языковым группам, однако в языковых контактах имеются лексические тождества и фонетические различия, обусловленные типологически различием кыпчакских и огузских языков, что подтверждает иллюстративный материал. Зафиксированные в речевой деятельности информантов фонетические различия казахского и турецкого языков отражают типологические закономерности кыпчакских и огузских

языков, которые складывались исторически в структуре тюркского слова. К ним относятся различия в анлауте – смычно-щелевой *ж* в казахском (*jıl, juldız, jılan, jol, jas, jat, je, jürek, joldas, jer*) и йотированный *й* в турецком ( *yıl, yıldız, yılan, yol, yaş, yat, ye, yürek, yoldaş, yer*); губно-носовой *м* в казахском (*men, murın, mıy, mın*) и губно- взрывной *б* в турецком (ben, burın, beyin, bin); глухие *к, т* в казахском ( köz, köl, kerek, kün, könil, kök, kel, kör, kül jb; til, tört, tis, tiri, teniz, temir, taw, tar, tur, tök, tik) и звонкие *г, д* в турецком (*göz, göl, gerek, gün, gönül, gök, gel, gör, gül vb; dil, dört, diş, diri, deniz, demir, dağ, dar, dur, dök, dik* ); в ауслауте – щелевые *с, ш* в казахском (*tas, bes, qarsı, qus, kümis, qıs, qıs, kisi, as, basqa*; *üş, agaş, üşin, küş, iş, aş, şıgar, uş*)и смычно-щелевой *ч* в турецком (*taş, beş, karşı, kuş, gümüş, kış, kişi, aş, başka; üç, ağaç, için, güç, iç, aç, çıkar, üç*). Кроме того, в турецком языке функционируют фонемы *в* и *ф*, не характерные для казахского языка.

В турецкой речи информантов также отмечаются активные лексические заимствования из казахского языка. Например: *Bugün* ***toyga*** *bardım.- Сегодня ходил на свадьбу.* Вместо турецкого *düğün (дуюн)* респондент использует казахское слово *той. Magazindan nan, süt, üyge tamak getirdim, akçam (dengi) bitti. – Из магазина домой принес, хлеб, молоко, домой продукты, деньги закончились.* Заимствовано слово *магазин*, которое в реалиях сельской жизни Казахстана является универсальным торговым местом, где можно купить все. В турецком языке названия магазина зависит от функционального назначения (продуктовый/непродуктовый), если в значении - продуктовый, то говорят *маркет*.

В речевой коммуникации казахстанских турок казахские лексемы заменяют турецкие слова, т.е. наблюдается непосредственные языковые вкрапления. Например, казахское слово *үй* употребляется вместо турецкого *ev (эв)*; *апай, ағай* – вместо (teyze и dayı); *тенге* или *ақша* – вместо турецкого *пара*. В последнем случае казахстанские турки используют казахские лексемы в обозначении денег, потому что *para* в современном казахском языке имеет отрицательное значение: *пара алу* "брать взятку", *пара беру* "давать взятку", поэтому в турецкой речи наблюдается казахское вкрапление, что подтверждает влияние казахского культурного кода на носителей турецкого языка.

Исследуя взаимодействие казахского языка с языком турецкой диаспоры в настоящее время нами выявлены казахские лексемы в разных сферах турецкой речи: ***это и названия пищевых изделий и напитков*** *бешбармак* – казахское национальное блюдо из мяса, *касма* – лапша (каз. кеспе), *тохач* – бауырсак (каз. тоқаш), *кумус* – кисломолочный напиток из кобыльего молока (каз. қымыз) и др.); ***названия домашней утвари, видов одежды и обуви*** *тахия* – тюбетейка (каз. тақия), *мәс* – ичиги (каз. мәсі); ***ботанические и аграрные термины*** (*қызылша* – свекла (каз. қызылша), *пияз* – лук (каз. пияз), *карагач* – вяз (каз. қарағаш), *бүлдүргүн* – костяника (каз. бүлдірген), *масах* – мелкие корни, оставшиеся после сбора сахарной свеклы, катофеля (каз. масақ), *чабан* – пастух (каз. шабан) и другие; ***наименования музыкальных инструментов*** *домбура* – казахский народный инструмент (каз. домбыра); ***а также лексемы,***

***обозначающие традиции, обычаи*** *кокпар* – конные состязания («козлодрание»), *бәйге* (скачки) *беташар* – казахская традиция открывания лица невесты (каз.беташар), *төр* – почетное место в доме для гостей (каз. төр), *бата* – благословение уважаемых людей и т.д. [6, 496].

Во время полевых исследований нашей исследовательской группой была зафиксирована речь турчанки ахыска из села Тургень Алматинской области, где информант активно используют указанные выше казахские этнографические термины *той, дәм-түз, бата, төр.*:

1. *Bizim* ***toylarımız*** *edändä qazax ta urus ta nemec ta gälir.* 'На наши ***тои*** приходят и казахи, и русские, и немцы*'*.

2. *Qazax aγajïmlarïmïzï çaγrijerux gälir* ***däm tus*** *tat dejerlär.* 'Мы приглашаем наших братьев казахов и они приходят отведать хлеба-соли*'*. Информант употребляет казахское ***дәм-тұз*** вместо турецкого *tadına tuzuna.*

3. *Onlar bizä* **dua batasini** *verijer gedijerlär.* 'Они делают для нас дуа, бата*'*. ***Дуа*** (арабо-исламский термин) – духовное пожелание, обращенное к Всевышнему. ***Бата*** - у казахов благословение: напутствие молодежи, благословение хозяевам дома, новорожденного, новобрачных, путников и всех, кто просит удачи в новых начинаниях.

4. *Hörmät edijerlär bizlärä* ***törlä*** *dijer türk aγajïndar* ***törlä*** *ǰoγarï.* 'Почитают нас, проходите выше, говорят, к төру (почтенное место в доме)*'*. ***Төр*** – место для гостей, заслуженных людей, старейшин семьи [6, 500].

Анализ речи и поведения информанта показывают, что турки ахыска, департированные в Казахстан во время Великой Отечественной войны, сохранили с одной стороны, свою этническую культуру, с другой стороны, освоили и давно живут по обычаем и традициям казахов, знают и понимают казахский этикет и культурные константы окружающего ареала.

В процессе анализа турецкой речи других информантов также выявлены одновременные заимствования как с казахского, так и с русского языков, причем в речевую коммуникацию вставляются целые фразы и предложения: ***Şot na platu*** *verir misiniz?- Можете отправить счет на оплату (*вместо *Ödeme evrağı).* ***Mama, papa*** *geliyorlar (anne, baba)- Мама папа приезжают.* ***As bolsın*** *arkadaşlar!* ***Kop rahmet!****(afiyet olsun; çok teşekkürler).- Приятного аппетита, друзья! Большое спасибо!* ***Sau bolınız****, kendinize iyi bakın!(hosçakalın). - До свидания, берегите себя!* ***Salemetsiz be, kalınız kalay, bala şaganız kalay****, her şey yolunda mı?(merhaba, nasılsınız, çoluk çocuğunuz nasıl).- Здравствуйте, как ваши дела, как дети, все в порядке? Canım* ***pirivet, kak dela****?-* ***Ti doma?*** *(selam, nasılsın, evde misin?).- Душа моя, привет, как дела? Ты дома? Eşim* ***çudopeçkada tort pişirdi! Oçen vkusno****. Tadına bakar mısın? - Моя супруга испекла торт в чудопечке! Очень вкусно! Хочешь попробовать? (fırında kek, çok lezzetli)* [1, 159]. Все эти иллюстрации информантов представляют собой «микс», смешение турецкой, казахской и русской речи, и носители турецкого языка активно общаются на этом языке с казахами, русскими и между собой, прекрасно понимая друг друга. В речи коммуникантов отмечаются различные

виды интерференции, интеркаляции, характерные для языковой ситуации Республике Казахстан.

Нами также были проведены анализ языка гагаузов в Восточно-Казахстанской области, в их локальном проживании. Приведим аудиозапись речи жительницы села Романовка Кокпектинского района Восточно-Казахстанской области Стефаниды Николаевны Виничук [7, 78]:

***Аудио текст №1.***

*-Nikogo netu. Na rıbalku uehali vse. - Никого нету. На рыбалку уехали все.*

*-Baba gitti. -Папа уехал. Папа кеттi.*

*-Baba gitti. Nu tak. Nu takiye dela. Aç salatayı. Aha. Koy. Balık pişti. Koy biraz ladım. Stolda süt çıkar. Salata çıkar. Aha. Nu davay. - Папа уехал. Ну так. Ну такие дела. Открой салат. Ага. Поставь. Рыба готова. Положи немного. Поставь на стол молоко. Салат поставь. Ага. Ну давай.*

***Аудио текст №2.***

*-Kim ba(r) evde?- Кiм бар үйде?*

*-Kimse yok. Yalnız.- Ешкiм жоқ. Жалғыз. -Никого нет. Одна.*

*-Ufakla(r) yok mu?- Маленьких нет? Ұсақ балалар жоқ па?*

*-Ufakla(r) yok. Kocam gitti. - Маленьких нет. Муж уехал. Ұсақ балалар жоқ. Күйеуiм кеттi.*

*-Aa...*

*-Sen hozyain da. Aa..Tet Nina gelmedi me? - Ты хозяйка да. Аа..Тетя Нина не пришла? Сен қожайынсың, ия. А... Тет Нина келмедi ме?*

*-Yok gelmedi. Kimseyi bilmisin. - Нет не пришла. Никого не знает. Жоқ, келмедi.*

*-Yok. - Нет. Жоқ.*

*-Ufakla(r) evde? Gelin evde? - Дети дома? Невеста дома? Ұсақ балалар үйде ме? Келiн үйде ме?*

*-Aa..*

*-Bugün subbota. Nu ladno togda. Davay. Poka. - Сегодня суббота. Ну ладно тогда. Давай. Пока.*

Аудиозапись показывает, что гагаузы в речи используют 3 языка – гагаузский, казахский и русский. Гагаузские лексемы: *день открытых дверей, нет, только маленький (р), муж не приходил, не приходил, уходил, уходил.* Казахские лексемы: *бар, ты, знаешь, ким, папа, бухта, сегодня рыба.* Русские слова: *Никого нету. В противном случае все в порядке. Ну так. Ну такие дела. Ну давай. ... тоже хозяин. Аа .. Тет Нина. ... суббота. Ну ладно давай. Пока.*

Рассмотрим некоторые языковые особенности аудиозаписей.

*Baba gitti* - респондент употребляет слово *отец* в его гагаузском варианте, по мнению В.В. Радлова, восходит к монгольскому *ава* в значении «отец, сын, брат, сын старого ребенка» [4, 167] (цитируется по Кайдарову и Оразову). В современных тюркских языках в азербайджанском, башкирском, каракалпакском, киргизском, татарском, туркменском, уйгурском обозначает предка по мужской линии.

*Stolda süt çıkar – Столға сүт шығар.* В предложении, с одной стороны, проявляется влияние русского языка, с другой - казахского: к русскому *stol*

говорящий добавляет казахскую флексию дательного падежа *-da*. Кроме того, вместо исходного падежа он использует дательный направительный падеж. Слово *çıkar* звук в анлауте характерен для огузских языков, тогда как в кыпчакских языках, в казахском языке употребляется звук š, отсюда в казахском языке слово *шығар.*

*Kim ba(r) evde? – Кім бар үйде? Ev* (*de* – аффикс винительного падежа) от древнеюркского *eb* "жилище" *(*ev*<eb)* сохранилось в современном гагаузском, турецком языках, исторически слово претерпело множество фонетических изменений: *е<ү* и *б<в//ф//й.* В кыпчаких языках, в казахском языке, как отмечено выше, обозначается лексемой *үй.*

*Ufakla(r) yok (Ұсақ балалар жоқ. Маленьких нет). Ufak* в гаагузском языке означает «маленький, мелкий», и оно тождественно значению данной лексемы из современного казахского языка. В толковом словаре казахского языка слово *ұсақ* означает: 1. *Уақ, кішкене, ірі емес.* Ұсақ тастар сайдың түбіне қарай домалай жөнелді. 2. *Қой-ешкі, уақ мал.* 3. *Тиыннан құралған майда ақша.* Атасы ұсақ бір сомды қағаз бір сомға орап немересіне берді. ‣ Ұсақ адам – біреудің мейрейін көре алмайтын, іші тар кісі. ‣ Ұсақ сөз – өсек-аяң, пыш-пыш сөз [3, 686]. Таким образом, в толковом словаре указаны все лексико-семантические варианты прямого и переносного значения, из которых лексема *ufak/ұсақ* речи коммуниканта употребляется в значении «дети».

*Kocam gitti (Күйеуім кетті. Муж уехал.)* Информант употребляет гагаузское слово *koca* в значении «очень старый, престарелый муж, супруг», в этом же значении слово употребляется и в турецком языке.

В процессе исследования нами также выявлены лексемы северного диалекта **крымских татар**, которые употребляются в лексической системе казахского и других тюркских языков, т.е. заимствованы из речи крымских татар Казахстана, в ареале которых живут казахи. Нами сделана выборка лексем крмыско-татарских лексем в речи казахских коммуникантов, что подтверждается иллюстрациями ниже [8, 227].

*Бакърачь (медное ведро)***,** *в* казахском языке *бақыраш (ведро, ведерко).* Как считают исследователи, в некоторых тюркских языках слово употреблялось в значении «медный контейнер». В современном казахском языке слово диалектное и употребляется в основном, в западном Казахстане, например, в Атырауской области в значении «маленькая железная емкость для воды».

*Дегирмен (молотилка),* в казахском языке - *диірмен* (*жел диірмені, қол диірмені*). Значение слова восходит к древнетюркскому корню tek/teg/teg («приближаться,», «мелить», «прикасаться»), к которому присоединяется аффикс *-men.* Слово широко используется в тюркских языках в различных фонетических вариантах: турец. *değirmen*, азерб. *dagirman*, башк. *tirman*, кирг. *tegirmen*, узбек. *tegirman*, татар. *tigirman*, туркмен. *değirmen*, уйгур. tugman.

*Къуман (кувшин для омовения),* казахские слова *құман, құмған* обозначают кувшин для поливания воды на руки или посуда для кипячения чая

(ақ құман – диалект). Встречается в некоторых кыпчакских языках: кирг. *kumğan*, татар. *komğan*.

*Тава (сковорода, противень), казахское -таба.* Слово встречается во всех тюркских языках *tava* характерна для огузских и карлукских языков, в кыпчакских языках - *taba,* Считается, что в тюркских языках слово заимствовано из персидского языка tâve/tabe *«посуда для приготовления пищи», «плоский камень», «кирпич».*

*Челик (ведро),* в казахском языке - *шелек.* Возможно, также персизм, ибо в персидском языке çâlik означает «сталь», в турецком языке употребляется в также в значении *стали.* В крымско-татарском, казахском, киргизском, узбекском, уйгурском языках употребляется в значении ведра.

*Чёмучь (черпало, ковш),* в казахском языке - *шөміш* ( большой ковш для розлива). Значение слова восходит к древнетюркскому *çöm* в значении *впиться, спуститься вниз, вступить.* Слово употребляется во многих тюркских языках также в значении посуды: кирг. *çömüç*, татар. *çümiç*; узбек. *çömiç*, уйгур. *çömüç*.

*Элек (сито*), казахском языке - *елек.* По мнению А.Меметова, истоки слова находятся в древнетюркском языке, в где зафиксировано многозначное слово *el* , одно из которых означает «рука», отсюда *ele* – «что-то делать руками, руками выпирать, руками собирать», от *еле* образовалось производное слово при помощи аффикс-к, которое обозначает значение предмета [5, 89]. В современных тюркских языках лексема используется в следующих фонетических вариантах: турец. *elek*, азерб. *äläk*, башк. *iläk*, кирг. *elek*, узбек. *eläk*, татар. *iläk*, туркм. *elek*, уйгур. *ägläk*. Таким образом, сопоставительный анализ некоторых лексем крымско-татарского и казахского языков показывает, что они различаются фонетически, имеют общие истоки, в целом семантически тождественны и встречаются во многих кыпчакских, огузских, карлукских и других языках.

Резюмируя изложенное, следует отметить, что языковая ситуация в Республике Казахстан складывается из многоязычья, активного взаимодействия казахского государственного языка с русским языком, с языками других этносов, в т.ч. тюркских. В республике наблюдается взаимовлияние и взаимодействие казахского языка, казахской культуры на язык и культуры народов, проживающих в стране.

**Литература**

1. Абдрасимова А.Е., Жиембай Б.С. Казахские и русские заимствования в языке турецкой диаспоры Республики Казахстан // Вестник Евразийского национального университета имени Л.Н. Гумилева. Серия. Политические науки. Регионоведение. Востоковедение. Тюркология. – №1 (126)/2019. – С.157-163.

2. Жолдасбеков М., Шаймердинова Н.Г., Калдыбаев М.С., Каликов Р.К., Жиембай Б.С., Диханбаева А.Е. История, язык и этнокультура тюркских народов Казахстана. Монография. – Нурсултан: «Free Flight», 2020. – 237 с.

3. Қазақ тілінің сөздігі. Анықтамалық басылым. Жалпы редакциясын басқарған Телғожа Жанұзаков. – Алматы: Дайк-пресс, 1999. – 775 б.

4. Қайдаров Ә., Оразов М. Түркітануға кіріспе. – Алматы: Арыс, 2004. – 360 б.

5. Меметов А. Источники формирования лексики крымскотатарского языка. – Ташкент: Фан, 1988. – 196 с.

6. Сайын Ж. Лингвокультурные заимствования в разговорной речи турецкой диаспоры Казахстана// Сборник материалов Международной научно-практической конференции. «Современные проблемы тюркологии: язык - литература - культура» – М., РУДН, 2016. – С.496 -500.

7. Шаймердинова Н.Г. Тюркские народы Казахстана: гагаузы, их история, язык, традиции // Вестник КарГУ им. Букетова. – № 2 –2017. – С. 74-81.

8. Шаймердинова Н.Г. Жиембай Б., Абдрасимова А. Қазақстандағы Қырым татарлары тілінің ерекшеліктері // Туған жер идеясы және қоғамдық сананың жаңғыруы ғылыми конференциясының материалдарының жинағы. – Алматы, Arna-B баспасы, 2019. – 225-232 б.

9. Шаймердинова Н.Г. Татарская диаспора Казахстана: социокультурные аспекты//Материалы международной научно-практической конференции «Литература и худ.культура тюркских народов в контексте Восток-Запад». – Казань, КФУ, 2015. – С.590-601.

# СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ ТЕХНОЛОГИЯСЕ НИГЕЗЕНДӘ ЯЗУЧЫ ТЕЛЕН ӨЙРӘНҮ

Хөснетдинов Д.Х., Сагдиева Р.К.
Казан федераль университет
Domer1982@mail.ru

**Аннатоция.** В статье рассмотрены основные здоровьесберегающие технологии применяемые в школе. Раскрыты возможности их применения. Проведена классификация здоровьесберегающих технологий.

**Ключевые слова**: язык, метод, технология

Сәламәтлек – иң зур байлык. Укучыларның яшьтән үк сәламәт булып үсүе бик мөһим. Сәламәтлек әле ул авырмау гына түгел, үзеңне тыныч, гармонияле итеп хис итү; башка кешеләргә карата мәрхәмәтле, яхшы мөнәсәбәттә булу.

Сәламәтлек технологиясе – укучының сәламәтлеген саклауга һәм ныгытуга юнәлтелгән чаралар, алымнар, ысуллар системасы.

Күптөрле галимнәрнең хезмәтләрендә укыту ысулларының төрлечә төркемләнүе китерелә. Шулар арасында И.Я.Лернер һәм М.Н.Скаткин тарафыннан тәкъдим ителгәне күпчелек тарафыннан яклана: аңлату-күрсәтү методы, репродуктив метод; проблемалы укыту методы; өлешчә эзләнү яки эвристик метод; тикшерү методы.

Укучыларның яшь үзенчәлекләренә, белем дәрәҗәләренә һ.б. факторларга бәйле рәвештә, укытучы аларның тиешлесен сайлап ала. Язучы телен өйрәткәндә дә, бу методларның төрлесе кулланыла ала.

Аерым бер темаларны аңлатканда репродуктив метод, ягъни укытучы сөйләвенә нигезләнгән ысул уңышлы була. Аерым алганда, кушма җөмлә турында күзаллау булдыру дәресендә бу ысулга мөрәҗәгать итәргә була. Аңлату-күрсәтү методы кулланылганда, укытучы, күрсәтмә әсбаплардан (таблица, схема, рәсемнәр һ.б.) файдаланып, төрле мисаллар ярдәмендә өйрәнә торган материалны укучыларга аңлата, шул ук вакытта укучыларның танып-белү эшчәнлеген активлаштыруны да күздә тота. Бу метод күләме ягыннан зур булмаган, укучылар өчен кыен, авыр аңлашыла торган темаларны яки тел күренешләрен өйрәткәндә кулланыла ала. Язучы телен өйрәтүдә бу ысул – иң мөһиме. Мәсәлән, лексика бүлеген үткәндә, Ә.Еники әсәрләреннән рухи һәм физик сәламәтлек турындагы фразеологизмнар, синтаксис бүлеген үткәндә, Бәдретдин һәм аның сабакталашларының мәдрсәдәге көндәлек режимы турындагы җөмләләрне укып анализлауда, ягъни иң күләмле, төп темаларны өйрәнгәндә, аңлату-күрсәтү ысулы аеруча әһәмиятле. Моның өчен синтаксис буенча таблица һәм схемаларга (алар дидактик хезмәтләрдә дөнья күрде) мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Әлеге юнәлештәге эштә компьютер технологияләре дә ярдәмгә килә. Бу төр дәресләрдә компьютер технологияләре белән беррәттән, сәламәтлек саклау технологиясен бергә кулланырга мөмкин. Ә.Еникинең “Гөләндәм туташ хатирәсе” әсәре буенча спекталь карап, артистлар телендәге гади сөйләм

сүзләрен тыңлап анализларга мөмкин. Шулай ук фонетика бүлеген үткәндә дә спектакльне карап¸ авазлар әйтелешен, аваз үзгәрешләрен тикшерергә мөмкин. Билгеле, бу метод кулланылганда, укучылар пассив гына утырырга тиеш булмый, укытучы, төрле сораулар биреп, аларның игътибарын җәлеп итәргә, активлаштырырга тиеш була. Авазлар орфоэпиясе турында өйрәнгәндә дә, тел чисталыгы мәсьәләләренә тукталу мөһим. Димәк, сәламәтлек саклау технологиясе шулай ук гамәлгә ашырыла.

Өлешчә эзләнү ысулын кулланганда, укучыларның аң эшчәнлекләре төп урында тора, алар, укытучы җитәкчелеге астында, аерым бер күренеш буенча эзләнәләр, нәтиҗәләр ясыйлар, аннан соң белемнәрне гомумиләштерәләр. Сүз төркемнәренә караган мәгълүматны шул рәвешле бирергә мөмкин. Укытучының юнәлеш бирүче сораулары ярдәмендә, укучылар өйрәнелгән сүз төркемнәре, аларның грамматик категорияләрен турында искә төшерәләр, аларның үзенчәлекләрен билгелиләр, җөмләдәге синтаксик вазыйфаларын әйтәләр, шуннан соң укытучы тарафыннан яңа сүз төркеменә билгеләмә бирелә.

Болардан тыш, карточкалар белән эш, тестлар, әдәби әсәрдән я булмаса газета я журналлардан сәламәтлек саклау темасына караган җөмләләр язып алу, викторина һ.б. шундый эш алымнарын куллану кушма җөмлә синтаксисын өйрәтү дәресләрен нәтиҗәле итәргә булыша.

Фонетика турында гомуми төшенчә булдырганнан соң, балаларга авазлар, аерым алганда тартык һәм сузык авазлар турында мәгълүмат бирелә. Бу татар телен укытуда дәвамчанлык һәм эзлеклелек принцибына нигезләнеп башкарыла. Сузык авазларның классификациясе, алга таба тартыклар классификациясе турында мәгълүмат китерелә. Дәресләрнең шушы этабында татар һәм рус телләрендәге авазларны үзара чагыштырып өйрәтү әһәмиятле һәм максатка ярашлы. Моның өчен төрле биремнәр, күнегүләр тәкъдим итәргә мөмкин. Мәсәлән, яңа теманы аңлату дәресендә үк, аваз үзгәрешләре, аларның транскрипциядә бирелеше турында искә төшереп китү дә уңышлы. Шуннан соң, интерактив такта ярдәмендә әйтелеш белән язылыш арасындагы аермалыкларны табарга тәкъдим итеп була:

***Сәламәтлек – җәүһәр, ләкин тиз югала.***

***Бурычын яшергән бөлгән, авыруын яшергән үлгән.***

Башта җөмләләрнең мәгънәләре аңлатыла. Аннары грамматик сүзләр транскрипциядә күрсәтелә. Шул ук вакытта сүзләрнең орфоэпиясе аңлатыла. *Сәламәтлек* сүзенең язылышы нинди кагыйдәгә буйсынуы ассызыклана.

Төрле сүз төркемнәрен өйрәткәндә, татар һәм рус телләрендә морфологик категорияләрне үзара чагыштырып өйрәткәндә, төрле күнегүләр эшләү барышында аларны аера белү күнекмәләре формалаштырыла. Мондый төр күнегүләр, әлбәттә, белем һәм күнекмәләрне ныгыту һәм йомгаклау, тикшерү этапларында кулланыла ала.

Сәламәтлек кешенең туган табигатенә дә бәйле, шуңа күрә дә рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында укучы татар төркемнәрендә кушма җөмлә синтаксисын өйрәткәндә, аналитик һәм синтетик җөмләләрне үзара чагыштырып өйрәтү дә әһәмиятле. Дәреслектә дә аналитик һәм синтетик

җөмләләрне чагыштырып өйрәнү күздә тотыла. Бу очракта күрсәтмәлелеккә мөрәҗәгать итү уңышлы дип санала.

**Әдәбият**


1. Смирнов Н.К. Здоровьесберегающие образовательные технологии и психология здоровья в школе. /Н.К. Смирнов // М.:АРКТИ.-2005.- С 320.
2. Соловьева Н.И. Концепция здоровье сберегающей технологии в образовании и основы организационно-методические подходы ее реализации. / Н.И.Соловьева // ЭКО. – 2004. – № 17. – С. 23-28.
3. Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре / Русчадан Н.К.Нотфуллина тәрҗ. – Казан: Мәгариф, 2002. – 367 б.

# УНИВЕРСАЛЬ УКУ ГАМӘЛЛӘРЕН ФОРМАЛАШТЫРУ ПОЗИЦИЯСЕННӘН, ЗАМАНЧА ЧИТ ТЕЛ ДӘРЕСЛӘРЕ ПРОЕКТЛАШТЫРУ

Шаймухаметова Р.Р.
МБОУ «Татарско-Ямалинская ООШ»
rushaniya81@yandex.ru

**Аннотация**. Иглиз философы Джон Дьюның шундый сүзләре бар «*Әгәр дә без бүген кичәге көндәге кебек укытсак, без балаларның киләчәген урлыйбыз*». Минемчә, бу сүзләр бүгенге яңа стандартларның максатын чагылдыра. Бүгенге көндә укытучыларның максаты, заман таләпләрен тотып, беренче чиратта, укучы шәхесен формалаштыруда. Укучы конкрет дисциплиналар буенча белем алып кына калмый, ә аларны көндәлек тормышта, алга таба укуында файдаланырга да өйрәнә. Башкача әйткәндә, мәгариф системасы баланы белемле итү хакында гына түгел, аңа күнекмәләр бирү, аны эшкә өйрәтү турында да кайгырта.

**Төп сүзләр:** укыту, проектлаштыру, заманча укыту

Билгеле булуынча, яңа стандартлар уку предметының реаль тормыш белән бәйле булуын да аерым игътибарга ала. Укучы бала алган белемнәрен тормышта иркен куллана белергә, килеп туган мәсьәләләрнең чишелешен эзли, таба белергә тиеш. Заманча дәресләрдә исә шушы максатны гамәлгә ашыру өчен, укучыларда универсаль уку гамәлләрен формалаштырырга кирәк. Укытучы һәр балага шәхси якын килеп эшләгәндә генә, бала белемне аңлап үзләштерә. Укучы каршына нинди дә булса мәсьәлә куелган икән, ул аны ни өчен чишәргә икәнен аңларга, бу мәсьәләне чишкәннән соң, эшнең соңгы нәтиҗәсен күрә белергә тиеш. Бүгенгесе көндә барлык фән укытучылары, шулай ук инглиз теле укытучылары алдына укучыларда махсус белем һәм күнекмәләр генә түгел, универсаль уку гамәлләре формалаштыру максаты да куела. Заманча инглиз теле дәресе укучыларны шәхси, регулятив, танып-белү, коммуникатив УУГ белән коралландыруны таләп итә.

Дәрескә әзерләнгән вакытта, мин дә, башка укытучылар кебек, үз алдыма ике сорау куям: нәрсәгә өйрәтергә һәм ничек укытырга? Белемем буенча татар теле һәм чит тел укытучысы буларак һәм дә 15 ел чит тел укытып, мин бу телләрнең күп кенә охшаш якларын таптым. Шулай ук күп кенә очракларда миңа рус теленә дә мөрәҗәгать итәргә туры килә. Бу технологик алымны грамматик темалар белән танышканда куллану отышлы. Мин әлеге алымны үз дәресләремдә танып белү УУГ формалаштыруда бик актив кулланам. Гади генә мисал китерик, сыйфат дәрәҗәләре белән танышкан вакытта, мин укучыларның татар һәм рус телләрендә алынган белемнәренә таянып эш итәм. Белгәнебезчә, 3 телдә сыйфат дәрәҗәсе бар, сүзләрнең аффикслары үзгәрә һәм бу сүзләр ярдәмче сүзләр белән ясала. Бу бигрәк тә башлангыч сыйныф укучылары өчен бик уңышлы алым. Беренчедән, әлеге метод өйрәнелә торган телләрнең

үзенчәлеген, грамматик һәм лексик структураларындагы охшашлыкларны һәм аерымлыкларны тирәнтен үзләштергән очракта бигрәк тә файдалы. Икенчедән, татар теле мөһитендә тәрбияләнгән укучылдарны исә татар, рус телендәге белемнәрен инглиз теле дәресләрендә кулланулары табигый ихтияҗ формасында алып барыла (таблица рәвешендә чагыштырып бирү яхшырак хәтердә кала, икенчедән, аларның татар һәм рус телләрендә алган белемнәре инглиз телен үзләштерергә ярдәм итә). Шулай ук бу алымны тәртип санын, фигыльнең заман формаларын, алмашлыкларны, исемнәрнең күплек санын өйрәнгәндә һәм башка бик күп кенә очракларда кулланып була.

Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләргә килгәндә, чит тел укытучыларына бүгенгесе көндә зур бурыч куела. Без төрле яклап камил, иҗади үзүсешкә сәләтле, милли гореф-гадәтләр, Россия Һәм Бөтендөнья культурасы кыйммәтләре нигезендә тормышта үз урынын тапкан шәхес тәрбияләргә тиешбез. Бүгенге поликультуралы һәм полилингваль дөньяда алар турыдан-туры мөстәкыйль эшчәнлек алып барырлык, җаваплы, оештыруга сәләтле укучылар булырга тиешләр. Шуңа күрә дә бүгенгесе көндә дәүләт бу адымны балалар бакчасыннан ук башларга кирәклеген зарур дип тапты. Район башлыгының да фикерләрен, таләпләрен исәптә тотып, киләчәктә авыл балалар бакчаларында да чит телләр укытыла башлаячагы безне бик сөендерде. Бу, әлбәттә, киләчәктә аларда шәхескә кагылышлы УУГ формалаштыруда җиңеллек тудырачак. Алар кечкенәдән “Минем өчен чит тел өйрәнүнең нинди мәгънәсе һәм әһәмияте бар?» - дигән сорауларга җавап табачаклар, үз халкы культурасы белән беррәттән, башка халыкларның культурасына, тарихына хөрмәт белән караячаклар.

Чит тел дәресләрендә дә, башка фәннәрдәге кебек, регулятив уку гамәлләре план буенча эшләргә юнәлеш бирә, эшчәнлекне оештыру мөмкинлеге бирә, танып-белү процессы белән идарә итәргә булыша. Үзбәя, дустыңа, дәрескә бәя кую кебек алымнар белән беррәттән мин дәресләремдә үзмаксат куюны отышлы саныйм.

Алда санап үтелгән УУГ ләре заманча дәрес проектлаштыруда зур роль уйныйлар. Әмма чит тел өчен иң кирәге ул укучыларда коммуникатив УУГ формалаштыру. Татар мәктәпләрендә укучы балаларга чит тел укытуда коммуникатив методны төп юнәлеш итеп алсак, уңышка ирешергә мөмкин.Үземнең тәҗрибәдән чыгып әйтәсем килә: балалар дәрестә грамматик күнегүләрне, язма эшләрне эшләүгә караганда, нинди дә булса да мәсьәлә буенча сөйләшү, проект эшләре, экскурсияләр, диалогларны рольләргә бүлеп сөйләү, картина, видеоязмалар буенча әңгәмәләрне күпкә яратып башкаралар. Рольле уеннар алар өчен күпкә кызыклырак һәм бу эшләрнең нәтиҗәсе зур.

Коммуникатив УУГен формалаштыру юлларын дөрес оештырганда, ул укучыларның тел өйрәнүгә карата мөнәсәбәтләрен уңай якка үзгәртә, белемнәрнең аңлылыгына этәрә, мөстәкыйльлеккә өйрәтә, иҗади фикерләүне үстерә.

Татар милләтеннән булган балаларга чит тел өйрәтүнең һәрбер чорында уеннарны дәрестә һәм дәрестән тыш куллану уңай нәтиҗәләргә ирешергә

мөмкинлек бирә. Бары тик оста оештырылган заманча дәрес кенә балаларга чит телгә карата кызыксыну уята ала.

Listing (аудирование), Speaking (говрение) вакытында танып белү һәм коммуникатив УУГ тормышка ашырыла. Бу бүгенге заманча чит тел дәресләренең үзәгендә торырга тиеш. Аудирование һәм говорение өлешләрен яхшы үзләштергән балаларның киләчәктә БДИ ын уңышлы бирүләренә шик калмый. Ә бу безнең, ягъни чит тел укытучыларының, киләчәктә алга куелган төп бурычларыбызның берсе.

Мондый мисалларны саный китсәң, алар шактый. Бу хәзергесе вакытта бер генә фән укытучысы өчен дә яңалык түгел. Әмма шушы безнең өчен таныш булган гамәлләрне без көннән-көн үзебез яңартабыз. Шулай яңалыкка омтылып эшләсәк кенә без заманча дәрес формалаштыра алабыз һәм укучыларда укуга кызыксыну уятачакбыз. Ә чит тел укытучылары өчен болар һәммәсе дә бермә-бер тырышлык сорый.

Язмамны бик матур хикәя юллары белән төгәллисем килә:

Борын заманда яшәгән ди бер патша. Беркөнне ул үзенең вәзирләрен чакырып алган да, үзенең патшалыгындагы иң зур йозакны ачырга кушкан. «Вәзирләрем минем! Кемдә - кем шушы йозакны ача, аңа мин патшалыгымдагы иң югары вазифаны бирәм. Шушы сүзләрне ишетү белән кайбер вәзирләр, бездән булмас дип» китеп барганнар. Икенчеләре йозак каршысында озак карап, тикшереп торганнан соң, кайтып киткәннәр. Тик бер вәзир генә йозакны тегеләй караган, болай караган, ниһаять тартып карарга булган. Һәм могҗиза! Йозак ачылып киткән. Патша моны күреп, болай дигән: «Карагыз! Ул үзенең күзләренә һәм колакларына гына таянмый, иң мөһиме үз көченә ышанып, авырлык алдында туктамыйча, янәдән – янә омтылыш ясады».

# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ УКУЧЫЛАРНЫҢ ФУНКЦИОНАЛЬ ГРАМОТАЛЫЛЫГЫН ФОРМАЛАШТЫРУ

Шәмсетдинова Р.Р., Фаттахова Р.Ф.
ГАОУ ДПО “Институт развития образования РТ”
**tnd@rambler.ru**

**Аннотация.** В статье рассматриваютя некоторые понятия грамотности и процесс формирования функциональной грамотности на уроках татарского языка и литературы – целесообразное использования языковых средств при работе с текстами.
**Ключевые слова:** грамотность, функциональная грамотность , базовый уровень, языковые средства, культура речевого общения, использование информации прочитанного

Халыкның грамоталылыгы мәсьәләсе халыкара дәрәҗәдә (ЮНЕСКО) 20 нче гасырның 50 нче елларында карала башлый. 1958 елда ЮНЕСКО барлык илләр өчен тәкъдимнәр эшләп чыгара, әлеге тәкъдимнәрдә грамоталы кеше –ул укый белүче, укыганын аңлый һәм көндәлек тормышка караган гади кыска текстлар төзи белүче шәхес (Юнеско Генераль конференциясенең 10 нчы сессиясе материаллары). Шул ук вакытта грамоталылык терминын шәхеснең социаль мөнәсәбәтләр системасында нормаль хис итешен тәэмин итә алырлык күнекмәләр күләме мәгънәсендә аңлау да кабул ителгән. Шуңа бәйле рәвештә әлеге күнекмәләрнең күләме конкрет шартлардан чыгып төрлечә билгеләнә, хәзерге белем бирү эшчәнлегендә функциональ грамоталылык термины кулланыла. Ул кешенең тышкы мохит белән мөнәсәбәткә керә алу һәм тиз арада шул шартларга җайлаша алу сәләте мәгънәсендә кулланыла.

Педагогика фәнендә грамоталылык мәсьәләсе төрле елларда күтәрелеп чыгып килде. Нигездә, грамоталылык мәсьәләләре массакүләм белем бирү мәсьәләләре хәл ителгәндә аеруча кискен күтәрелгән. Шул ук вакытта грамоталылык төшенчәсенең төгәл генә билгеләмәсе юк. Грамотылы кешене характерлый торган укый, яза, рәсем ясый һ.б. төрле кешенең нормаль тормыш эшчәнлеге өчен кирәк булган һәм башлангыч сыйныфларда үзләштерелә торган минималь күнекмәләр җыелмасы гына хәзерге чор социаль мәсьәләләрен чишү өчен җитәрлек түгел. Грамоталылык, белем бирү мәсьәләләре, тулаем алганда, һәрвакытта конкрет социаль, икътисади һәм мәдәни ситуациягә бәйле булган. Мисал өчен, антик дөньяда 1 дән алып 10 га кадәр исәпләүне укучылар еллар дәвамында өйрәнә алганнар һәм компетентлыкның мондый дәрәҗәсе шул чордагы социомәдәни чынбарлыкка туры килгән булса, хәзер исә грамоталылыкның бу дәрәҗәсе укуның беренче атнасында ирешелә торган дәрәҗә санала. Хәзерге чор цивилизациясенең дәрәҗәсе грамоталылык һәм белемлелекне бөтенләй башка төрле эчтәлектә аңлауны таләп итә. Бүгенге көндә функциональ грамоталылык кешенең мәгълүматны (беренче чиратта – текстны) таба, аңлый, үзләштерә, эшкәртә, саклый, тапшыра, көндәлек

тормышта, уку, һөнәри өлкәдә, иҗтимагый тормышта нәтиҗәле файдалана белү сәләтенә ия булуны белдерә. Функциональ грамоталылык – метапредмет күренеш һәм ул төрле предметларны үзләштергәндә файдаланыла һәм төрле формаларда чагылыш таба. Функциональ грамоталылыкның берничә индикаторы билгеләнә: коммуникатив грамоталылык, мәгълүмати грамоталылык, эшчәнлекле грамоталылык.

Коммуникатив грамоталылык укучыларда сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрен яхшы белүләрен, алардан урынлы куллана белүне формалаштыруны күзаллый.

Сөйләм эшчәнлегенең һәр төре сөйләмә һәм язма формада җиткерелгән мәгълүматны дөрес аңлауны формалаштыра, шуңа күрә татар теле дәресләрендә теоретик материалны тирәнрәк үзләштерү өчен татар теле күренешләре турында хикәяләүче текстларны, экиятләрне кертү, рус телендәге, чит телдәге тәңгәл яки тәңгәл килми торган мисаллар җирлегендә бирү мөһим. Бу очракта укучылар өйрәнелә торган тел күренешен ниндидер формаль грамматик күренеш буларак түгел, ә телләр тормышыннан алынган кызыклы, мөһим, күпкырлы күренеш буларак кабул ителәчәк. Мисал өчен, татар телендә грамматик күренеш буларак чагылыш тапмаган род категориясен, кайбер телләрдә (рус, француз, немец һ.б. телләрдә) исемнәргә карата кулланылуының бик шартлы булуын я яңа өйрәнә башлаганда, я кабатлау дәресендә түбәндәгечә шәрехләргә мөмкин: кешеләрнең, хайваннарның, кош-кортларның җенесен чагылдыра торган сүзләр бар телләрдә, мәсәлән, эти-әни, папа-мама, әтәч-тавык, петух-курица, ата каз –ана каз, гусак – гусыня. Татар телендә род төшенчәсенең башкача чагылышы юк. Ә менә рус телендә башка сүзләрнең родын билгеләгәндә, бу логика өзелә, кушымчаларга таянып билгеләнә, кайбер очракта, мисал өчен, “ночь» һәм «день” беренче карашка берни белән дә аерылып тормаган сүзләрнең беренчесе – женский род, ә икенчесе мужской. Род категориясенең шартлылыгын тәрҗемә эшчәнлегеннән мисаллар белән дә күрсәтергә мөмкин: рус телендә стол – мужской род, шул сүз кергән текстны француз теленә женский родтагы исем буларак тәрҗемә итәбез (une table), яисә немец телендә das Madchen (кыз –девочка) - средний родтагы исем. Чагыштырып бирү нәтиҗәсендә, укучы үзенең туган теленең грамматик структурасы турында нәтиҗәләрен чыгара ала, башка телләр турында күзаллау булдыра ала, телләрдәге башка аерым күренешләр турында үзенең тикшеренү эшен алып бара, күзәтүләр ясый ала, шулар аша анда эшчәнлекле грамоталылык формалаша. Татар теле дәресләрендә эшчәнлекле грамоталык формалаштыру өстендә эш “татар теле” курсының барлык темаларын өйрәнгәндә алып барылырга тиеш һәм аңа “фикер һәм белем” проблемалы метапредмет ситуацияләрне чишү өчен шартлар тудырылып дәрестә фикернең белемнән аермасын күрсәтү юнәлешендә эш алып барганда ирешергә мөмкин.

Функциональ грамоталылык формалаштыру, укучыларның сөйләм эшчәнлеген камилләштерү татар теле предметында алган белемнәрен аларны аралашуның төрле шартларында куланылу үзенчәлекләренә нигезләнә. Өйрәтү процессы тел материалын анализлау күнекмәләрен формалаштыруга, тел

фактларын классификацияләүгә генә юнәлдерелмичә, сөйләм культурасы тәрбияләүгә, укуның төрле формаларыннан файдалану, текстларны мәгълүмати яктан үзләштерү, мәгълүматны төрле формаларда эзләү һәм аны сөйләм ситуациясенә һәм әдәби тел нормаларына, аралашуның этик нормаларына туры китереп тапшыруның төрле ысуллары кебек тормышта гаять кирәк булган осталык формалаштыруга юнәлдерелгән.

Функциональ грамоталык формалаштыруда татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә текст өстендә эш оештыру мөһим роль уйный. Нигез текстның гомуми мәгънәсен аңлау, авторның позициясен билгели белү, автор позициясе белән герой позициясе арасындагы аерманы билгели белү, текстның логик төзелешен аңлый белүгә ия булу тора. Текстларны уку процессына кертеп җибәргәндәге методик факторларга без, беренче чиратта, текст материалын сайлау критерийларын; текстны дәрескә кертеп җибәрүнең максатка туры килә торган эш төрләре; дәресне текстка таянып алып барырлык итеп оештыруны кертәбез. Текстны өйрәнгәндә, текстның, лингвистик күзәтүләр юлы белән бәйләнешле, структур компонентлары ачыклана. Җөмләнең өлешләре һәм аерым җөмләләрне бәйләү өчен уртак булган, шулай ук үзенчәлекле саналган күрсәткечләр бүлеп чыгарыла, бәйләнешле сөйләмгә чыгу күнекмәләре булдырыла. Бәйләнешле сөйләмне тикшерү кеше фикеренең төзелешен, аның телдә чагылышын аңлауга ярдәм итә. Текстларны игътибар белән уку барышында укучылар фразаларны бәйләүдә катнаша торган иң типик чараларны бүлеп чыгаралар. Мисал өчен, 9 сыйныфта сөйләм үстерүгә караган темаларны ныгытканда, укучылар текст төзелешендә текст барлыкка китерүдә катнашкан, авторга текстның экспрессив-стилистик бөтенлеген тудыруга нигез булган төп чараларны билгелиләр. Мондый төр биремнәр укучыларны текстка нигезләнеп, иҗади эшчәнлек башкару өчен бик кирәкле, мөһим. 9 нчы сыйныфта туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясе эше сочинение элементлары белән киңәйтелгән иҗади биремле изложение формасында тәкъдим ителә. Изложение имтихан бирүчеләрнең текстка нигезләнеп, мөстәкыйль рәвештә мәгънәви бөтен, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерланган иҗади бирем башкаруына йөз тота. Киңәйтелгән изложение укучыларның лингвистик компетенциясе (тел материалы белән эшләгәндә, лингвистик белемнәрне куллана алуы, тел һәм сөйләмгә караган белеме, өйрәнгән материалны урынлы куллана белү күнекмәләре, шулай ук танып белү, төркемләү, татар теле дәресләрендә алган аналитик белем һәм күнекмәләр), тел компетенциясе (лексик, грамматик, стилистик, орфографик һәм пунктуацион нормаларны саклау осталыгы һәм күнекмәләре), коммуникатив (аралашу) компетенциясе (сөйләм эшчәнлегендә продуктив һәм рецептив күнекмәләрне үзләштерү дәрәҗәсе) тикшерелә. Шуңа күрә 5 нче сыйныфтан укучыларның коммуникатив грамоталылыгын үстерү өстендә эш оештырылырга тиеш. Мәсәлән, эчтәлек сөйләгән вакытта, җөмләләрне дөрес итеп төзүгә игътибар бирелә. Бер үк җөмләдә яки янәшә җөмләләрдә кабатлаулардан арыну, сүзләрнең синонимнарын куллану таләп ителә. Сүзлек диктантлары язган вакытта ( һәр дәрестә диярлек языла),

синонимнар таптырыла. Дәрестә орфографик сүзлекләр белән эшләү уңай нәтиҗә бирә. 5 нче сыйныфтан ук сүзлек диктантларының дөреслеген сүзлектән карап тикшерү сүзләрнең язылышын хәтердә калдырырга ярдәм итә, шул ук вакытта сүзлек белән эшләү күнекмәләрен үстерә. Дөрес, башта бу эш шактый күп вакытны ала, соңга таба укучылар кирәкле сүзләрне бик тиз табарга өйрәнәләр. Дәрестә текстны аңларга ярдәм итә торган уңышлы эш формаларыннан актив файдалану (абзацларны сайлап абзацларның эзлеклелеген билгеләү; авторның фикер йөртешен, тасвирлауларның бирелешен анализлау; вакыйгалар хронологиясен билгеләү, тексты микротемаларга бүлү һ.б.) укучыларның коммуникатив һәм эшчәнлекле грамоталылыгын арттырырга ярдәм итә.

Альберт Эйнштейнның функциональ грамоталылыкның гамәли әһәмиятен тулысынча чагылдыра торган фикере бар: “...мәктәптә өйрәткәннәрнең онытылганнан соң калган өлеше ул - белем...” . Татар теле һәм әдәбияты дәресләреннән дә белем калырлык итеп укыту мөһим бурычыбыз.

**Әдәбият**


1. Концепция федеральных государственных образовательных стандартов общего образования: проект / Рос.акад. образования; под ред. А.М. Кондакова, А.А. Кузнецова. — М.: Просвещение, 2008. http://www.ed.gov.ru/ob-edu/noc/rub/standart/
2. Валькова Г., Зайнуллина Ф., Штейнберг В. Логико-смысловые модели - дидактическая многомерная технология // Директор школы: науч.-метод. журн. для рук. учеб. заведений и органов образования. - 2009. - № 1. - С.49-54.
3. Гыйләҗева Л.Г., Хадиева Г.В. Татар теле. 9 нчы сыйныф. Дәүләт (йомгаклау аттестациясенә әзерләнү. Татар телендә гомуми белем бирү мәктәпләре өчен методик кулланма. – Казан: Ихлас. - 92 бит.
4. Ермоленко В.А. Проблемы функциональной грамотности в современных условиях. Через чтение в мировое образовательное пространство. Выпуск 11. – М., 2002 - С.45-49.
5. Шәмсетдинова Р.Р. Татар теле: Күнегүләр. Анализ үрнәкләре. Тестлар/ Р.Р. Шәмсетдинова; тулыл. икенче басма. – Казан: Татар. кит. Нәшр., 2007. – 191 б.

# МИЛЛИ МӘГАРИФНЕ БЕЛЕМ СЫЙФАТЫН КҮТӘРҮДӘ ТӨП БУРЫЧЛАР

Шарифуллина Р.И
МБОУ “Черемшанский лицей”
shrazily@mail.ru

Аннотация. Эта статья не только о проблемах обучения языкам в качестве родного, но и о применении о новой и уникальной технологии в обучении родного языка.
Ключевые слова. Деятельностный подход. Приоритетные технологии. Обучение в сотрудничестве. Успешный выпустник.

Бүгенге көн мәгариф системасыны стенлекле юн леше булып- ү ө ә ң ө ә баланың ү ә ү ә ү ә злегенн н сешен т эмин ит г юн лдерелг н уку-танып бел процессын ә ә ү оештыру тора. Без т ртипле, эш с юч н, тормышта з урыннарын таба ә ө ә ү алырлык, мгыять чен т рле яклап ск н ш хес т рбиял рг тиеш. Алар җә ө ө ү ә ә ә ә инициатива к рс т бел че, очраган кыенлыклардан и юлларын ү ә ә ү җ нү м ст кыйль таба алырлык, ягъни стандарт булмаган чишелешл р таба алучы; ө ә ә креатив (и ади), критик (т нкыйди) фикерг ия, м шулай ук хезм т җ ә ә һә ә базарларында конкурентлыкка с л тле, компетентлы ш хес булсын. Бу- ә ә ә укыту-т рбия процессыны асыл максаты. ә ң Б генге к нд компетентлы ( способный, белемле, с л тле, у ышка иреш ү ө ә ә ә ң ә торган) ш хес формалаштыру чен, укытучы зе д шул тал пл рг ия ә ө ү ә ә ә ә булырга тиеш. Компетентлы укытучы нинди к некм л рг ия булырга тиеш? ү ә ә ә 1) Даими йр нерг : зг решл рг зер булырга, р эш н ти ле булсын чен ө ә ә ү ә ә ә ә һә ә җә ө тырышырга, белеме не системага салырга, башкалар фикере бел н ң ә ис пл шерг , я алыкны тиз кабул ит рг йр нерг ; ә ә ә ң ә ә ө ә ә 2) Эзл нерг : информацияне сайлап ала белерг , зе кир клесен эзл п ә ә ә ү ңә ә ә табарга; 3) Хезм тт шлек ит рг : группада, командада эшл г нд , карарлар кабул ә ә ә ә ә ә ә итк нд , конфликтларны чишк нд башкалар фикере бел н ис пл ш д ; ә ә ә ә ә ә ә ү ә 4) Эшк тотынырга: проектлар эшл рг , берд м булырга, з эше не оештыра ә ә ә ә ү ң белерг ; ә 5) айлашырга: я а информацион м коммуникатив технологиял рне Җ ң һә ә кулланырга, я алыкны тиз кабул ит рг , югалып калмаска. ң ә ә Заманча сыйфатлы белем бир – универсаль уку гам лл рен (УУГ) ү ә ә формалаштыруга юн лг н булырга тиеш. ә ә Укытуга компетентлы якын килү укытучы бел н укучыны бер к максатта эшл вен т эмин ит .Укытучы ә ң ү ә ә ә укучыга зер белем бирерг тиеш т гел:укучылар белем алырга кил , ә ә ү ә ә укытучы укучыларны белем алуларын оештырырга тиеш була, ягъни ң эшлекле белем механизмы тормышка ашырыла:укытучы да, балалар да процессны субъектлары булу зарур. ң УУГ гам лл ре я а белем м ә ә ң һә к некм л рне м ст кыйль р вешт зл штер алуы м шул процессны ү ә ә ө ә ә ә ү ә ә һә оештыра бел не т эмин ит торган гам лл р ыелмасы ү ә ә ә ә җ . Укытучы – оештыручы т рле эш формалары, я а белемн рне эзл рг эт р че ө ң ә ә ә ә ү технологиял р кулланырга тиеш. (Традицион эш т рл ре бел н, инновацион ә ө ә ә формалар еш

кулланырга: тренинг, эшлекле уен, мастер-класс, проект эшл ре, ә эзл н -тикшерен эшл ре .б.) ә ү ү ә һ Я а стандартлар укытучыдан м гъл мати коммуникатив технологиял р ң ә ү ә куллануны тал п ит .Компьютер технологиял рен куллану н ти сенд ә ә ә ә җә ә балалар м гъл мат ташкынында иркен аралашырга йр н , м гъл мат алу ә ү ө ә ә ә ү ысулларын зл штер . Белем бир д проектлар методын файдалану балага ү ә ә ү ә ш хси якын килеп укытуда н ти ле технологиял рд н санала. Проект т з ә ә җә ә ә ө ү эшч нлеге м ст кыйль фикерл не стер ,м гъл мат таба бел , ә ө ә әү ү ү ә ү ү фаразлау ,стандарт булмаган карарлар кабул ит осталыгына ия булуны к зд ү ү ә тота. Мультимедиа технологиял ре электрон белешм лекл р, ә ә ә энцеклопедиял р, к л мле м гъл мат чыганаклары бел н эшл г юл ача. ә ү ә ә ү ә әү ә Укучыларны зара ярд мл ш ен активлаштыруга юн лтелг н эш ң ү ә ә ү ә ә формасы буларак эшч нлекне т ркемн рд оештыру у ай н ти л р бир . ә ө ә ә ң ә җә ә ә Укучылар бер – берсе бел н аралашып, бер – берсене фикерен ты лап, з – ә ң ң ү ү ә ә ө ә ү ү ә зл ренд м ст кыйльлек сыйфатлары булдыралар, шулай итеп, алар з сешк ireш . ә Проблемалы укыту технологиясе куллану н ти сенд балаларны ә җә ә ң фикерл с л те камилл штерел . әү ә ә ә ә Татар теле д ресл ренд ә ә ә и ади стерешле Р химов технологиясе җ ү ә кулай булса, д бият д ресе чен Яхин ә ә ә ө методологиясе кулай. Тагын инновацион технологиял рне берсе- ә ң критик фикерл технологиясе әү н аерып к рс т сем ү ә ә кил . Бу технология – з фикере не яклый, иткер алу, г м д ше не ә ү ң җ ә әң ә ә ә ң ты лый бел , аргументларга нигезл неп, логик фикер й ртерг шартлар ң ү ә ө ә тудыра. Д ресне т рле этабында куллану чен т рле алымнары бар. Я алыгы ә ң ө ө ө ң – и ади ш хес т рбиял г шартлар тудыра. Бу турыда м гъл матны м гариф җ ә ә әү ә ә ү ә журналларыннан да таба аласыз. (“К рзин” ысулы, Синквейн, Кластер, Алты ә эшл п .б. ысуллар) ә ә һ Укучыларны зара ярд мл ш ен активлаштыруга юн лтелг н эш ң ү ә ә ү ә ә формасы буларак эшч нлекне т ркемн рд оештыру у ай н ти л р бир . ә ө ә ә ң ә җә ә ә Укучылар бер – берсе бел н аралашып, бер – берсене фикерен ты лап, з – ә ң ң ү ү ә ә ө ә ү ү ә зл ренд м ст кыйльлек сыйфатлары булдыралар, шулай итеп, алар з сешк ireш . ә Укытуны традицион системасында булган и яхшы алым,методларын ң ң кулланып м стер барып эшл г нд ген инновацион технологиял р яхшы һә ү ә ә ә ә ә ә н ти г ирешерг ярд м ит . мма рбер д ресне д информацион ә җә ә ә ә ә Ә һә ә ә технологиял р кулланып тк реп булмый, мондый д реск зерлек укытучыдан ә ү ә ә ә ә к п вакыт та тал п ит ү ә ә.“Укытучыны тере с зен бернинди компьютер да ң ү алыштыра алмый” диг н с зл рне еш ишетерг туры кил . Бу с зл р бел н ә ү ә ә ә ү ә ә килеш м. Туган тел д ресл рен укучыларны мониторга каратып кына тк реп ә ә ә ү ә булмый. Ч нки д ресне т рле этапларында урынлы, уйланылып кулланылган ө ә ң ө компьютер бел н эш укучыны укытучы ә ң һә ә м сыйныфташлары бел н аралашуы һә ү ө ә ә ү м башка к п т рле эшл р бел н релеп барырга тиеш. Б генге к нд м кт пл рд татар халкы тарихы бик аз к л мд укытыла ү ө ә ә ә ә ә ү ә ә яис б тенл й укытылмый. Шу а к р татар теле д ресл ренд , коммуникатив ә ө ә ң ү ә ә ә ә һә ә ү ә м т рбияви максатларны к зд тотып, кызыклы этнографик-тарихи темаларны яктырту укучыларга з халкыны тк не турында к пмедер к л мд ү ң ү ә

ү ү ә ә м гъл мат биреп, аларда татар тарихын йр н г мотивация булдыра. ә ү ө ә ү ә Икенчед н, б генге к н укучыларында татар халкыны гореф-гад тл ре, ә ү ө ң ә ә традициял ре турында к заллау бик шартлы. Бигр к т зур ш рл рд яш че ә ү ә ә әһә ә ә әү балалар лк н буын в килл ре – би-бабаларыннан читт яши, шу а к р ө ә ә ә ә ә ң ү ә аларда татар халкыны гасырлар д вамында формалашкан гореф-гад тл ре ң ә ә ә турында х б рсез булып калуы ихтимал: “ бил регез яшь чакта кулъяулыклар ә ә Ә ә чикк ндер, к рг негез, сораганыгыз бармы?” - дип сорагач, балалар “без би ә ү ә ә бел н яш мибез, ул аерым яши” яки “ би-бабай лг н, йортлары сатылган ә ә ә ү ә инде”, дил р. Гомум н, социом д ни компетенцияне тел материалы бел н берг ә ә ә ә ә ә ү ө ә Ө ә реп, диалогик яки монологик с йл м итеп ченчед н, укучыларда татар халкыны д нья цивилизациясене бер леше булуын, аны з милли киен ң ө ң ө ң ү ү р веше, к заллаулары, гореф-гад тл ре, рухи м материаль байлыгы барлыгы ә ү ә ә һә турында фикер урнаша. Ә ә ә ң ү т рбияви максаты татар милли биз кл ре, татар халкыны киен ү ә ә ә ә ә зенч лекл ре, гореф-гад тл ре, аш-су осталыгы, кулдан эшл нг н эш кораллары турында м гъл мат бир , укучыларда з халкыны гореф- ә ү ү ү ң гад тл рен , этнографик зенч лекл рен ихтирам-х рм т уяту, горурлык хисе ә ә ә ү ә ә ә ө ә т рбиял булган д ресл р комплекслы т къдим ителс , укучыларыбызда з ә әү ә ә ә ә ү халкы м д нияте турында тулы к заллау булдырырга м мкин. Шул р вешле ә ә ү ө ә б генге заман 21 нче гасыр укытучысы татар телен м д биятын йр т бел н ү һә ә ә ө ә ү ә берр тт н, укучыларда, ягъни кил ч к буын в килл ренд , з тк нен , ә ә ә ә ә ә ү ү ә ә тарихына, м д ни мирасына ихтирам-х рм т т рбияли, дим к, р бала з- зен ә ә ө ә ә ә һә ү ү яратырга, би-бабасын, ти- нисен х рм тл рг йр н . ә ә ә ө ә ә ә ө ә ә М кт пт кулланыла торган и отышлы инновацион технологиял рне ә ә ә ң ә ң берсе электрон д реслекл р ә ә һә ә ә Ү ә ә ә м ярд млекл р. з д ресл ремд Хайдарова Р.З. Галиева Н.Г ит кчелегенд чыккан “К елле татар теле” электрон җ ә ә үң д ресл кл рен, ә ә ә Ф тхуллова К.С. Юсупова А.Ш. Денм х мм това Э.Н. ә ө ә ә авторлыгында чыккан “Татарча с йл ш без, укыйбыз, язабыз” ярд млекл рен ө ә ә ә ә кулланам. леге д реслекл р м ярд млекл рд ге материаллар укучыда тел Ә ә ә һә ә ә ә ө ә ү ә ң ә ә ә һә йр н г кызыксыну тудыра. Аларны з выклы биз леше, биремн р м текстларны с нгатьч биз леше, биз лешт т сл рне урынлы куллану, ң ә ә ә ә ә ө ә т къдим ителг н текстларны м зекл рне балалар чен кызыклы булуы, ә ә ң һә ө ә ң ө яшь зенч лекл рен туры кил е, биремн р м сорауларны укучы башкарып ү ә ә ә ү ә һә ң чыга алырлык катлаулылыкта булуы, аудирование лешл ре булу бик т яхшы. ө ә ә Татар теле м д бияты д ресл ренд компьютер технологиял рнен һә ә ә ә ә ә ә куллануны т б нд ге у ай яклары бар: ң ү ә ә ң • уку процессы эчт легене индивидуальл ш , к л мле материалны тиз ә ң ә ү ү ә ң ү ә ү зл штерел е; • укучыларны танып бел активлыгы с ; ң ү ү ү • укучыларны психологик м мкинлекл рене ис пк алынуы м ң ө ә ң ә ә һә белемн рне объектив б ял нел е; ә ң ә ә ү • укытучыны эш характеры зг р . ң ү ә ү Шул р вешле, татар телен укытканда, заманча технологиял рг таяну ә ә ә укытучыны да эшен и ел йт , укучыларны белем д р сен арттыруда да ң җ ң ә ә ң ә әҗә м им чара булып тора. өһ Х зерге шатрларда татар телен гам лг керт чен, объектив шартлар ә ә ә ү ө җ ә ө ә ә җә ә ү ү ө ит

рлек. Татар телен укытуны м мкин кад р н ти лер к ит – б генге к н педагогикасыны м им бурычларыннан берсе. у ай н ти л рг иреш д ң өһ Ә ң ә җә ә ә ү ә заманча технологиял рг таяну ярд м ит ала. ә ә ә ә Белем бир д заманча технологиял рне куллану ул - хлаклы кеше ү ә ә ә т рбиял , педагогик технологиял р булдыруда ф нне роле арту, йр нг нне ә әү ә ә ң ө ә ә тормышта куллана бел м башкалар. ү һә Д ресл ремд заманча технологиял рне кулланып мин т б нд ге ә ә ә ә ү ә ә н ти л рг иреш алдым дип уйлыйм:укучыларны с йл м теле яхшыра, ә җә ә ә ә ң ө ә с злек запасы баеый; компьютер технлогиял ре куллану уку эшч нлеген тагын ү ә ә да баетты;укучыларны и ади эшч нлеге артты. ң җ ә Эшемне н ти се буларак укыткан укучыларым ачык д ресл рд , т рле ң ә җә ә ә ә ө конкурсларда, конференциял рд актив катнашалар, урыннар алалар, д реск ә ә ә ә кызыксыынп, тел п й рил р. ә ө ә Я а технологиял р бел н танышуны м д рест куллану, и ади сешне ң ә ә һә ә ә җ ү т эмин ит че методик д биятны йр н , эзл н эшч нлеген д вам ит ә ү ә ә ө ә ү ә ү ә ә ү кил ч кк переспиктивам. ә ә ә Алда язылганнардан н ти ясап, шуны йтерг була: педагогика ф ненд ә җә ә ә ә ә укыту-т рбия процессы сыйфатын стererг булышлык ит че технологиял р ә ү ә ү ә шактый. Укытучыны бурычы – я алыклар агымында югалып калмыйча, д рес ң ң ө юн леш алу, укытучыны р этабы чен уку материалын а латуны и ә ң һә ө ң ң ң у ышлы вариантын табу. Шул ук вакытта аларны бер-берсе бел н ярашырга ң ң ә тиешлеген д онытмау зарури. И м име шул: заманча технологиял рне ә ң өһ ә куллану алынган м гъл матны 85%ка якынын, традицион технологиял р – ә ү ң ә ә 40% белемне х терд озак сакларга ярд м ит . ә ә ә ә Я а белем бир стандартлары куйган тал пл рне у ышлы т м кт п, ң ү ә ә ң ү әү ә ә гаил , мгыять м д л т берд м булып, зур к ч куеп эшл г нд ген ә җә һә әү ә ә ө ә ә ә ә булачак. Я а стандартлар буенча чыгарылыш укучысы кызыксынучан, ң д ньяны актив танып-бел че, белем нигезл рен яхшы зл штер че, м ст кыйль ө ү ә ү ә ү ө ә һә җ ү ң ә һә җә м и ади, зене туган ягын, илен яратучы, гаил м мгыять кыймм тл рен кабул ит че м х рм т ит че, зе эшл г н эшк гаил м ә ә ү һә ө ә ү ү ә ә ә ә һә м кт п алдында авап бир бел че, кеше фикерен ты лый м з фикерен ә ә җ ә ү ң һә ү ә ә ү ә ә әү ә ә ә ө ә ү әү йт бел че, с лам т яш р веше кагыйд л рен т г л т че булырга тиеш. Укытучы к р з че т гел. Ул баланы кил ч кт кем булуын, ү ә ә ү ң ә ә ә җә ә ә мгыятьт нинди урын тотуын бел алмый. Шулай да укытучы перспектив эшл рг тиеш. Ул т рбиял че ш хес заманча мгыятьк ә ә ә әү ә җә ә у ышлы формалашкан булсын м чын кеше булып калсын.

Әдәбият

1. Загашеев И.О., Заир-Бек С.И., Муштавинская И.В. Учим детей мыслить критически. – СПб, 2003

2. Селевко Г. К. Современные образовательные технологии. М., “Народное образование”, 1998.

3. Педагогическая технология творческого развития : метод. пособие по развивающему обучению / А.З. Рахимов ; Башк. гос. педуниверситет. - Уфа : Творчество, 2003 . - 142 с.

# ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ МӘГЪЛҮМАТИ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНУ

Шиһабеддинова Г.Х.
ДАҺБУ “Г. Тукай ис. Арча педагогия көллияте”
shigabuddinova@mail.ru

**Аннотация.** В статье рассматриваются современные педагогические технологии, широко используемые в области языкового образования, в том числе при обучении татарскому языку. Среди них наиболее привлекательными считаются информационно-коммуникационные, дистанционные, игровые технологии и проектная технология. Использование их способствует развитию коммуникативной компетенции учеников, которая понимается как способность порождать высказывание на изучаемом языке.
**Ключевые слова:** языковое образование, татарский язык; современные технологии, коммуникативная компетенция.

Җәмгыятьтә барган үзгәрешләр чоры укыту-тәрбия эшенең дә барлык өлкәләренә яңача якын килү, аны яңача аңлауны таләп итә. Бу үзгәрешләр мәгариф өлкәсендә эшләүчеләр алдына яңа мәсьәләләр куя. Укытучылар бу яңарышларны тормышка ашыруда төп рольне башкаралар. Укыту-тәрбия системасын яңарту – яңа идеяләр, ысуллар, чаралар эзләү дигән сүз. Мәктәпләрнең бүгенге бурычы – хәзерге көн таләпләренә, тормыш, җәмгыять ихтыяҗларына җавап бирүче белемле, тирән фикер йөртә торган, социаль актив, карарларны мөстәкыйль кабул итә торган иҗади шәхес тәрбияләү [3, 5].

Соңгы елларда күп кенә яңа технологияләр тәкъдим ителде һәм гамәлгә кертелде. Аларның күбесе дәресләрдә уңышлы кулланыла. Укытучы һәм укучылар эшчәнлеген оештыру мәсьәләләрен алдан уйлап, башкарырга тиешле эшләрне системага салып кую укыту-тәрбия процессында уңышка ирешергә ярдәм итә.

Татар телен яңа заманча технологияләр аша өйрәтү – ул уку процессын яңача оештыру, ахыргы нәтиҗәләрне күзалларга омтылу, укучыларның актив эшчәнлегенә этәргеч бирү.

Соңгы елларда белем бирү системасында заманча метод-алымнардан уку процессын оештыру һәм идарә итүнең нәтиҗәлелегенә нигезләнгән педагогик технологияләр (терәк схемалар кулланып, алга китеп укыту, белем бирүнең компьютер, үстерелешле укыту, проектлар методы, концентрик белем бирү технологияләре) һәм укучылар эшчәнлеген активлаштыру һәм интенсивлаштыруга юнәлтелгән педагогик (уен, проблемалы укыту, аралашуга өйрәтү технологияләре) уңышлы кулланыла.

Татар теленә өйрәткәндә, заманча технологияләрне файдалануның мөһим бурычлары булып түбәндәгеләр санала:

- укучыда өйрәнелә торган фәнгә карата кызыксыну уяту;
- укучының танып белү активлыгын арттыру;

- тел өйрәнү өчен уңайлы шартлар булдыру, аралашу вакытында үзара ярдәмләшү мохите тудыру;

- укучының иҗади мөмкинлекләрен тулырак ачу, алган белемнәрен тирәнәйтү, инициативасын тагын да үстерү [4, 33].

Әлеге технологияләрнең берничәсенә тукталып үтик.

Дәресне заман таләпләренә туры килгән компьютерлар белән тәэмин итү – мәгълүмати технологияләрне гамәлгә куюда беренче шарт. Аларны укыту һәм тәрбия эшендә гамәлгә ашыру, укытучыдан фәнни-методик яктан әзерлек белән беррәттән, укытуны компьютер ярдәмендә оештыра белүне дә таләп итә. Бу – яңа технологияне нәтиҗәле куллануның иң мөһим педагогик шарты.

Компьютер – соңгы елларда уку процессына актив кертелгән һәм иң мөһим чараларның берсе. Аны куллану яңа мәгълүмати технологияләрдән файдалануны күзаллый.

Компьютер технологияләре төрле чаралар белән гамәлгә ашырыла: мөстәкыйль компьютер, автоматлаштырылган эш урыны, локаль исәпләү челтәре, компьютерлы мәгълүмат челтәрләре. Уку йортларында аның белән бәйле төшенчәләр актив һәм уңышлы кулланыла башлады: мәгълүмат базасы, укучының эш урыны, мультимедия системасы. Компьютер технологиясе – компьютер мөмкинлекләреннән файдаланып, өйрәнүчегә мәгълүматны әзерләү һәм тапшыру процессы ул. Ф.Харисов, татар телен өйрәткәндә, компьютерны түбәндәге очракларда кулланырга тәкъдим итә:

- тел күренешләренә өйрәткәндә;
- диалогны, аралашуны тәэмин иткәндә (компьютер челтәре аша);
- сөйләм осталыгын һәм күнекмәләрен формалаштырганда;
- белем һәм күнекмәләр булдыруның билгеле бер дәрәҗәсен тикшергәндә;
- кирәкле мәгълүматны укыту максатыннан чыгып эзләгәндә;
- уку материалын тәкъдим иткәндә һәм аңлатканда, төрле ситуацияләрне модельләштергәндә [5, 219].

Компьютер программаларын кулланып укыту ысуллары сөйләмгә өйрәтә торган диалогларны һәм төрле процессларны модельләштерү, уку материалын үзләштерүне контрольдә тотудан гыйбарәт. Моннан тыш, компьютер мөһим мәсьәләләрне хәл итәргә булыша. Мәсәлән: текстларны төзү һәм эшкәртү, укытучыны иҗади булмаган эштән бушату, өйрәнелә торган тел белән бәйләнешне арттыру. Шулай ук татар теленә өйрәтүнең төп методларын (күрсәтү, аңлату, төзәтү, белемнәрне бәяләү, күнегү) гамәлгә ашырырга ярдәм итә.

Тиешле белем бирү һәм алган күнекмәләрне кирәкле дәрәҗәдә үстерү өчен, заманча мәгълүмати технологияләрне дәрестә системалы һәм урынлы итеп файдалану зур әһәмияткә ия. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә бу технологияләрне куллануның өстенлеге бәхәссез. Барыннан да элек, алар шәхескә юнәлтелгән, ныклы һәм вариатив. Компьютер күрсәтмәлелекне, контрольлекне тәэмин итеп һәм күп мәгълүмат биреп, укытуның сыйфатын күтәрүгә ярдәм итә, этәргеч бирә.

Компьютер куллану шулай ук укучыны дөрес язарга, дөрес укырга өйрәтә, сүзлек запасын баета. Компьютерның өстенлеге шунда: мониторда барлык биремнәр матур, эстетик яктан камил эшләнә. Компьютер ярдәмендә бик күп эшләр эшләп була: мультимедиа презентацияләре, төрле тестлар, схемалар. Мәсәлән, презентацион программаларны төзегәндә, укытучы аның эченә бик күп материал: төрле схемалар, рәсемнәр, фотосурәтләрне кертә ала. Мондый программа белән танышканда, укучы үзен кино караучы итеп хис итә. Электрон презентацияләр даими кулланылганда гына, уңай нәтиҗәләргә китерә. Презентация слайдлары яңа материалны аңлатканда да, белемнәрне актуальләштерү этабында да, белемнәрне гомумиләштерү, системалаштыру этапларында да уңышлы кулланылырга мөмкин. Материал фәннилек, аңлаешлылык, күрсәтмәлелек принципларына җавап бирерлек итеп сайланырга тиеш. Яңа теманы аңлатканда, презентация бирелешенең әһәмияте зур. Слайдларда рәсемнәр, схемалар, даталар, терминнарга аңлатмалар, кыскача тезислар язылырга мөмкин. Яңа тема аңлату дәресе тулаем слайд карап утыруга гына кайтып калырга тиеш түгел. Дәрес барышында башка эш төрләре дә актив кулланыла: дәреслек белән эш, тактага язу, сүзлекләр белән эшләү һ.б. Шулай итеп, презентация материалын күрсәтү башка эш төрләре белән үрелеп бара. Электрон презентацияләр төзү укучыларга өй эше итеп тә бирелергә мөмкин. Мондый эшләр башкару укучыларга үз фикерләрен төгәл, җыйнак итеп әйтеп бирергә мөмкинлек бирә.

Телгә өйрәтүдә компьютер технологияләрен куллануның өстенлек яклары итеп түбәндәгеләрне күрсәтергә була:

- укытуда индивидуализация барлыкка килә;
- укучыларның компьютер белән кызыксыну укыту процессын мотивлаштыра;
- укучылар компьютер белән диалогны бик теләп башкаралар;
- хаталар булганда, компьютер тискәре эмоцияләрне белдерми;
- объектив билге куела [1, 143].

Компьютерның мөһим бурычларыннан берсе булып күнегүләр системасын тормышка ашыруны тәэмин итү тора. Ул исә үз чиратында, уку процессын камилләштерергә, сөйләм материалын үзләштерүне җиңеләйтергә тиеш. Эш барышында укучы үзенең җавапларының дөреслеген дә тикшереп бара ала.

Дәрестә уеннар оештыру – укытуның актив формалары һәм методларыннан файдалану ул.

Уенны оештыру өчен, элек төп бурычны билгеләргә, укучыларны уенга әзерләргә, аларны кирәкле теоретик белемнәр, төрле мәгълүматлар белән тәэмин итәргә кирәк. Уен шартлары һәм үзара аралашу кагыйдәләре белән таныштырырга; максатны һәм чишелергә тиешле бурычларны аңлатырга, уен барышында шул бурычларны үтәүгә ирешергә, чишелешнең дөреслеген тикшереп, нәтиҗәләргә бәя бирергә кирәк була.

Уенны нәтиҗәле үткәрү өчен, укучыларны кызыксындырырлык проблемалы сораулар куя белүнең дә әһәмияте зур.

Уку процессын интенсивлаштыру максатын истә тотып, уеннар төшенчәләрне үзләштерү, теманы өйрәнү, яңа материалны аңлату һәм ныгыту, сөйләм эшчәнлегенең тыңлап аңлау, уку төрләренә өйрәтү вакытында технология буларак файдаланыла ала.

Татар теленә өйрәткәндә, рольле уеннар аеруча актив кулланыла [6, 11]. Уеннарны парлап та, төркемләп тә үткәрергә мөмкин. Мондый уеннарны үткәрү өчен пьеса формасында уенның моделе төзелә. Укучыларга рольләрнең сүзләре бүлеп бирелә. Уен вакытында катнашучылар бер-берсе белән аралашалар, аларның табигый рәвештә нәрсәдер әйтү, нәрсә турында булса да сорау, әңгәмәдәшенә җавап бирү теләге туа.

Бу уеннар берничә этаптан тора: әзерләнү этабы (сценарий төзү, уен өчен кирәкле материалларны әзерләү, үткәрү планын төзү, максат-бурычларны билгеләү, уен кагыйдәләрен ачыклау, рольләрне бүлешү, төркемнәргә бүленү, консультацияләр үткәрү һ.б.); уенны үткәрү этабы (кирәкле чыганаклар белән эшләү, төркемнәрнең чыгышы, дискуссияләр үткәрү, экспертларның эшләре һ.б.); йомгаклау этабы (уенга анализ ясау; бәяләү; нәтиҗә ясау, киңәшләр бирү һ.б.). Рольле уеннар төрле тип дәресләрдә дә уңышлы кулланылалар.

XIX йөзнең беренче яртысында чит ил педагоглары И.Г. Песталоцци, А. Дистервег, рус галим-педагоглары К.Д. Ушинский, Л.С. Выготский тарафыннан үстерешле укыту технологиясенә нигез салына. Аның нигезен укучыларның танып белү мөмкинлеген активлаштыру һәм үстерү тәшкил итә.

Үстерешле белем бирү теориясе Л.В. Занков, Д.Б. Эльконин, В.В. Давыдов һ.б. педагогларның хезмәтләрендә алга таба эшкәртелгән. Хәзерге вакытта үстерешле укыту буенча берничә технология эшләнгән. Л.В. Занков технологиясе шәхесне төрле яклап үстерүне күздә тота, Д.Б. Эльконин – В.В.Давыдов технологиясе акыл эшчәнлеге үсешен алга куя, иҗади үсеш технологиясенең төп шарты – психологик уңай халәт тудыру. Проблемалы-үстерелешле белем бирү методларын эшләүгә М.И. Мәхмүтов зур өлеш керткән. Ул үз хезмәтләрендә укучыларның интеллектуаль мөмкинлекләре үсешендә бу методның нәтиҗәле булуын раслаган. Ә.З. Рәхимов иҗади үсеш технологиясенә нигез салган. Иҗади үсеш технологиясе, барыннан да элек, иҗади шәхес тәрбияләүгә юнәлтелгән. Ә.З. Рәхимов төп кагыйдәләр итеп укытучы һәм укучының дәрестә субъект буларак эшләвен, укытучының балалар эшчәнлеге белән идарә итүче дирижёр вазифасы башкаруын күрсәтә.

Дәресне иҗади үсеш технологиясе нигезендә үткәрүнең иң мөһим шарты – уку эшчәнлеген төркемнәрдә алып бару.

Профессор Ә.З. Рәхимов болай ди: “ИҮТ өч китта тора. Шуларның беренчесе – төшенчәнең эчтәлеген һәм аңа билгеләмә бирү буенча эш итү ысулын гомумиләштерү, икенчесе – укучылар эшчәнлеген төркемнәрдә оештыру, өченчесе – модельләштерү” [2, 132].

Шушы мөһим компонентларның берсе булган модельләштерүгә тукталыйк. Модель төзү – иҗади эш. Аның аша укучылар төшенчәнең үзенчәлекләрен, төп билгеләрен һәм эчке бәйләнешләрен ачалар. Типографиядә эшләнгән әзер күрсәтмә чаралар укучыларның фикерләү сәләтен үстерми, ә

модель укытучы һәм укучыларның бердәм уку эшчәнлеге нәтиҗәсендә туа. Укучылар төрле символлар, билгеләр, график модельләр белән эш итәргә өйрәнәләр.

Модельләштерү бигрәк тә теоретик материалны кыска бер фикер итеп күз алдына китерү өчен кулай.

Мәсәлән, “Исем” темасын өйрәнгәндә, модель төзү һәм төшенчәгә билгеләмә бирү этабын күзәтик:

Исем

↓

Мөстәкыйль сүз төркеме

↓

Предмет яки зат

↓

Кем? Нәрсә?

↓

Ия, хәбәр, аергыч, тәмамлык, хәл.

Бирем: модельгә таянып, исемнең билгеләмәсен бирергә.

Модельләштерү дәрестә төшенчә өстендә эш белән нык бәйләнгән. Төшенчә формалаштыру – дәреснең мөһим этабы. Чөнки төшенчә - логик фикер йөртүнең төп формасы булу белән бергә укучыларда фәнни белемнәр булдыруның төп чарасы да.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, татар теле дәресләрендә заманча технологияләрне куллануның өстенлеге бәхәссез. Барыннан да элек, технологияләр – шәхескә юнәлтелгән, ныклы һәм вариатив булуы белән аерылып тора. Компьютер, күрсәтмәлелекне һәм контрольлекне тәэмин итеп, күп мәгълүмат биреп, укытуның сыйфатын күтәрергә ярдәм итә, этәргеч бирә.

**Әдәбият**

1. Апатова Н.В. Информационные технологии в школьном образовании. – М.: Изд-во РАО, 1994. – 143 с.

2. Рахимов А.З. Психология семьи: учеб. пособие. – 2-е изд., доп. – Уфа: Башк. гос. пед. ун-т. 1999. – 132 с.

3. Федераль белем бирү стандартларын тормышка ашыруда татар теле һәм әдәбияты укытучысына фәнни-методик ярдәм / төз.: Р.Б. Камаева, А.Х. Мөхәммәтҗанова. – Казан: ТРМүи, 2015. – 110 б.

4. Харисов Ф.Ф. Татар телен өйрәтүдә заманча технологияләр / Ф.Харисов, Ч.Харисова // Мәгариф. – Казан, 2002. – № 8. – Б.33-36.

5. Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2002. – 367 б.

6. Харисов Ф.Ф. Татар теле: яңача укыту юнәлешләре. – Казан: Вестфалика, 2015. – 52 б.

# XIX ГАСЫР ТАТАР ТЕЛЕ ҮЗӨЙРӘТКЕЧЛӘРЕ

Юсупова Ә.Ш.
Казан федераль университеты
alyusupova@yandex.ru

**Аннотация.**Постоянное и периодическое издание самоучителей в XIX веке говорит о том, что была настоятельная необходимость обучения русских татарскому языку, что объясняется целями и задачами, как просвещения, так и восточной политики царского самодержавия и христианизацией. В самоучителях ставилась практические цели: обучить понимать, говорить, читать и писать на татарском языке. Эти цели в различных самоучителях осуществлялись по–разному. В большинстве самоучителей основное внимание уделяется пониманию и говорению. Обучение произношению проводилось при помощи транскрипции в основном на кириллице, которая, естественно, не в состоянии была передать правильное звучание тюрко–татарских слов и фраз. Структура и композиция самоучителей во многом совпадают. Почти во всех самоучителях лексика вводится по тематическому принципу. Это наблюдается в самоучителях, Ш.Саинова, М.Салихова, И.Кондратова. Основы коммуникативного принципа, который является главным среди лингвистических принципов в современной методике, были заложены уже в самоучителях XIX века. Во многих самоучителях отсутствуют теоретические и научные сведения по фонетике, морфологии, синтаксису татарского языка. Авторы ограничиваются лишь представлением алфавитов двух языков: татарского (на арабской графике) и русского. Это, несомненно, обедняет содержание самоучителей. Только в самоучителе И.Кондратова даются краткие сведения по грамматике татарского языка. В остальных трудах правила грамматики применяются только для составления речевых образцов и изучение его не является самоцелью, носит вспомогательный характер.
**Ключевые слова:** татарский язык, XIX век, самоучитель, методы

XIX гасырда татар теленә өйрәтү өчен дәреслекләр һәм укыту ярдәмлекләренә булган зур ихтыяҗ яңадан-яңа хезмәтләр язылуга китергән.

1880 елда Казанда “Татар теленнән яңа һәм тулы үзөйрәткеч яки русларга татар телендә һәм татарларга рус телендә сөйләшергә һәм укырга үзлегеннән өйрәнү өчен кулланма” исемле хезмәт басылып чыккан, аның авторы – Ш.Саинов. Тюркологларның хезмәтләрендә бу исем телгә алынмаган. Шуңа күрә бу автор турында биографик мәгълүматлар билгесез. Шунысы гына мәгълүм ки, Ш.Саинов укытучы булган. Хезмәтнең титул битендә автор болай дип язган: “Бу үзөйрәткеч яңа кулланмалар нигезендә укытучы Ш.Саинов тарафыннан төзелде”. Ш.Саинов татар укытучылар мәктәбенең инспекторы булган дигән караш яши [2,202]. Үзөйрәткеч 130 биттән тора, ул Мәскәү шәһәрендә Россия китапханәсендә саклана [7,210-215].

Үзөйрәткеч традицион рәвештә төзелгән. Беренче кисәктә татар теленең алфавиты бирелгән. Автор 32 татар хәрефенең язылышын һәм укылышын тәкъдим иткән. Алга таба юл өсте һәм юл асты ярдәмче тамгалары тасвирланган. Бу – әлеге дәвердә татар теленнән дөнья күргән үзөйрәткечләрнең барысы өчен дә хас үзенчәлек.

Башка үзөйрәткечләрдән аерылмалы буларак, Ш.Саинов үзөйрәткечендә сүзләрне дөрес уку өчен күнегүләр китерелгән. Башта автор сүзләрнең тәрҗемәләрен биргән, соңыннан, истә калдыру һәм ныгыту максатыннан, бу сүзләр гыйбарәләр эчендә тәкъдим ителгән. Беренче төркем 79 сүздән тора. Сүзләр төрле өлкәләргә карый. Тематик принцип сакланмаган. Мәсәлән, تآ – ат, توا – ут, نوا – ун, نامروا – урман, ىوا – өй, رق – кыр, وات – тау, راق – кар, تيا – ит [3,8–11] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, сүзләрнең транскрипциясе күрсәтелмәгән.

Сүзләрдән соң гыйбарәләр урын алган. Мәсәлән, ىن وب бу ни? زغك قآ –ак кәгазь, زپراق نكشپ – пешкән карбыз, چقصاب رميت – тимер баскыч, روض هزهرت – зур тәрәзә, شاب اتوا – баш авырта, تيا نكشپ – ит пешкән, ىاب لو – ул бай, چاكشا – ишек ач [3,10–12]. Гыйбарәләр арасында сүзтезмәләр һәм гади җөмләләр бар.

Сүзлекнең зур өлешен татарча-русча сүзлек тәшкил итә. Сүзләр тематик төркемнәргә бүленгән. Барлыгы 29 төркем бирелгән. «Части человеческого тела» (“Кеше тәне әгъзалары”), «Учебные принадлежности» (“Уку әйберләре”), «Слова, обозначающие действия» (“Хәрәкәтне белдерә торган сүзләр”), «Пять чувств» (“Биш хис”), «Названия животных» (“Хайван исемнәре”), «Названия птиц» (“Кош атамалары”), «Насекомые и гады» (“Бөҗәкләр һәм әкәм-төкәмнәр”), «Минералы» (“Минераллар”), «Деревья, растения» (“Агачлар, үсемлекләр”), «Упряжь» (“Җигем”), «Родство» (“Туганлык”), «Природа» (“Табигать”), «Дом и двор» (“Йорт һәм ишегалды”), «Одежда» (“Кием”), «Пища и напитки» (“Ашамлык һәм эчемлек”), «Профессия и ремесла» (“Һөнәр һәм кәсеп”), «Цветы» (“Чәчәкләр”), «Орудия» (“Кораллар”), «Человек» (“Кеше”), «Имена» (“Исемнәр”), «Свойства» (“Үзлекләр”), «Глаголы» (“Фигыльләр”), «Вес и мера» (“Үлчәм һәм чама”). Шунысын билгеләргә кирәк: әлеге тематик төркемнәр шул чор татар теленнән үзөйрәткечләрнең барысында да чагылыш тапкан, ләкин бу хезмәттә алар тулыландырылган һәм үз эчендә берничә төркемгә бүленгән. Мәсәлән, «Столовый прибор» (“Табын дирбиясе”), «Чайный прибор» (“Чәй савыт-сабасы”) төркемнәре аерым бирелгән. «Имена стран и народов» (“Ил һәм халык атамалары”) дигән үзенчәлекле төркем бар. Тематик төркемнәрнең исемнәре бары тик рус телендә генә бирелгән.

Традицон рәвештә бу үзөйрәткечтә дә «Разговоры» («Суйляшуляръ») диалоглары бирелгән. Аларның рус теленә тәрҗемәләре күрсәтелмәгән. Мөгаен, автор бу эшне укучыларның үзләренә калдырган. Диалоглар сорау-җавап рәвешендә төзелгәннәр һәм ике кешенең сөйләшүе буларак бирелгән.

Ш.Саинов, укучыларны татар халык авыз иҗаты белән таныштыру максатыннан, әхлакый характердагы мәкальләр тәкъдим иткән. Мәсәлән, Гыйлемлекъ байлыктанъ яхшыракъ. Күп бел, аз сөйлә. Эшне башлаганда ахрынъ уйла. Бер иске дусъ яңаның икесеннән артыгракъ. Тимерне кызуында сукъ. Бурычны түләсәң ямьле. Бер колъ ике хуҗага хезмәт итми [с.95]. Еди үлчә бер кис [с.96]. Тугры сүз күзне тишә [с.97]. Яхшыдан качма, яманны кылма [с.97]. Һәр орлыкның үз буразнасы [с.99]. Балта юл өчен иптәш [с.99].

Ш.Саинов үзөйрәткече русларга татар телен өйрәтү өчен төзелгән үзөйрәткечләр арасында матур үрнәк булып тора.

1885 елда М.Ш.Салиховның “Татар теленнән яңа үзөйрәткеч”е басылып чыккан. Хезмәт Казан император университетының басмаханәсендә дөнья күргән, 53 биттән тора. 1893 елда басылган икенче басма тулысынча беренчесе белән туры килә.

Билгеле булганча, М.Ш.Салихов мәдрәсә мөгаллиме булган [1,254]. Шунысы да билгеле: М.Ш.Салихов татар фольклоры белгече булган һәм 1880 елда беренче татар табышмаклары һәм мәкальләре җыентыгын бастырган.

М.Салиховның үзөйрәткече, алда карап киткән башка хезмәтләрдән аерылмалы буларак, җайлырак рәвештә төзелгән; кереш өлештә шулай ук татар һәм рус телләренең алфавитлары урнаштырылган. М.Салихов татар алфавитында 33 хәрефне билгеләгән. Аларның язылышы, уку кагыйдәләре аңлатылган. М.Салихов түбәндәгечә язган: “Татар язуын уңнан сулга таба укырга кирәк. Сүзләрне укыганда бу хәрефләр кыскартылып әйтеләләр” [4,3].

Үзөйрәткечнең кереш өлешендә автор татар авазларын рус авазлары белән чагыштырган: “ا элифъ рус авазлары **э**, **и**, **у** кебек әйтелә; мәсәлән, ب دا – эдебъ – образованность, فاصنا – инсафъ – скромность, ديما умидъ – надежда, әгәр юл өстендә (˜) мәддә тамгасы булса һәм сүзнең уртасында һәм ахырында рус телендәге **а** авазы кебек әйтелә, мәсәлән, طآ ат, شاٿ таш; ب тулысынча рус телендәге **б** авазына тәңгәл: رابْ – баръ – есть; **п** پавазы кебек әйтелә: هاشداپ – падша – царь; تавазы рус телендәге **т** шикелле: هزرٿ– тярязя – окно” [4,5].

Русча-татарча сүзлек рәвешендә төзелгән үзөйрәткечтә сүзләр 47 тематик төркемгә бүленгән. Сүзләр кириллица һәм гарәп шрифтында язылган. Тематик төркемнәргә киң кулланылышта булган сүзләр кертелгән. Аларның кайберләре хәзерге вакытта фонетик үзгәреш кичергән. Аерым бер сүзләр диалектларда гына сакланып калган. Татар сүзләренең Пугачев күтәрелеше вакытында татар телендәге документларда теркәлгән борынгы вариантлары да очрый [8,162]. Түбәндәге тематик төркемнәр күрсәтелгән: “Рухи сүзләр”, “Җир шары”, “Кеше һәм кеше тәне әгъзалары”, “Кием”, “Авырулар”, “Ашамлыклар һәм эчемлекләр”, “Язу әйберләре”, “Фәннәр”, “Кәсепләр”, “Хайваннар дөньясы”, “Үсемлекләр”, “Җимешләр” һ.б.

Г.Ваһапов (1867 елдан соңгы басмалар), М.Бекчурин һәм Ш.Саинов үзөйрәткечләреннән аермалы буларак, М.Салихов үзөйрәткечендә диалоглар, гыйбарәләр, халык авыз иҗаты үрнәкләре бирелмәгән. М.Салихов хезмәтендәге тематик төркемнәрнең лексик составы Г.Ваһапов (1864, 1867) үзөйрәткечләренең беренче басмалары белән охшаш.

1887 елда Казан университеты типографиясендә билгесез авторның “Татар теленнән яңа тулы үзөйрәткеч яки русларга татар телендә һәм татарларга рус телендә сөйләшергә һәм укырга өйрәнү өчен кулланма” исемле 51 биттән торган хезмәте басылып чыккан. Авторның исеме тышлыкта да, титул битендә дә күрсәтелмәгән. Китап белгече, татар кулъязмаларының зур остасы, Н.И.Лобачевский исемендәге китапханәнең сирәк китаплар бүлегенең элекке мөдире – А.Фәтхиев билгеләвенчә, бу үзөйрәткечне төзүче кеше Г.Ваһапов булырга мөмкин. Ул хезмәтнең тышлыгында Г.Ваһапов авторлыгын күрсәтә торган тамга билгеләгән, әмма Г.Ваһапов үзөйрәткечләре арасында 1887 елгы басма очрамый. Хезмәт сүзлек составы, күләме белән дә аерыла. Моннан тыш, үзөйрәткеч Ш.Саинов хезмәте белән зур охшашлык күрсәтә. Күбесенчә гыйбарәләр, тематик төркемнәр, лексик берәмлекләр туры килә.

Башка үзөйрәткечләрдәге кебек үк, кулланманың кереш өлешендә ике телнең алфавиты чагыштырма рәвештә тасвирланган. Татар әлифбасы бирелгән [6,2]. Ярдәмче яки юл өсте һәм юл асты тамгалары [6.3], рус әлифбасы [6,4–5].

Үзөйрәткечнең төп өлешен 22 тематик төркемгә бүленгән татарча-русча сүзлек тәшкил итә. Сүзлекнең лексик составы Г.Ваһапов үзөйрәткечләрендә бирелгән сүзләр белән күп очракта туры килә, ләкин теге яки бу лексик берәмлекнең бирелешендә кайбер аермалар да бар (фонетик үзгәрешләр, сүзләрнең диалект вариантлары). Тематик төркемнәр түбәндәгечә урнаштырылган: مويك кием – одежда, چاغا агачъ – дерево, قايا ىمويك аякъ кіеми – обувь, واشا ашау – ъда, رلكمچا ичемлекларъ – напитки, ونيك кіену –наряд تغامج джямагать – семейство, رلناص санларъ – числа, رلسوت тусляръ – цвъта, تقو вакытъ – время, واچلوا үльчау – въсы.

Кайбер тематик төркемнәр билгеләнмәгән, ягъни исемнәре күрсәтелмәгән. Алар тормышның төрле өлкәләрен чагылдыралар (дин, дөнья, төзелеш, мебель, уку әйберләре, хайваннар, җимешләр, металлар, ат дирбиясе, гумно, фигыльләр).

Үзөйрәткечнең соңгы өлешендә 84 татар халык мәкале һәм әйтеме бирелгән. Алар рус теленә тәрҗемә ителгән яки рус телендәге эквивалентлары тәкъдим ителгән.

Бу үзөйрәткечне тәфсилләп өйрәнү нигезендә без түбәндәге нәтиҗәгә килдек: әлеге хезмәт Г.Ваһапов һәм Ш.Саинов үзөйрәткечләренең синтезы булып тора. Үзенең төзелеше, сүзлек составы белән үзөйрәткеч Г.Ваһапов китабына якын тора, гыйбарәләр, халык авыз иҗаты үрнәкләре күп очракта Ш.Саинов үзөйрәткечендә бирелгән мисаллар белән туры килә. Әмма без үзөйрәткечнең теге яки бу авторныкы булуын дәлилли алмыйбыз.

1893 елда Казан император университетында И.Кондратовның “Татар теленнән яңа гамәли үзөйрәткеч” исемле хезмәте басылып чыккан. Кызганычка каршы, автор турында бер генә нәрсә әйтергә мөмкин: ул казан тюркологы булган  [1,192]. Башка мәгълүматлар сакланмаган. Үзөйрәткеч 90 биттән тора; 6 тапкыр басылган; Н. Лобачевский исемендәге китапханәдә 1893, 1908, 1911, 1914 елгы басмалар сакланып калган. Бу хезмәтләр барысы да үзгәрешсез басылганнар, шуның өчен без беренче басманы гына тикшерәбез.

Автор А. Троянский (1824, 1833, 1860), Г. Мәхмүдов (1857) хезмәтләре, М. Салихов  ( 1885) үзөйрәткече белән яхшы таныш булган. Үзенең үзөйрәткечен ул шушы китаплар нигезендә язган. Китапның титул битендә И.Кондратов үзе үк болай дип билгеләгән: “Үзөйрәткеч А.Троянский, Г.Мәхмүдов һәм М.Салиховка таянып төзелде”  [5,1].

Китап татар һәм рус алфавитларын күрсәтү һәм аңлату белән башланган. Ике телнең алфавитлары белән таныштыргач, И.Кондратов татар грамматикасының нигезләрен биргән. Ул болай яза: “Татар грамматикасында (нәхү) баш хәрефләр һәм тыныш билгеләре юк. Шулай ук язу вакытында хәрефләрнең астында һәм өстендә сузык авазлар кулланылмый.

Татар телендә сүзләрнең, фикернең бүленеше аларның тәртибенә карап билгеләнә. Татар телендә хәрефләр сузык, ике сузыклы, өч сузыклы була. Сузык авазлар дип әйтелеш вакытында бары бер генә аваз ишетелгәннәрне атыйлар; алар өчәү: ى و ا. Ике сузыклы авазлар ике сузыктан торалар һәм әйтелеш вакытында бер аваз булып ишетеләләр; алар 7: وا – о, وا – у, اى – эй, آى – ай, ايـ – я, ويـ – ю, ييـ – йи. Өч сузыклы авазлар өч сузыктан торалар, бер иҗекне тәшкил иткән катнаш аваз чыгаралар; алар 4: اوى – ой, ايى – яй, ويى – юй, يى – ей. Тартык авазлар сузыклардан башка әйтелмиләр. Әгәр сүзнең уртасында һәм ахырында бер сузык аваз булса, сузыклары булмаган хәрефләр күп очракта аңардан көч алалар һәм шуның ярдәмендә төзеләләр. Сузык хәрефләре булмаган сүзнең әйтелешен билгели торган сузык тамгалар көчсезрәк, тизрәк, йомшаграк әйтеләләр.Татарларда мужской һәм женский род дигән төшенчә юк” [5,14].

“Күнегү өчен сүзләр” бүлегендә автор үзенең укучыларын кайбер сүз төркемнәре белән таныштырган. Беренче чиратта, И.Кондратов 33 алмашлыкны күрсәткән. Алар арасында зур урынны бүгенге көндә дә киң кулланылышта йөргән алмашлыклар алып тора: я – مين минъ, ты – سين син, кто – كم кем, что – نى ни. [ Кондратов, 1893:15]. Аннан соң “Теркәгечләр, рәвешләр, бәйлекләр” дип аталган бүлек бирелгән, анда ярдәмче сүз төркемнәре, модальлек төшенчәсен белдергән сүзләр тикшерелгән [5,25].

Үзөйрәткечнең зур өлешен русча-татарча сүзлек алып тора, сүзлектә 47 тематик төркем бирелгән. Төркем исемнәре, аларның лексик составы М.Салихов үзөйрәткечендәге кебек. Шулай да аермалар бар, һәм алар тематик төркемнәрнең урнаштырылуына бәйле. Сүзлек 49 биттән тора. Алга

таба “Күнегү өчен гыйбарәләр”, “Сөйләшүләр” исемле бүлекләр урын алган. Бу бүлекләрдә гади, җыйнак җөмлә үрнәкләре бирелгән. Мәсәлән:

نم ىشک Мин кеше
نيس ذيا وک Син изге
نم لايقنم Мин кыламын
املیق نس نسى Син кылмыйсың
وم زبلايق زب Без кылабызмы?
مديا روليق نم Мин кылыр идем
وم زكنديا روليق زس Сез кылыр идегезме?
زس زساناشا Сез ышанасыз
[5, 80].

Соңгы “Сөйләшүләр” бүлегендә диалог үрнәкләре бирелгән, аларда сүз грамматика, тәрҗемә сәнгате, сәламәтлек, язу турында бара.

И.Кондратовның татар телен өйрәнү өчен төзелгән үзөйрәткече традицион төзелеш калыбын саклаган. Хезмәтне өлешләп тикшерү нигезендә шундый нәтиҗә ясарга мөмкин: грамматик мәгълүматны автор А.Троянский һәм Г.Мәхмүдов китапларыннан алган, хезмәтнең лексик составы М.Салихов үзөйрәткече белән туры килә, диалоглар, югарыда әйтелгәнчә, А.Троянский грамматикасыннан алынган.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, XIX гасырда дөнья күргән татар теле үзөйрәткечләре гамәли максатларны күздә тотып төзелгәннәр. Бу хезмәтләрдә үз заманының иң үтемле тел өйрәтү методлары кулланылган. Әлеге хезмәтләр XIX гасырда татар телен өйрәнүгә булган зур ихтияҗны тормышка ашыруда зур роль уйнаганнар һәм алар үзләренең мнтодик кыймммәтләрен бүген дә югалтмый.

**Әдәбият**

1.Кононов А.Н. Биобиблиографический словарь отечественных тюркологов (дооктябрьский период) . М.: Наука, 1974. – 340 с.

2.Михайлова С.М. Казанский университет в духовной культуре народов Востока России. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1991. – 359 с.

3.Саинов Ш. Новый и полный самоучитель татарского языка или руководство выучиться без посторонней помощи говорить и читать русским по-татарски и татарам по-русски. Казань,1880.130с.

4.Салихов М. Новый самоучитель татарского языка или руководство выучиться говорить и читать русским по-татарски и татарам по-русски, без посторонней помощи. Казань: типография императорского университета, 1885. - 53 с.

5.Кондратов И. Новый практический самоучитель татарского языка. Полное руководство, как без посторонней помощи выучиться говорить и читать русским по-татарски, а татарам по-русски.

6.Новый и полный самоучитель татарского языка или руководстве выучиться говорить и читать русским по-татарски и татарам по-русски* Казань: типография императорского университета, 1887. - 52-е.

7.Сафиуллина Ф.С. Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре Казан: ТаРИХ, 2001. – 432 б.
8. Хисамова Ф.М. XVШ йөздәге татарча эш кәгазе язмаларынын тел үзенчәлекләре Казан: Казан ун-ты нәшр., 1981. – 162 б.

# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ДИСТАНЦИОН УКЫТУ ТЕХНОЛОГИЯСЕН КУЛЛАНУ

Юсупов А.Ф., Юсупова Н.М.
Казан федераль университеты
*faikovich@mail.ru*

**Аннотация.** Статья посвящена изучению современных информационных технологий в образовательном процессе, в частности использованию технологии дистанционного обучения на уроках татарского языка и литературы. Как известно, концепция модернизации российского образования ставит новые цели и задачи перед общим образованием на современном этапе. В современной системе образования стремительно набирает скорость процесс внедрения информационно-коммуникационных технологий, которые должны быть направлены на развитие познавательной самостоятельности и творческих способностей учащихся.
**Ключевые слова:** родной язык, татарская литература, информационные технологии, дистанционное обучение.

XXI гасыр башында илдә барган иҗтимагый яңарыш мәгариф өлкәсенә, шул исәптән татар теле һәм әдәбиятын укыту методикасына да үзгәрешләр алып килде. Заман таләбе, яшьләрнең кызыксыну өлкәләре үзгәрү уку процессына да зур йогынты ясады. Белем бирү традицион форма кысаларыннан чыгып, укучы өчен актуаль һәм кызыклы булырга, аны җәмгыяткә яраклаштырырга тиеш дигән фикер алга куелды. Бу исә укытучыларга – белем бирү процессы белән идарә итүчеләр буларак – яңа мәгълүмати технологияләр белән хәбәрдар булуны, аларны дәресләрдә нәтиҗәле куллана белүне көн тәртибенә куйды.

Онлайн белем бирүнең тарихы, мәгълүмати технологияләр тарихына караганда күпкә кыскарак. Онлайн укыту бүген мәгълүмати технологияләрнең үзенә күрә иң югары дәрәҗәсе дияргә мөмкин, аның барлыкка килүе технологик трансформация белән генә түгел, ә иҗтимагый трансформация, җәмгыятьнең традицион белем бирү модельләреннән китәргә әзерлеге белән бәйләнгән. Бүген классик белем бирү форматлары торган саен азрак ихтыяҗ тудыра, шул ук вакытта, төрле онлайн-ресурсларны кулланучыларның саны даими үсештә.

Тулы масштаблы онлайн укыту 2001 нче елда, Массачусет технологик институты OpenCourseWare проектын ачып җибәреп, үзенең бер төркем уку-укыту материалларына һәм белем бирү программаларына ачык керүне игълан иткәч башлана. Әгәр әлеге моментка кадәр онлайн укыту системалы характерга ия булмаса, бу моменттан ул комплекслы тәмамланган продукт буларак тәкъдим ителә. Бүгенге көндә унбер меңгә якын ачык белем бирү программалары бар, дип исәпләнелә, аларның егерме миллионга якын тыңлаучылары бар [5: 21].

Шулай итеп, онлайн укыту – безнең көннәрдә ачык белем бирүнең киң таралыш алган формасы. Онлайн укыту – өйрәнү өчен өстәмә материаллары, тестлары һәм арадаш аттестация эшенең башка биремнәре булган кыска видеолекцияләр сериясеннән гыйбарәт. Ахырда теге яисә бу курсны үтү һәм үзләштерүне раслаган сертификат алу мөмкинлеге бар. Теләсә кайсы эш формасы кебек үк, бу төр укытуның да уңай һәм кимчелекле яклары бар. Онлайн укытуның өстенлекле ягы лекцияләрне тыңлау мөмкинлеге булуга бәйле, ләкин бу очракта укытучы белән аралашу кими [7: 20]. Онлайн белем алу, кайда һәм кайчан укырга уңайлы булуга бәйле төстә, белем алу процессын мөстәкыйль оештыру мөмкинлеген бирә. Әмма шушы ук факт кулланучылардан үздисциплина һәм даими төстә укуга мотивация булдыруны да таләп итә. Мондый укытуның төп өстенлеге, кешенең үз белем траекториясен шәхси кызыксынулары һәм ихтыяҗларына бәйле рәвештә мөстәкыйль билгели алуына бәйле. Әмма, галимнәр искәртүенчә, мәктәптәге предметларны онлайн укыту белән алыштыру реаль түгел, чөнки, алар нинди генә плюс якларга ия булмасыннар, белем бирү алдында торган бурычларның күпчелеген мәктәп стеналарыннан тыш хәл итеп булмый. Ләкин мондый система мәктәптәге предметларны өйрәнүдә һәм дәресне тулыландыруда файдаланыла ала, теманы, предметны тирәнрәк өйрәнү мөмкинлеге бирүче яхшы ресурс булырга мөмкин.

Онлайн укыту, башлыча, теоретик белемнәрне гамәлдә куллануга һәм метапредмет якын килүгә юнәлдерелгән. Онлайн укыту укытучының укучыларга индивидуаль якын килүен гамәлгә ашыруда өстәмә механизм була ала. Биредә укытучының төп максаты булып онлайн укыту потенциалын традицион дәресләр белән интегральләштереп дөрес һәм нәтиҗәле куллану торачак.

Белем бирү оешмаларындагы предметлар кысаларында онлайн укыту технологиясе белән эшләүнең берничә варианты бар:

– онлайн укыту материалын өй эше сыйфатында өйрәнү;

– үзләштерелгән белемнәрне контрольгә алу формасы буларак онлайн укыту тестларын һәм арадаш аттестация эше биремнәрен башкару;

– теманы тирәнрәк үзләштерү өчен онлайн укытуны өстәмә материал сыйфатында куллану;

– онлайн укыту мөмкинлекләрен укучыларның мөстәкыйль иҗади һәм проект эшчәнлегендә куллану;

– материалны тел предметы (яисә башка предмет та булырга мөмкин) буенча программаны үзләштерүдә һәр укучының «йомшак» якларын һәм ныгытырга кирәк булган белемнәрен исәпкә алып сайлау.

Электрон белем бирү фәндә ике төрле мәгънәдә аңлашыла: 1) мәгълүмати-телекоммуникацион технологияләр ярдәмендә уку; 2) яңа мультимедиа технологияләр һәм Интернетны куллану хисабына уку-укыту сыйфатын арттыру [3: 313].

Татар телендә электрон белем бирү ресурслары, гомумән, белем бирү системасындагы кебек үк, үсеш юлында берничә этап кичерә.:

1) беренче этап (1990 нчы еллар). Электрон белем бирүнең төп ресурсларын электрон дәреслекләр тәшкил итә;

2) икенче этап (2000 – 2004 нче еллар). Дистанцион уку системасы формалаша;

3) өченче этап (2004 – 2009 нчы еллар). Болытлы сервислар барлыкка килә;

4) дүртенче этап (2008 – 2011 нче еллар). Электрон укуда ачык курслар барлыкка килә;

5) бишенче этап. Онлайн-курслар оешып китә [4: 8].

Уку-укыту китабының перспектив юнәлешләре турында сөйләгәндә, белгечләр киләчәктә әйдәп баручы булып мәгълүмати-коммуникацион технологияләр мөмкинлекләреннән файдаланып төзелгән электрон (мультимедияле) дәреслекләр торачак дигән фикерне үткәрәләр. Электрон дәреслек дигәндә, «аерым гына файдаланырга мөмкин булган, басма аналоглары булмаган, өстәвенә уку материалы кысаларын киңәйтә, мәктәп курсы белән генә чикләнмичә, өстәмә белем алу мөмкинлеге бирә торган аерым бер продуктны» атыйлар [1: 10]. Т.С. Круст, төрле предметларга караган электрон дәреслекләрнең телен, стилен, жанр үзенчәлекләрен өйрәнеп, мондый нәтиҗәгә килә: «Электрон дәреслек – фәнни стильгә караган жанрлар системасында «дәреслек» жанрының бер вариантын, ә компьютер тирәлегендәге мәгълүмати жанрлардан мөстәкыйль жанрны тәшкил итә. Ул билгеле бер адресатка юнәлдерелә, белем бирү максаты белән төзелгән каты структуралы гипертекст буларак төзелә; аңа мультимедиялелек, интерактивлык, катлаулы төзелешле булу, мәгълүматның фәнни стильдә тапшырылуы хас; метател аңында электрон дәреслекләрнең релевант билгеләре булып гипертекстуальлек, мультимедиялелек, мәгълүматның дәреслек битләрендә фрейм рәвешендә бирелеше тора» [6: 24].

Программалаштырылган электрон дәреслек укытучы башкара торган кайбер вазыйфаларны да үти башлый: «мәгълүмат чыганагы булып тора; уку-укыту процессын оештыра; материалның үзләштерелү дәрәҗәсен контрольдә тота; предметны өйрәнүнең темпын көйли; аңлатмалар бирә; хаталарны кисәтә» [8: 303]. Электрон дәреслектән тыш, укытучы дәрестә эшне электрон кушымтага нигезләнеп тә алып барырга мөмкин. Бу очракта укытучы никадәр күбрәк чыганакка нигезләнеп эш итә, эшчәнлекне никадәр төрләндерә ала, шулкадәр яхшырак, нәтиҗәлерәк санала.

Бүгенге көндә һәрбер дәреслекнең электрон варианты бар, әмма ул басма вариантны тулысынча кабатламый, ә бәлки өстәмә материал буларак файдаланыла. Мисал өчен, рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында татар телен өйрәнүче укучыларга атап төзелгән дәреслекләрнең электрон формаларында дүрт төрдәге биремнәр тәкъдим ителгән: аудиоязма, диктант, тест һәм физкультминутлар өчен видеороликлар. Моннан кала электрон дәреслек, электрон кушымталарда диктор укуындагы текстлар тәкъдим ителә. Әлеге төр биремнәр, беренче чиратта, укучыларга авазларны дөрес әйтергә өйрәтсә, икенче чиратта, аларны әсәрне сәнгатьле итеп укырга өйрәтә.

Дистанцион уку системасына килгәндә, «дистанцион курслар кулланучыларны табигый сөйләм эшчәнлегенә җәлеп итәләр һәм бүгенге көн реалияләренә туры киләләр. Алар матур итеп бизәлгәннәр, бу исә кулланучыларда татар телен өйрәнүгә өстәмә мотивация тудыра» [2: 279].

Дистанцион уку системасын камилләштерү юлында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан җитди эшләр алып барыла. Мисал өчен, «Ана теле» онлайн-мәктәбе сыйфатлы сервис аркылы татар теленә өйрәнү мөмкинлеге бар. Шулай ук, «Бала.рф» виртуаль китапханәсе дә «үзебезнең илдәге һәм чит илдәге татар балаларын дистанцион укытуда эффектив ресурс» буларак бәяләнә ала.

Тагын бер уңышлы эшләп килүче татар телле интернет-ресурс – «Татармультфильм». Әлеге берләшмәнең продуктлары сыйфатлы, җанлы, тәэсирле булулары белән аерылып торалар. Берләшмә халык әкиятләрен, атаклы әдипләрнең иҗатларын мультфильм яки анимацияле рәт буларак тәкъдим итә. Шуны билгеләп үтәргә кирәк: мультфильмнарны карау алдыннан укучыларга берничә төрле эш тәкъдим ителә: яңа лексика белән таныштыру, кайбер сүзләрнең мәгънәләрен ачыклау – сүзлек эше, видеосюжетның исемен аңлату һ.б.

Дәреслектә тәрҗемәләр эше өчен биремнәр аз күләмдә генә бирелә, укучының әсәрне аңлавында контекст, укытучы ярдәме зур булачак дип күзалланырга мөмкин. Шул рәвешле әзерлек эше алып барылганнан соң, укытучы турыдан-туры видеоматериалны күрсәтүгә керешә. Сыйфатлы итеп ясалган видеоматериал, кызыклы сюжет, ачык төстәге бизәлеш, әсәрнең мультфильм жанрына яраклаштырылып бирелүе гадәттә балаларга ошый, уңай мотивация тудыра. Мультфильм каралганнан соң, текст материалын аңлау дәрәҗәсе күнегүләр белән эш вакытында тикшерелә.

Билгеле булганча, укылган текст буенча сорауларга җавап бирү кызык булмаска мөмкин, сораулар укучыда авырсыну да тудыра ала. Әмма мультфильм караганнан соң аның темасы, идеясе, геройлары башлангыч сыйныф укучысы күңелендә урын ала, димәк, бирем дә җиңеллек белән башкарылыр дип уйларга җирлек бар. Берләшмәнең проекты булган «Бала.рф.» виртуаль китапханәсенең кыйммәте аеруча зур булып аңлашыла, биредә җанлы, кызыклы ресурслар тест биремнәре һәм әңгәмә өчен сораулар белән тулыландыра. Күп кенә әсәрләр рус балаларына татар теленә – дәүләт теленә өйрәнү әсбапларындагы текстлар белән аваздаш.

Чираттагы татар телле интернет-ресурс – «Татар теле онлайн» интерактив интернет-дәреслеге. Әлеге интерактив дәреслек түбәндәге максатларга ирешүне күз уңында тота: 1) киң җәмәгатьчелекне алдынгы Интернет-технологияләрне кулланып татар телен мөстәкыйль өйрәнүгә җәлеп итү; 2) татар телен, мәдәниятын, тарихын һәм сәнгатен өйрәнүгә кызыксыну уяту; 3) белем бирүче Интернет-ресурсларны киңәйтү. Бу дәреслектә аудиоматериалларны тыңлау һәм татар теленең фонетикасы, лексикасы һәм грамматикасы буенча биремнәрне үтәү; текстны укып, дөрес җавапларны яки бер генә дөрес җавапны табу; текстның төшеп калган урыннарына язып бетерү; бирелгән хәрефләрдән

сүзләр һәм сүзләрдән җөмләләр төзү; телдән һәм язма сөйләмгә кагылышлы биремнәрне үтәү һ.б.лар урын алган.

Болытлы сервисларны куллану буенча да татар теле һәм әдәбияты укытучылары нәтиҗәле эшчәнлек алып баралар. Гугл-диск болытлы сервис укучыга үз эшчәнлегендә кулланырга мөмкин булган мәгълүматны кертергә, сакларга, кирәкле вакытта укучылары яки коллегалары белән бүлешергә мөмкинлек бирә. Әлеге сервис ярдәмендә графикалы, текстлы, аудио һәм видеофайлларны, электрон таблицаларны, презентация, графика, диаграммаларны карарга һәм үзгәртергә була. Белгечләр ассызыклаганча, әлеге сервис саклау вазифасын гына башкарып калмый, ә файллар белән коллектив рәвештә эшләү мөмкинлеген дә бирә. Гугл-диск, гугл-формалар ярдәмендә укытучылар, аларның үз сүзләре белән әйткәндә, укучылар арасында сораштыру оештырганда, проект һәм реферат темалары буенча эшләгәндә һәм укучыларга тәкъдим иткәндә, интерактив биремнәр эшләгәндә, онлайн-тестлар эшләгәндә нәтиҗәле эш алып баралар [9: 51-52].

Гомумән алганда, татар теле һәм әдәбиятына өйрәтү заманча шартларда, заманча ысуллар һәм сыйфатлы ресурслар ярдәмендә тормышка ашырыла. Ул ресурслар укытучының вакытын тиешенчә сарыф итү мөмкинлеген бирә, дәреснең җанлылыгын тәэмин итә.

**Әдәбият**


1. Бәшәрова А., Шәмсетдинова Р. Татарча электрон кушымталар һәм дәреслекләр // Мәгариф. – 2016. – №1. – Б. 10-12.

2. Замалетдинов Р.Р., Фатхуллова К.С., Юсупова А.Ш. Из опыта использования мультимедийных технологий в обучении татарскому языку // Филология и культура. – 2013. – №3(33). – С. 277-281.

3. Исследовательская лингводидактика по русскому языку: теория, практика, инновации: монография. – М.: РУДН, 2016. – 598 с.

4. Краснова Г.А. Можаева Г.В. Электронное образование в эпоху цифровых трансформаций. – Томск: Изд. Дом Томск. гос. ун-та, 2019. – 200 с.

5. Кузнецов Н.В. Онлайн-образование: ключевые тренды и препятствия // E-Management. – Т. 2. – №1. – 2019. – С. 19-25.

6. Куст Т.С. Жанровая природа электронного учебника: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Томск, 2011. – 25 с.

7. Основы открытого образования: в 2 томах. Т. 1. / Отв. ред. В.И. Солдаткин. – М.: НИИЦ РАО, 2002. – 676 с.

8. Радчиков А.С., Радчикова Н.П. Использование электронных учебников для организации самостоятельной работы студентов / Женщина. Общество. Образование. Материалы 12-ой международной научно-практической конференции (18-19 декабря 2009 г.). – Минск, 2010. – С. 304-308.

9. Яхин И.Использование Гугл-форм в педагогической практике // Мәгариф. – 2016. – №1. – Б. 51 – 52.

СОДЕРЖАНИЕ
ЭЧТӘЛЕК

Айдарова С.Х., Гарипова-Хасаншина В.М. Уроки татарского языка на краткосрочных курсах 3
Алшейхо Газала Специфика ономастики и топонимики гидронимов турецкого и татарского языков 7
Болгарова Р.М., Исламова Э.А. Особенности функционирования тюркизмов в сравнениях русского языка 16
Вершинина Т.В. Связь фразеологии и языковой картины мира 21
Гайнуллина Г.Р. Ә. Еники публицистикасында башлангыч мәктәптә туган телне өйрәтү мәсьәләләренә карашлар 23
Гайнутдинова А.С. Ортактюрк тили в современности 25
Гайсина Р.С. Башлангыч сыйныф укучыларында этномәдәни компетенция формалаштыру юллары 29
Галиева Л. А. Руские фразеологизмы как средство формирования коммуникативной компетенции учащихся 7-8 классов 33
Галиева Р.Т. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә уңай мотивация тудыру – белем сыйфатын арттыру чараларының берсе 38
Галимҗанова Р.Ф. Кейс-технология һәм аны татар телен укытуда куллану мөмкинлекләре 43
Галиуллина Г.Р. Татар теле белемендә синонимнарны өйрәнү тарихына күзәтү 47
Гареева Р.Р., Гареева М.Р. Некоторые особенности разговорной речи студентов в полилингвальном образовательном пространстве 50
Гареева Р.Р., Гиззатуллина А.Ф. Иновационные педагогические технологии на уроках татарского языка 54
Гарифуллина Г. А. Логопедическая мнемотехника как средство активизации речевой деятельности детей 58
Гарифуллина Л.И. Обучение родного (татарского) языка в начальной школе 60
Гатауллина А. С. Халык һәм автор җырлары 63
Гилазетдинова Г.Х., Абдрахманова Ю.Д. Специфика путешествия как литературного жанра в России конца XIX века 68
Гилязова Р.Р., Ашрапова А.Х. Интерактивный подход при обучении иностранному языку детей дошкольного и младшего школьного возраста 73
Гаязова Д. И. Проект технологиясен татар теле дәресәрендә куллану ысуллары 77
Гомәрова Г.А. Туган телгә өйрәткәндә заманча һәм инновацион технологияләрне куллану 81
Гыйләҗева Л.Г. Татар телен чит тел буларак өйрәтү дәресләрендә лексиканы һәм грамматиканы активлаштыру 84
Денмухаметова Э.Н. Языковая личность в полилингвальной среде и мониторинг знаний выпускников по татарскому языку 88

Замалетдинова Г.Ф. Концепт җан / душа в татарском языковом сознании 93
Замалетдинов Р.Р. О новой системе оценки уровня владения татарским языком 97
Зөфәрова Г. Хәзерге татар һәм төрек телләрендә мөрәҗәгать итү алымнары 102
Ибнеева А.М., Марданова З.Р. Развитие коммуникативных компетенций учащихся на уроках литературы в начальной школе 105
Измайлова Г. А., Замалетдинова Г. Р. Молодежный сленг в современном английском языке 109
Иргалина З. Г. Мобильные инновационные технологии в обучении иностранному языку 112
Исламова Л.Л. Татар һәм казах телләрендә «баш» компонетлы фразеологизмнар 116
Исмаилова М. Этнокультурологическая характеристика кулинарной культуры Азербайджана 120
Исхакова Р. Ш . Азнакай районында хәзерге татар теле лексикасын өйрәтү 127
Karimova I. M.Caucasus area of toponyms of Turkish origin 130
Каюмова И.Ф. , Мударисова Р.Р. Современные цифровые средства обучения языкам 138
Кәлимуллина Л.Ю. Татар теле дәресләрендә заманча һәм иннавацион технологияләр куллану 141
Кириллова З.Н. Германия һәм Венгриядә татар телен укыту 145
Лукаш Л.В. Применение инновационных технологий на уроках русского языка и литературы в современной школе 149
Мансурова З.Җ. Татар телен өйрәтүдә сыйныфтан тыш уку дәресләренең роле 152
Мирзагитов Р.Х. Подготовка би- и полилингвалтьных педагогических кадров в казанском федеральном университете 155
Мигранова Л.Ш. Изучение фразеологических единиц на уроках родного языка (русского) 159
Мөгътәсимова З.А. «Кара» компонентлы татар мәкальләренә лингвомәдәни анализ 164
Мухаметьянова Э. Р. Совершенствование образовательной среды на уроках татарского языка и литературы 167
Насипов И. С., Рамазанова А. Р. Г. Ибраһимовның «Казак кызы» романындагы тел үзенчәлекләрен урта мәктәптә өйрәнү 171
Нәбиева Я.К. Схемалылык эш технологиясе куллану буенча тикшеренү нәтиҗәләре 174
Нәбиуллина Г.Ә. Татар сөйләм этикетына өйрәтү алымнары 177
Нәүмәтова Р.Р. Татар теленә өйрәтүдә әхлакый кыйммәтләрне формалаштыру чарасы буларак мультипликацион фильмнар 180
Некрасова Т.В., Моисеенко Л.Н. Нарративный подход в методике

преподавания иностранного языка в условиях глобализации профессионально - ориентированного образовательного процесса 185
Нигамаева Г.Г. Развитие речи младших школьников в поликультурной среде 190
Нигметзянова А.Р., Садыкова А.М. Внедрение компьютерных технологий в процессе обучения 195
Нурисламова З.Г. Туган тел һәм әдәбиятын укыту мәсьәләләрен чишүдә универсаль уку гамәлләрен үзләштерүгә юнәлтелгән биремнәрнең әһәмияте 197
Нурмөхәммәтова Р.С. XXI гасыр русча-татарча һәм татарча-русча сүзлекләре 200
Нуэрмаймайти Нуэрсяти. Поздравления в речи уйгур 205
Öner Mustafa. «Ege-türkoloji»de çağdaş türk yazi dilleri öğretimi ve araştirmasi 209
Сәгъдиева Р.К., Хөснетдинов Д.Х. Туган (татар) тел дәреслекләрендә электрон дәреслекләрне файдалану 214
Сабирҗанова Р. Р. Сүз сәнгатендә кешелек кыйммәтләренең бирелеше 218
Саде Бейза. Характерные особенности использования компонентов-зоонимов в пословицах турецкого и татарского языков 220
Салахова А.Р. Лексикографическое описание мифологического персонажа “дию” 223
Саматова И.Р. Татар телендә исем фигыль һәм аны укыту үзенчәлекләре 226
Саматова М.А. Ясалма сүзләр системасында синоним, антоним, омонимнар 229
Samedova K. I. Non-Terminological words in the Northern dialects of the Azerbaijani language 234
Саттарова М.Р. Татар һәм рус телләрен чагыштырма өйрәнү: актив һәм пассив төзелмәләр кулланылышы үзенчәлекләре 240
Сафина Э. И. Туган тел дәресләрендә татар сүзлекләре 244
Сәлахова Р. Р. Татар теле дәресләрендә сөйләм телен үстерү һәм камилләштерү чарасы буларак кроссвордлар 249
Селендили Л.С. Первые шаги в обучении крымскотатарскому языку 255
Сибгаева Ф.Р. Татар теле дәресләрендә интеграль алымның роле 261
Файзуллина Г.Ч. Метрические записи XIX – начала XX вв. о тобольских бухарцах как историко-лингвистический источник 265
Фаттахова Р. Ф., Шәмсетдинова Р.Р. Татар теле дәресләрендә укучыларның тел байлыгын үстерү 269
Фәтхуллова К.С., Мөгътәсимова Г.Р. Телләрне заманча укытыйк 274
Фәхриева Л.Х. «Пушкин илә Лермонтовтан үрнәк алам…» (Г. Тукай әдәби мирасында «Пушкиннән мокътәбәс» ирекле шигырьләренең тель-стиль үзенчәлекләре) 277
Ферафонтова А.И. Синонимическая парадигма в филологических

исследованиях 281
Хәева Ф. Җ. Татар теле һәм татар әдәбияты дәресләрендә куллану өчен, learningapps.org сервисы ярдәмендә интерактив биремнәр төзү 284
Хаева-Хаметзянова В.Х., Фатхуллова К.С. Развитие коммуникативной одаренности учащихся гимназии 289
Халиуллина А.Г., Башарова Г. Сопоставительный анализ переводов романа Марка Твена «Приключения Тома Сойера» на русский и татарские языки 294
Халиуллина Н.У., Басырова А.Р. М. Кашгарлының "Диване лөгат әт-төрк" сүзлегендәге лексик параллельләрнең семантик үзенчәлекләре 297
Халиуллина Э.У., Сираева А.А. Функционирование концепта өй «дом» в памятниках древнетюркской письменности 302
Харисов Ф.Ф. Татар теле дәресәлрендә компетенцияләр формалаштыру мәсьәләсе 306
Хәйретдинова Л.Н. Татар теле дәресләрендә проект эшчәнлеген оештыру 310
Хәйруллин И.Р. Дәресләрдә мультимедиа технологияләрен куллану 314
Һадиева Г.К., Кузьмина Х.Х. Гомуми белем бирү оешмалары өчен татар телендә төзелгән дәреслекләрдә топонимик материалның кулланылышы 316
Шаймердинова Н.Г. Взаимодействие казахского языка с кыпчакскими и огузскими языками в Казахстане 321
Хөснетдинов Д.Х., Сагдиева Р.К. Сәламәтлек саклау технологиясе нигезендә язучы телен өйрәнү 329
Шаймухаметова Р.Р. Универсаль уку гамәлләрен формалаштыру позициясеннән, заманча чит тел дәресләре проектлаштыру 332
Шәмсетдинова Р.Р., Фаттахова Р.Ф. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә укучыларның функциональ грамоталылыгын формалаштыру 335
Шәрифуллина Р.И. Милли мәгарифнең белем сыйфатын күтәрүдә төп бурычлар 339
Шиһабеддинова Г.Х. Татар теле дәресләрендә мәгълүмати технологияләр куллану 343
Юсупова Ә.Ш. XIX гасыр татар теле үзөйрәткечләре 348
Юсупов А.Ф., Юсупова Н.М. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә дистанцион укыту технологиясен куллану 355

*Научное издание*

**СОВЕРШЕНСТВОВАНИЕ МЕТОДИКИ ОБУЧЕНИЯ ЯЗЫКАМ**

**ПЛОЩАДКА ОБМЕНА ПРОГРЕССИВНОЙ ПРАКТИКОЙ**

**ТЕЛЛӘРГӘ ӨЙРӘТҮ МЕТОДИКАСЫН КАМИЛЛӘШТЕРҮ**

**АЛДЫНГЫ ТӘҖРИБӘ БЕЛӘН УРТАКЛАШУ МӘЙДАНЧЫГЫ**

МАТЕРИАЛЫ МЕЖДУНАРОДНОГО НАУЧНО-МЕТОДИЧЕСКОГО

ОНЛАЙН-СЕМИНАРА

(18 февраля 2021 г.)

Подписано в печать 17.03.2021.
Бумага офсетная. Печать ризографическая.
Формат 60х84 1/16. Гарнитура «Times New Roman». Усл. печ. л. 35,5
Усл. изд. л. 42,1. Тираж экз. Заказ электронный формат

Отпечатано с готового оригинал-макета
в типографии Издательства Казанского университета

420008, г. Казань, ул. Профессора Нужина, 1/37
тел. (843) 233-73-59, 233-73-28